ГРАДУСЛЫ АКЧА

Татарстанда исерткеч эчемлекләр сату вакытын өч сәгатькә озайттылар

> 15

ТЫЕЛГАНЫ ТАТЛЫРАК

Баласыз тормыш рәвешен алга сөрүчеләрне җәзага тартырга тәкъдим итәләр

> 16

МАРАТ КӘБИРОВ:

«Үзебезне икенчел дип кабул итүгә күнегеп киләбез»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 41 (28814) | Җомга | 25 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ЙӘ МИН, ЙӘ АВЫЛ?!

ШӘҺӘРГӘ КИТҮЧЕЛӘР САНЫ АРТА БАРА

Соңгы 20 елда республикада 100 меңнән артык кеше авылдан шәһәргә күченгән. Бу – уртача 4–6 район бушап калган дигән сүз. Шәһәргә китүчеләр арасында хатын-кызлар дүрт мәртәбә күбрәк икән, ә, гомумән, китүчеләрнең өчтән бере – 15–39 яшьтәгеләр. Татарстанның фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе президенты Камияр Байтимеров, миграция темплары бернинди кысаларга сыймый башлады, ди. Белгечләр моннан фаҗига ясарга кирәкми дип саный, дөрес. Шулай да, авылларны ничек саклап калырга соң?

> 6

Ишетми калмагыз

Махсус ипотека үзгәрми

Россия Президенты Владимир Путин вице-премьер Марат Хөснуллинның ташламалы ипотека ставкасын 12 процентка кадәр арттыру, авыл, гаилә һәм Ерак Көнчыгыш ипотекалары буенча элеккеге ставкаларны саклап калу турындагы тәкъдимен хуплады. Бу турыда ул Министрлар Кабинеты әгъзалары белән киңәшмә вакытында әйтте. Дәүләт җитәкчесе әйтүенчә, ташламалы ипотека ставкасы 12 процентка җитсә дә, бу сан барыбер базар ставкасыннан ике тапкыр чамасы ким.

Ипотеканы Үзәк банкның төп ставкасы артканчы алучылар исә аны элеккечә түләячәк. Бу хакта Россия Премьер-министры Михаил Мишустин белдерде. Хөкүмәт алдында чиктән тыш мөһим бурыч: үзгәрүчән ставкалы кредит алып, хәзер процентларның үсүеннән аптырап калган кешеләргә ярдәм итү бурычы тора. Илдә 11 триллион сум күләмендәге әнә шундый кредит рәсмиләштерелгән.

КФУга ректор тәкъдим ителде

КФУ Күзәтчелек советы вуз ректоры вазыйфасына Ленар Сафинны билгеләүне тәкъдим итте. Совет утырышы Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов рәислегендә узды. Университет уставы нигезендә, вуз ректорын Күзәтчелек советы тәкъдим иткән кандидатуралар арасыннан Россия Хөкүмәте билгели.

Ленар Сафин Федерация Советының Икътисади сәясәт комитеты рәисе беренче урынбасары булып тора. Моңа кадәр Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры вазыйфасын биләде, 1995–2008 елларда университетның юридик факультетында укытты.

Исегезгә төшерәбез: Россия Фән һәм югары белем министрлыгы 21 мартта КФУның элекке ректоры Илшат Гафуров белән хезмәт килешүен өзде. КФУ ректоры вазыйфаларын башкаручы итеп Дмитрий Таюрский билгеләнде.

1 апрельдән башлана

23 апрельдә Казанда шәһәр территориясен чистарту буенча өмә узачак. Мэрия документлары җыентыгында бу җәһәттән тиешле карар басылып чыккан. Өмәдә юллар, ишегаллары, чүп контейнерлары мәйданчыклары, тукталышлар тәртипкә китереләчәк, агач-куаклар утыртылачак, бакчалар, парк, скверлар җыештырылачак. Казан районнары хакимиятләренә һәр көн саен тиешсез урыннардагы чүплекләрне, пычрак урыннарны ачыклау сорала.

Исегезгә төшерәбез: Татарстанда 1 апрельдән 31 майга кадәр торак пунктлар территорияләрен чистарту буенча санитария-экология икеайлыгы уздырылачак.

Районнарда ни хәлләр?

Зәй

Шәһәр һәм авыл мәктәпләренең IX сыйныф укучылары үзләрен ZainSkills чемпионатында һөнәри осталык буенча сынадылар. Узган ел ярышлар графикалы дизайн юнәлеше буенча гына үткән булса, быел укучылар төрле мәйданчыкларда эретеп ябыштыру, эшмәкәрлек, веб-дизайн һәм пешерү осталыгы буенча көч сынашты. Егетләр эретеп ябыштыру буенча биремнәрне үтәде, ә кызларга винегрет ясарга һәм катлы камырдан татлы ризык пешерү бурычы куелды. Компьютер программаларын үз иткән укучылар бәйгенең «Веб-дизайн» компетенциясендә сайтларның дизайнын ясады. «Эшмәкәрлек» юнәлешендә укучылар, командаларга бүленеп, бизнес-план төзеп, аны жюри алдында яклады.
(«Зәй офыклары»)

Кукмара

Аш-Буҗи авылында «Мәдәният» илкүләм проекты буенча төзелгән клуб ачылды. «Авылның киләчәге бар, биредә тырыш халык яши, балалар да күп. Без республикада эшләп килүче күп кенә программаларда катнашабыз һәм алар буенча районда зур күләмле эшләр башкарабыз. Аш-Буҗи авылы мәдәният йорты да – моның бер мисалы. Мәдәният учагы гөрләп эшләр, биредә җыр-моң тавышы тынмас дип ышанам», – диде район башлыгы Сергей Димитриев тантанада. Яңа клуб йөз урынга исәпләнгән, ул заман таләпләрен исәпкә алып салынган. Әлеге проект буенча, 2020 елда Иске Юмья авылында да яңа клуб файдалануга тапшырылган иде.
(«Хезмәт даны»)

Түбән Кама

Районда яшәүче яшь парлар язылышу өчен «матур дата»ларны сайларга тырыша. 22 март сишәмбегә туры килүгә карамастан, бу көнне 13 пар язылышырга теләк белдергән. Гадәттә, бу көнне язылышучыларны теркәү башкарылмаса да, ЗАГС хезмәткәрләре аларга каршы килмәгән. Түбән Камада 22 гыйнварда (шимбә) – 12, ә 22 февральдә (сишәмбе) 20 пар гаилә корган.
(e-nkama.ru)

Балтач

Район мәдәният үзәгендә «Татар кызы – Татар егете – 2022» бәйгесенең районкүләм финалы узды. Алты кыз һәм җиде егет әлеге бәйгенең алты турында катнашып, сыналып, финалга үтте. Алар залдагы тамашачыны үзләренең осталыклары, тапкырлыклары, җитезлекләре, җыр-биюгә һәвәслекләре белән сокландырды. Җиңүче «Татар кызы» булып Балтачтан Диләрә Кәшәфуллина танылды, ә «Татар егете»ндә беренче урын Бөрбаш Сәрдегәне авылы егете Инсаф Хәлиуллинга бирелде.
(«Хезмәт»)

НӘҮРҮЗ КИЛЕШҮЛӘРЕ

Татарстан Президенты Үзбәкстанга сәфәр кылды. Рөстәм Миңнеханов «Чирчик» технопаркын ачуда катнашты, эшлекле очрашулар уздырды һәм дәүләт башлыгы Шәүкәт Мирзиёев белән хезмәттәшлекне үстерү турында фикер алышты.

Ташкентка килгәч, Рөстәм Миңнеханов, иң беренче эш итеп, Үзбәкстандагы милләттәшләребез белән очрашты. Бу илдә 300 меңнән артык татар яши. Күбесе Ташкент һәм Сәмәрканд өлкәләрендә көн күрә. Апрель башында Ташкентта татар иҗтимагый мәдәни үзәгенең 30 еллыгын билгеләп үтәргә әзерләнәләр. Әлеге тантанага Татарстан Президентын да чакырдылар. Бу чарага бездән мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре барачак. Моннан тыш, көз көне «Татар кызы» конкурсының финал бәйгесен уздырырга ниятлиләр. Рөстәм Миңнеханов исә милләттәшләребезне Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан узасы бәйрәм чараларына, Бөтендөнья татар конгрессының 8 нче корылтаена чакырды.

Үзбәкстан Премьер-министры Абдулла Арипов белән эшлекле очрашуда ике арадагы хезмәттәшлекне үстерү турында фикер алыштылар. Аерым алганда, «КамАЗ» автомобильләре, автобуслар һәм электробуслар сату, «Түбән Кама шин» продукциясен җибәрү, «Татнефть»нең ягулык салу станцияләре санын арттыру турында сөйләштеләр. Рөстәм Миңнеханов Татарстандагы башка эре компанияләрнең эшчәнлеге турында да сөйләде.

Рөстәм Миңнеханов белән Абдулла Араипов бергәләп башкарылган иң зур уртак проектларның берсе – «Чирчик» химик-индустриаль технопаркын ачу тантанасында да катнаштылар. Сүз уңаеннан, Татарстанның «ВР – Пласт» (пластик җитештерә), «Бионоватик» (үсемлекләрне саклау чараларын җитештерә) һәм «Табигый сәламәтлек» (биологик актив өстәмәләр җитештерә) компанияләре Ташкент өлкәсендә урнашкан әлеге технопаркның иң беренче резидентлары булды. Хәзер биредәге шартлар белән

tatarstan.ru

Россия генә түгел, Кытай, Һиндстан, Көньяк Корея һәм башка ил ширкәтләре дә кызыксына.

Тантана Ташкент шәһәре хакимияте һәм Татарстан Хөкүмәте арасында 2022–2023 елларга хезмәттәшлекне киңәйтү буенча «юл картасы»н имзалау белән тәмамланды. Гомумән алганда, әлеге сәфәр барышында Татарстан делегациясе вәкилләре белән Үзбәкстан предприятиеләре арасында 20дән артык килешү имзаланды.

Үзбәкстан Президенты Шәүкәт Мирзиёев белән очрашуда хезмәттәшлекне тагын да арттыру турында сөйләштеләр. «Сезнең илдә эшләүче Татарстан компанияләренә ярдәмегезне югары бәялибез, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Бу катлаулы шартларда да нәтиҗәле сәүдә-икътисади һәм мәдәни-гуманитар хезмәттәшлекне саклап калдык. Уңай тәҗрибә алга таба да безнең илләр арасындагы яхшы мөнәсәбәтләрне үстерүгә ярдәм итәр дип ышанам».

Татарстан Президенты әйтүенчә, соңгы 5 елда Татарстан белән Үзбәкстан төбәкләре арасындагы мөнәсәбәтләрнең тотрыклы рәвештә ныгуында Үзбәкстан Президентының да өлеше зур. 2021 ел нәтиҗәләре буенча ике арадагы товар әйләнеше 23,5 процентка артып, 200 млн долларга якынайган. Әмма мөмкинлекләр тулысынча файдаланылмый. Рөстәм Миңнеханов Шәүкәт Мирзиёевны Татарстанга чакырды. Үзбәкстандагы милләттәшләребезгә күрсәткән ярдәме өчен рәхмәт белдерде һәм Нәүрүз бәйрәме белән котлады.

Президент Чаллының хәлен белеште

«Акыллы завод», икмәк, машина... Чаллыга эш сәфәре кысасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шәһәрнең төп предприятиеләре эшчәнлеге белән танышты.

«ИХТЫЯҖ ЗУР». Чикләүләр чорында сәнәгать предприятиеләре аварлыклар белән очрашты. Бу бигрәк тә чит ил технологияләре, җиһазлау, материалларга кагыла. Татарстан Президенты әйтүенчә, хәзер төп бурыч – стратегик әһәмияткә ия булган предприятиеләрнең өзлексез эшләвен тәэмин итү. Чаллыда ул «КамАЗ» җәмгыяте ихтыяҗлары өчен комплектлау чаралары җитештерүдә импортны алыштыру кысасында хезмәттәшлекне үстерү һәм материалларны үзләштерү буенча киңәшмә уздырды.

Искәртеп үтик: КамАЗ – илдә йөк автомобильләре җитештерүче иң зур компания. 2021 ел нәтиҗәләре буенча 44 меңгә якын йөк машинасы җитештереп чыгарган. Экспортка 5,8 мең берәмлек техника чыгарылган, ә Россия авыр йөк машиналары базарында «КамАЗ»ның өлеше 44 процентны тәшкил итә.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, «КамАЗ» автомобильләренә ихтыяҗ да, кызыксыну да зур. Киңәшмәдә импортка алмаш табу мөмкинлекләре каралды. Бу хәзерге шартларда аеруча мөһим. «Безгә предприятие эшчәнлеген дәвам иттерү, ниятләгән эшләрне башкару кирәк», – дип ассызыклады республика Президенты.

ҖИТЕШТЕРҮ ТУКТАМЫЙ. Сәфәр кысасында, Президент «Хайер Индастри РУС» көнкүреш техникасы заводы эше белән дә танышты. Хәзерге вакытта җәмгыятьнең «акыллы завод» төзелеше бара. Биредә суыткыч һәм суыту җиһазларын җитештерәчәкләр.

ИКМӘК БАР! Рөстәм Миңнеханов «Агросила. Челны-МПК», һәм «Чаллы икмәге» җәмгыятенең эш барышы белән танышты.

«Агросила» предприятиесендә Президентка продукция төрү цехларын, чимал әзерләү мәйданчыкларын, ыслау камераларын күрсәттеләр. Сүз уңаеннан, ул – Татарстанда аена 100 тонна күләмендә казылык һәм ярымфабрикатлар җитештерү мөмкинлеге булган бердәнбер предприятие. Аның продукциясенә Үзбәкстан һәм Азәрбайҗанда да кызыксыну бар. Экспортның зур өлеше хәләл ризыкларны сатуга карый.

«Чаллы икмәге» исә бүген Татарстанның Кама аръягы төбәгендә икмәк-күмәч һәм кондитер ризыкларын җитештерүче иң эре предприятиеләренең берсе санала. Биредә тәүлегенә 80 тоннадан артык продукция җитештерелә. 2020 елдан предприятие хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча федераль программага керде.

ЯРДӘМ ЮЛГА ЧЫКТЫ

Луганск һәм Донецк республикаларыннан күченүчеләр өчен Ростов өлкәсенә Казаннан чираттагы гуманитар ярдәм юлланды. Гуманитар йөкне «Бәхетле» складыннан төяп җибәрделәр. Бу эшнең ничек оештырылуы белән Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин танышып кайтты.

tatarstan.ru

«Республикадан моңа кадәр дә берничә гуманитар эшелон җибәрелде инде, – диде парламент башлыгы журналистларга. – Безнең халыкка игелеклелек, бәлагә юлыккан кешеләргә ярдәм кулы сузу хас. Хәйрия акциясенә «Бердәм Россия» партиясе әгъзалары һәм «Яшь гвардия»челәр генә түгел, милли-мәдәни автономияләр вәкилләре, волонтерлар, яшьләр дә кушылды. Чираттагы гуманитар йөкне бергәләп җыйдык. Менә хәзер 12 тонна йөк төялгән фураны озатабыз».

Фәрит Мөхәммәтшин хәйрия акциясендә катнашучыларның һәркайсына рәхмәт сүзләре җиткерде. «Үзләре өчен дә шундый катлаулы чорда, санкцияләр шартларында Луганск һәм Донецк республикаларыннан күченүчеләргә ярдәм кулы сузучыларның һәркайсына рәхмәт», – диде ул. Фәрит Мөхәммәтшин, «бердәмроссияле»ләргә әлеге изге эшне оештырган өчен рәхмәт белдереп, башка партияләр вәкилләрен дә акциягә кушылырга чакырды.

«Бердәм Россия»нең күп кенә әгъзалары, гуманитар ярдәм белән беррәттән, матди ярдәм дә күрсәткән. «Авырлыклар берләштерә, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Мондый чакларда бер-береңнең ярдәмен тою бигрәк тә мөһим. Мин моның яшьләр өчен бик зур тәрбияви нәтиҗәсен дә күрәм».

Донецк һәм Луганск республикаларыннан мәҗбүри күченүчеләргә ярдәм итү эшенә торган саен күбрәк кеше кушыла. Россиядә алар өчен кирәкле әйберләр җыю буенча 700дән артыграк үзәк ачылган.

Республикадан Ростов өлкәсенә 5 йөк машинасы белән 50 тоннадан артыграк гуманитар ярдәм җибәрелгән инде. Бу юлы татарстанлылар азык-төлек, көнкүреш химиясе, көнкүреш техникасы, урын-җир кирәк-ярагы, балалар киеме, язу-сызу, гигиена әйберләре җыеп озаткан.

КӨЧНЕ БЕРЛӘШТЕРЕР ЧАК

Катлаулы чорларда бердәмлек сынала. Татарстан халыклары ассамблеясы Советының чираттагы утырышындагы төп фикер әнә шул булды. Утырышта 2021 елга нәтиҗәләр ясалды, 2022 елга максатлар билгеләнде.

Быел Татарстан халыклары ассамблеясы 30 еллыгын билгеләп үтә. Шул уңайдан, Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе, ассамблея Советы җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин ассамблеяның үсеш-үзгәреш тарихына тукталды. «Хәзерге вакытта Татарстан халыклары ассамблеясы 249 милли иҗтимагый берләшмәне берләштерә. Ассамблея оешканнан бирле республикадагы милли хәрәкәт географиясе киңәя. Әйтик, узган ел дәвамында гына да без Буада Дуслык йорты, Татарстан буенча җиде вәкиллек һәм ике милли-мәдәни берләшмә ачтык», – диде ул.

Фәрит Мөхәммәтшин илдәге вазгыятьнең әле дә катлаулы сакланувын әйтте һәм караңгы чорларда бердәмлекнең чын мәгънәсендә сыналуына берничә мәртәбә басым ясады. «Милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзенчәлеге шунда ки, аларның чишелеше юк, ягъни аларга даими игътибар кирәк. Бигрәк тә бүгенге вазгыятьтә. Татарстанның күпмилләтле халкы һәрвакыт бердәм булды, бүген дә уртак гамәлләре белән шуны раслап тора. Әйтик, шушы көннәрдә 25 оешма, 50дән артык милләт вәкиле белән берлектә Луганск һәм Донецк республикаларыннан күченергә мәҗбүр булучылар өчен 3 млн сумнан артык гуманитар ярдәм җыйды», – диде ул.

Халыклар ассамблеясы Советының Башкарма комитеты җитәкчесе Константин Яковлев исә 2021 елгы эшчәнлекләренә нәтиҗә ясады. «Узган ел Татарстанның этномәдәни тормышы якты һәм бай булды. Республикада игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы безгә бик күп масштаблы чаралар бүләк итте», – диде ул. Комитет җитәкчесе үз чыгышында миграция мәсьәләләренә аерым тукталды. «Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре идарәсе статистикасы буенча, 2021 елда 256 меңнән артык чит ил кешесе миграция исәбенә кертелгән. Аларның күбесе (63 мең) – эшкә, 30 меңнән артыгы шәхси максат белән килсә, 25,5 мең кеше Татарстанда белем ала. Ассамблея миграциягә бәйле проблемалар һәм хокук яклау мәсьәләләрен хәл итү буенча профилактик эшне даими рәвештә алып бара», – дип сөйләде Яковлев.



Утырышта «Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе» мәгариф үзәге җитәкчесе Майя Хухунашвили да катнашты. Хәзерге вакытта мәктәпкә 448 бала йөри икән. Фәрит Мөхәммәтшин сыйныфларны киңәйтергә һәм мөгаллимнәр җәлеп итәргә кирәклеген искәртте. «Мондый очрашуларда проблемалар турында күбрәк сөйләсәк иде. Хәл итү юлын ничек тә табарбыз», – диде ул.

Инде әйтелгәнчә, майда Татарстан халыклары ассамблеясы төзелүгә 30 ел тула. 2022 ел Россиядә Мәдәни мирас елы дип игълан ителде. Республика һәм бөтен мөселман дөньясы Идел буе Болгар дәүләтендә ислам кабул ителүнең 1100 еллыгын билгеләп үтәчәк. «Алда безне күп чаралар көтә. Көчләребезне берләштерер чак. Милләтара тынычлык һәм татулыкның уртак эшебезнең нигезе булуын онытмасак иде», – диде Мөхәммәтшин.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ТОРГАН САЕН НЫГРАК «ТЕШЛИ»

ТОВАРЛАРГА БӘЯ АРТУ СӘБӘПЛӘРЕ

Росстат мәгълүматлары буенча, узган атнада помидор – 12,2, кер юу порошогы – 3,6, тузан суырткыч бәясе 8,4 процентка күтәрелгән. Бәяләрнең болай сикереп уйнавының сәбәпләре нидә?

Икътисад базарындагы монополия. Мәгълүм булганча, Монополиягә каршы федераль хезмәт шикәр җитештерүчеләр арасында тикшерүләр оештыра башлады. Җитештерүчеләр үз продукциясенә бәяне 60–70 процентка арттырып тәкъдим итә. Шул рәвешле, шикәр кушылган барлык продукциягә дә бәя артачагы көн кебек ачык. Россиядә шикәр белән тәэмин итүчеләр болай да аз. Шуңа да заводлар үз җырын җырлап, үз кагыйдәләренә буйсындырырга маташмый түгел. Моңа да карамастан, илнең сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Виктор Евтухов Россиядә шикәр җитәрлек күләмдә дип ышандырды.

Сатып алуга бәйле ажиотаж. Шикәргә ияреп, ярмаларның да бәясе кискен артты. Тармак министрлыгы азык-төлек җитәрлек дип әйтүгә карамастан, халык кирәк-яракларны тизрәк күпләп алып кую ягын кайгыртты.

Үзәк банк башлыгы Эльвира Нәбиуллина сүзләренчә, санкцияләр аркасында чит ил компанияләренең ил базарыннан китүе, рубль курсы төшкәч, кытлык булыр дип, халыкның автомобиль, көнкүреш техникасы, җиһазлар, электрониканы күпләп сатып алуы ажиотаж тудырды.

Доллар курсының үзгәрүе. Чит ил валютасы читтән кертелә торган товарларга йогынты ясый. Тик Россия эчендә җитештерелә торган кайбер товарларга да читтән кертелгән ярдәм кирәк. Мәсәлән, киемсалымга, өй җиһазларына бәя артуга чит илдән кертелгән тукыма, буяу, фурнитура да йогынты ясый.

Үзбәясе арту. Теге яки бу товарга бәя аны җитештергән чактагы үзбәясенә бәйле рәвештә дә үзгәрергә мөмкин. Әйтик, авыл хуҗалыгы тармагын карасак, маллар өчен азык, ашламаларның бәясе күтәрелде.

Чит ил компанияләре сәясәте. Товарларның күп өлешен Россия территориясендә җитештерүгә карамастан, чит ил компанияләре продукцияләренә бәяне күтәрде. Мәсәлән, P&G компаниясе Ariel һәм Tide кебек кер юу, Fairy савыт-саба юу чаралары өчен күбрәк түләргә кирәк булуын искәртте. Моңа рубль курсы да, җитештерү материалларына бәя арту да, продукцияне ташу-тарату юнәлешендәге кыенлыклар да сәбәпче, диләр.

Бу – кызык!

24 февральдән 15 мартка кадәр социаль челтәрләрнең көндәлек аудиториясе ничек үзгәргән? Mediascope тикшеренү компаниясе шуны ачыклаган.

- «Инстаграм»* аудиториясе 16 процентка кимегән (40,9 миллионнан 34 миллионга калган).
- «Телеграм» – 35,7 миллионнан 47,3 миллионга кадәр арткан.
- «Фейсбук»* – 10 миллионнан 6 миллионга калган.
- «Твиттер» – 2,5 миллионнан 1,2 миллионга төшкән.
- «Одноклассники» – 1 млн кулланучыга арткан.
- «ВКонтакте» – кулланучылар саны 4 миллионга арткан.
- «ТикТок»та үзгәрешләр юк.

*Россия территориясендә тыелган.

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Саботаж

Бу араларда кибетләрдә төрле ярмалар, писук, тоз бетте. Бетмәс иде, халык кибетләргә ябырылды. Кирәге чыгар, дип бөтен нәрсәне кырып-себереп алып бетерә башлады. Хөкүмәт әһелләре халыкны борчылмаска өнди. Өзеклек килеп чыкмаячак, бөтен нәрсә булачак, ди. Әмма халык ышанмый. Иң кызыгы: ярма-писукларне, тозны күпләп-күпләп алып бетерә дә, кибет киштәләре бушый башлаганын күреп: «Менә ышан син хөкүмәткә!» – дип тавыш куптара. Ә сәүдә өлкәсендәге шәхси эшмәкәрләр, кычыта башлаган уч төпләрен уа-уа, бәя күтәрәләр. Халык исә бәя икеләтә, өчләтә күтәрелсә дә, иртәгәге көнне кайгыртып, запас туплый бирә. Моннан җан тынычлыгы таба ул, күңеленә горурлык хисләре артканнан-арта барудан башы тагын да югары күтәрелә. Менә нинди булдыклы кеше бит ул!

Әмма запасы күп булуын хәтта якын дусларына да бик үк әйтмәскә тырыша. Чөнки бурычка сораулары бар. Иртәгәге көнне кайгыртучылар даирәсендә үзенчәлекле бизнес әһелләре – спекулянтлар барлыкка килде. Совет заманында аларга җинаять җәзасы яный иде, хәзер бу «бизнес» өчен менә дигән шартлар туды.

Сүз уңаеннан, Горбачев керткән «коры закон» чорында хәмер сату белән шөгыльләнүче кече эшмәкәрлек вәкилләре – шинкарьләр барлыкка килгән иде. Борынгы Русьтә хәмер сату урыны «шинок» дип аталган ди. Ни өчендер, безнең шинкарьләр – нигездә, әби-чәбиләр. Бу бизнесның җенесе бүген дә үзгәрмәде, кибет киштәләрен бушатучылар да – шул ук хәрмәтле апалар-әбиләр. Әмма «гүзәл затлар», үзләре дә белмичә, зур сәяси хата ясамыйлар микән? Азык-төлек кытлыгы тудыру – саботаж түгел микән дип тә шикләнәм.

Саботаж димәктән, ул – борын-борын заманнарда ук Франциядә килеп чыккан сүз һәм «агач башмак» дигәнне аңлата. Яңа технологияләр фабрикаларда кул көчен кысрыклап чыгара башлагач, эшчеләр протест йөзеннән агач башмак шакылдата, шул башмак белән станокларны туктата башлаганнар ди. 1926–1958 елларда, Россия Җинаять кодексы буенча, саботаж «контрреволюцион» җинаять исәпләнгән.

Корткычлык тарих сәхнәсеннән китмәс, мөгаен. Бәлки, максатлары үзгәреп, төрле төсмерләргә баер. Бүген саботаж хакимиятне көчсезләндерү максатында да файдаланыла диләр. Бүгенге вазгыятьтә иртәгәге көнне кайгыртып, кибет төпләрен сагалаганнарны «саботажник»лар дип атарга тел әйләнми. Әмма аларның гамәлләре хакимият абруена сукмыйча калмый дип уйлыйм. Бит киштәләрдә көнкүреш кирәк-яраклары юкка чыгу күпмедер дәрәҗәдә паника тудырмый калмый. Бу үз чиратында бәяләр күтәрелүгә китерә.

Язмамны тәмамлар алдыннан кайбер районнарга шалтыратып алдым. Хәзер кибетләрдә писук, тоз җитәрлек ди. Әмма шикәр комы кыйбатланган, ә тоз бәясе, гомумән, өч мәртәбә арткан ди. Иң кызыгы: ни өчен тозга кытлык тудырылды соң? Ул бит кашыклап ашый торган ризык түгел. Табиблар әйтүенчә, кешегә тәүлеккә 6–8 грамм тоз җитә һәм организм аны үзе үк ризыклардан ала. Әмма халык аны кибетләрдән күтәрә алган хәтле ташыды, нәтиҗәдә тоз киштәләрдән юкка чыкты. Ярый әле хәзер бөтен авырлыкларны уен-көлке белән үткәреп җибәрергә тырышабыз үзе. Әмма һәрвакыт без уйлаганча барып чыкмый.

Беркөнне дусларның берсе шалтырата. «Хатын белән талаштык бит әле, малай», – ди. Хатыны тозсыз аш пешергән булган, ә дустым аңа: «Картаясың, карчык, ашка тоз салырга да оныта башладың», – дигән. Ә хатыны: «Тозсыз сүзләр сөйләп утырма әле, булмаган тозны ничек салыйм мин», – дип кычкырган. «Миндә тоз заводы юк, тапсаң, кибеттән үзең алып кайт!» – дип тә өстәгән.

Дустым сөйләгәннәр шаярту түгел икән. Беткән булган тозлары. Минем хатын язмаларга үзен кыстырганны бер дә яратмый. Шуңа күрә беркөнне аның кибеттән тозсыз кайтуын, аннан соң балкондагы шкафта пандемиядән калган һәм катып беткән бер кап тоз табуын, шуны кочаклап, кухня уртасында вальс әйләнүен язып тормыйм. Шуны гына әйтәсе килә: кайчак күңелсезлекләрне без үзебез китереп чыгарабыз. Җитәкчеләргә дә артык ышанасыбыз килми. Ә менә кибеттәме, урамдамы кемнәндер ишеткән сүз безгә иң дөресе тоела. Һәм шул очраклы ишеткән сүзне җәмәгатьчелек фикере дәрәҗәсенә күтәреп: «Халык шулай ди бит!» – дип, бөтен танышларга, туганнарга сөйләп йөрибез. Бүген барган мәгълүмати сугышка да бераз өлеш кертәбез кебек.

Хәзергә менә шул, җәмәгать. Монысы да тозсыз сүзләр язган, дип мине гаепләмәгез инде, яме! Кайбер күңелләрдәге саботажны бетереп булмасмы дип кенә тырышу иде.

СУМ БЕЛӘН ХИСАПЛАШУ

Чәршәмбе көнне Владимир Путин бөек тарихи «ат йөреше» ясады: «дус булмаган дәүләтләр»гә газ экспортын сумнарга күчерергә әмер бирде. Бер атна эчендә сумнарда газ сәүдәсе көйләнеп, Себер газына бәйле булган илләр «рубль»ләр табарга, Россия банкларында үз хисапларын ачып, безнең кесәләрдә шыгырдаган кәгазьгә зәңгәр ягулык ала башларга тиешләр. Бу карар сумның дәрәҗәсен шунда ук күтәрә, ул гади кәгазьдән резерв валютасына әверелә башлый.

Путин карары киләчәктә башка товарларны да сумнарга алыштыру перспективасын күз алдында тота. Мәгълүмат кырына бу яңалык чыгу белән, биржаларда сумның курсы сизелерлек үсте, вәләкин бераздан яңадан төште. Кремль лидеры атлаган адым Көнбатыш керткән санкцияләр стенасын да ярыйсы гына җимерә. «Әһә, сез безнең банк хисапларын бикләдегезме, моннан соң үзегез безнең банкларда хисап ачасыз да, ачу килсә, без дә сезнекен бикли алабыз», – дигән эчке мәгънә дә табып була ул чишелештән.

Газ сәүдәсе өчен «дус булмаган илләр» сумнарны кайдан алалар? Беренче юл: Мәскәү биржасына киләләр дә доллар һәм евроларны сумнарга алыштыралар. Икенчесе, үз товарларын безгә сумнарга саталар. Боларны уйлаганда, күңел шунда ук күтәрелеп китә инде, чөнки барысы да без сурәтләгәнчә барса, киләчәктә чит илгә чыкканда, валюта алыштырып мәшәкатьләнәсе булмаячак. Барасың да, әйтик, Истанбулга, валюта алыштыра торган тәрәзәгә сумнар сузасың, алар сиңа лира бирәләр. Доллар бөтенләй кирәкми. Евро да. Дубайга килеп төшсәң, сумны дирһәмгә алыштырасың, Җиддәгә төшеп утырсаң, риал табу проблемасы юк.

Гомумән, Россия икътисады өчен зур киләчәк вәгъдә итә бу карар. Башка тагын бик күп плюсларен санарга була даһи ат йөрешенең. Әмма дә ләкин, әйдәгез, күктән җиргә төшәбез дә, иллюзияләрдән арынып, чынбарлыкка башка күзләр белән карый башлыйбыз. Әйтик, Джо Байден күзлеген киябез. Аны киюгә, безнең күңелдә нәфрәт ташый башлый, чөнки Америка валютасын читкә тибәреп, без алар икътисадының артына тибәбез. Американнар туклыгына кылыч күтәрәбез. Синең акчаңны бөтен дөньяда берсүзсез кабул итәләр икән, син бай. Моның белән бәхәсләшми торгансыздыр инде. Кәгазьдән акча басу кыен түгел бит. Аны акча итеп танысу кыен. Америка долларының ничек итеп дөньякүләм валютага әйләнү тарихын белүчеләр аңлый сүзнең нәрсә хакында баруын. Валютасын резерв валютасына әйләндерү өчен, дәүләткә өч нәрсә кирәк: ныклы икътисад, хәрби куәт, сәяси йогынты. Күптән түгел генә АКШта моның өчесе дә артыгы белән бар һәм җитәрлек иде. Кемнәр доллардан баш тарта, америкалылар аларга икътисади басым ясадылар, сәяси йогынтыларын эшкә җигеп, коалицияләр тезеделәр һәм... хәрби һөҗүм оештырдылар. Кайда гына сугыш башламасыннар, алар нефть өчен дә, газ өчен дә түгел, доллар өчен сугышты. Алтын урынына доллар йөргәндә, углеводородларны күпме кирәк, шуның кадәр табып була. Ливиянең фаҗигале лидеры Каддафины хәтерлисездер инде? Алтын акча кертергә азаплану сәбәпле, аны шулай кырыс җәзаладылар. Ә Гыйрак диктаторы Сәддам Хөсәен нефтьне долларга түгел, еврога сатарга теләгән иде...

Бертуктаусыз сугышлар алып бара-бара һәм долларны хөрмәтләмәгән илләргә санкцияләрне чамасыз кертеп, Вашингтон үзен үзе көчсезләндерде. Кайсы гына илләрнең доллардагы хисапларын бикләмәделәр алар... Бу, билгеле, долларга ышанычны киметте, барлык илләрдә дә ризасызлык уятты. «Ни өчен доллар савым сыеры булырга тиеш әле?» дигән сорау күңелләрдә тумый калмый иде. Башта финанс хакимлеген евро белән бүлешергә туры килде. Евроның резерв валютасы дәрәҗәсенә ирешүе Евросоюзга муллык китерде, бомжларга без эшләп тә ала алмый торган күләмдә пособиеләр өләшү дәрәҗәсенә җиттеләр. Ул арада Кытайның икътисади һәм хәрби куәте үсте һәм юань резерв валютасы статусын таләп итә башлады. Соңгы көннәрдә юань инде Согуд нефтен сатып алу дәрәҗәсенә килеп җитте. Кытайны җиңел генә куркытып булмый бит. «Saudi Aramco»ның Кытай белән нефть өчен юаньнарда хисап ясау ихтималлыгы нефть базары өчен чып-чын шартлауга әверeләчәк». Бу – Шанхай университетының халыкара финанслар һәм сәүдә факультеты деканы Чжан Юйгу фикере. Бу хәл бөтен финанс системасына тәэсир итәчәк, дип саный ул. Аның белән килешмичә мөмкин түгел.

Әйдәгез, тагын вазгыятькә Джо Байден күзлегеннән карыйбыз. Дөньякүләм бердәнбер держава дип саналган лидерның бер дә абруен калдырмый бу хәлләр. Барлык янкиларның да кытыгына үтергеч итеп тия. Алар моның белән килешмәячәк. Европа да шулай ук. Чәршәмбе көнне Путин газны сумнарга сату турында игълан иткәндә, Байден Европага килеп төште. Бу юллар язылганда, пәнҗешәмбедә, НАТОның гадәттән тыш саммиты һәм «Зур җиделек»нең ашыгыч очрашуы әзерләнә. Карарлар газета әзерләнеп беткәч кенә чыгачак, шуңа күрә без фаразлап кына язабыз.

Миңа иртүк Европаның Россия газына сумнар белән түләүдән баш тарту өчен уртак килешү әзерләве турында хәбәр килеп ирешә инде. Германиянең кайбер сәясәтчеләре ризалык белдерә сумнар белән түләүгә күчәргә, тик бу – аларның шәхси фикере генә. Ни өчен сумга риза түгел? Сорауның төп җавабын югарыда бирдек шикелле. Без әле монда сумга шикәр сатып алуда кыенлыклар кичерәбез, көнбатышлылар андый волатиль, ягъни курсы һәм кыйммәте уйнап торган акча белән эш итәргә теләмәсләр, билгеле. Икенче төрле әйтсәк, сумның дәрәҗәсен күтәрү өчен, Россиянең икътисади куәте юк. Сәяси йогынтысы да чамалы гына. Хәрби куәттән атом бомбасы бар-барын. Халыкара сәүдәне сумнарга күчерү болай да финанс системасы өстендә атом бомбасы шартлатуга тиң инде ул.

Европадагы ике ашыгыч саммит Украинага хәрби ярдәмне көчәйтү турында сөйләшү максатыннан җыела. Кытайга басым ясау, Согуд принцы Мөхәммәд ибн Сәлманны җәзалау турында да сөйләшми калмаслар. Кытайга арканланып, принц үз язмышын зур куркыныч астына куя. Сүз уңаеннан, әлегә нефтьне юаньнарга сату мәсьәләсе ахырганча хәл ителмәгән. Артка чигенү өчен мәйдан калдырылган. Ә газ белән сумнарда сәүдә итү катгый карар булып яңгырады инде. Тагын бер нәрсәне искә төшерик: 2014 елгы Кырым хәлләреннән соң Болгария һәм Сербия белән Россия арасында газны сумнарга сату ихтималлыгын караган килешүләр төзелде һәм нәкъ менә шул вакыттан башлап НАТО гаскәрләре безнең чикләр буенда интенсив рәвештә туплана инде. Сәүдә барыбер евро һәм долларларда барды дип беләм ул илләр белән дә.

«Дус булмаган дәүләтләр» Мәскәүгә икътисади басымны көчәйтерләр башта. Украинага хәрби ярдәм күрсәтүне арттыру турында да килешерләр. Россия исә Киевка хәрби ярдәм күрсәтүчеләргә һөҗүм белән яный. Бу үзе генә дә зуррак конфликт ихтималлыгын үстерә. Ә инде газ өчен сумнар таләп итү аны тагын арттыра. Бер әметле нәрсә бар-барын. Санкцияләр кертелгәч, Кремль тышкы әҗәтләрне сумнарда түләү белән янады да, беренче түләү датасы килеп җитүгә, өстәлгә долларлар чыгарып салды. Димәк, газ сәүдәсендә дә чигенү ихтималлыгы бар әле. Газга бик мохтаҗ булганлыктан, Европа вакытлыча булса да сумнар белән түләргә риза булыр, бәлки. Бу бик уңышлы сценарий булыр иде. Гадәттән тыш уңышлы хәтта. Әмма АКШ, моңа юл куймас өчен, бар көченә тырышачак. Вазгыять менә шулай катлауланып үсә. Хәл киеренке, сабыр гына чишелешне көтәбез.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

МИКРОГЕНЕРАЦИЯГӘ – ЯШЕЛ ЮЛ

ТАТАРСТАНДА КОЯШ ЭНЕРГИЯСЕННӘН КЕМНӘР ФАЙДАЛАНА?

2021 елның март аеннан Россиядә микрогенерация объектларын технологик тоташтыруны гамәлгә ашыручы өр-яңа закон үз көченә керде. Микрогенерация объекты дигәндә электр энергиясен кояш, җил кебек альтернатив чыганаклардан җитештереп, моны шәхси милек буларак теркәгән һәм электр челтәренә тоташтырган файдаланучылар күздә тотыла. Республикада әлегә андыйлар күп түгел. Нибары 9 хуҗалык.

«Сетевая компания»ның матбугат хезмәте

Кояшлы урамында – кояш электр станциясе

«Яшел энергетика»ны көндәлек тормышта беренчеләрдән булып кулланучылар – Югары Ослан районының Яр буе Морквашы авылында яшәүче Рөстәм Фидаевлар гаиләсе. Аларның хуҗалыгы Татарстанда кояш энергиясен микрогенерация объекты буларак теркәп, электр челтәрләренә беренчеләрдән булып тоташтыра.

Фидаевлар гаиләсе Казаннан авылга 12 ел элек кайтып төпләнә. Рөстәм һәм Елена – икесе дә икътисади белемле, экономиянең ни икәнлеген беләләр. Башлангыч чорда ук үз йортларын иң арзанлы чыганак – электр энергиясе белән җылыталар. Шул чорда ук өстәмә энергия чыганагы буларак кояш энергиясен җитештерүче панельләр куйдыру идеясе белән яна башлыйлар. Ике елдан соң хыял, ниһаять, тормышка аша. Мәйданы 1х2 метр булган 8 кояш панеле гаилә бюджетына 200 мең сумга төшкән.

Ничек туры килгән бит: Фидаевлар хуҗалыгы авылның Кояшлы урамында урнашкан. Гаилә башлыгы Рөстәм Фидаев сүзләренә караганда, кояш станциясе ике ел эчендә инде 4000 кВт электр энергиясе җитештергән. Кояшлы аяз көндә батареялар 10–15 кВт энергия туплый. Бу хәтта кышкы чорда да көндәлек хаҗәтләргә җитә.

Кояш станциясен электр челтәрләренә Фидаевлар узган елның мартында тоташтыра. Нәкъ шушы чорда «Электр энергетикасы турында» федераль законга үзгәрешләр кертелгәч, микрогенерация объектларын технологик тоташтыруга ил күләмендә яшел юл ачыла. Тоташтыру эшләрен «Сетевая компания» оешмасы белгечләре башкара. Гариза тапшырганнан соң, компания интеллектуаль исәпләү приборын да урнаштыра. Сүз уңаеннан, «акыллы счетчик» кояш станциясенең күпме электр энергиясе эшләп чыгаруын автомат рәвештә ачыкларга мөмкинлек бирә.

Альтернатив энергия чыганагы кояшлы көннәрдә генә эшли. Болытлы көннәрдә микрогенерация объекты эшләп чыгарган электр энергиясе җитми һәм хуҗалык аны челтәрдән ала. Әгәр артып китсә, киресенчә, челтәргә бирә. Кояш панеле җыйган ток электр челтәренә никадәрле күбрәк бирелсә, түләү дә шуның кадәрле азрак килә. Бу процессларның барысы да счетчикта язылып барыла.

– Кышын кояшлы көннәр булса, бик шәп. Мондый вакытларда батареялар сәгатенә 10 кВт егәрлектәге энергия бирә. Интеллектуаль счетчик киловаттларны саный да саный. Гомумән безнең автоном станция 15 кВт эшләп чыгарырга сәләтле, ләкин Татарстанда кояш яктысы җитеп бетми. Елына бездә кояшлы көннәр саны 90нан артмый, – ди Рөстәм Фидаев.

Россиядә кояшлы көннәр аз булса да, кояш энергетикасының киләчәге якты, дип ышандыра белгечләр. Әлегә мондый якты киләчәк күбрәк илнең көньяк өлешендә урнашкан җылы регионнарга кагыла. Аның каравы бүген Татарстандагы шәхси йортларда да, дача һәм бакча хуҗалыкларында да кояш панельләрен торган саен ешрак очратырга була. Кояш энергиясе шулай ук светофор, юл камералары һәм урамнарны яктыртуда да кулланыла.

Дөнья статистикасына килгәндә, кояш генерациясе узган ел гына 20 процентка арткан. Сәбәбе нидә? Бердән, мондый чыганак теләсә нинди хуҗалыкны энергия ягыннан бәйсез итә. Икенчедән, микрогенерация объектын урнаштыру электр энергиясе өчен тотылган түләү чыгымнарын янга калдыра. Ә кайбер шартларны үтәгән очракта, хәтта табыш та алырга мөмкинлек бирә. Исәп электр энергиясен алу һәм җибәрүдәге аерма буенча алып барыла. Болар барысы да хуҗаларга «яшел тариф» кулланып, электр энергиясенә тотылган чыгымнарны киметергә булыша.

Дөрес, Рөстәм Фидаев: «Керем турында сөйләргә иртәрәк әле», – ди. Ә менә акча ягыннан кояш батареялары, чыннан да, аны янга калдыра. Кояш панелен урнаштырганнан соң, гаилә электр энергиясенә аена 600 сумга кимрәк түли башлаган.

Рөстәм Фидаев әйтүенчә, кояш станциясе бүген хуҗалыкның көнкүреш ихтыяҗларын капларга җитәрлек энергияне тулы күләмдә бүлеп бирә. Ягъни бу энергия ашарга әзерләргә, суыткыч, телевизор, гаджетлар эшләвен һәм яктылык бирү чыгымнарын капларга җитә.

– Кояш генерациясе – кызыклы тема, тик әлегә Россия өчен бик уңышлы дип әйтеп булмый. Кояшлы илләр өчен күпкә отышлырак, әлбәттә, – ди Рөстәм.

Ә Фидаевларга электр энергиясен күп кулланырга туры килә, чөнки өйдә дүрт яшүсмер бар. Алар компьютер, гаджетларда дәресләр хәзерли, проектлар эшли. Ике ел элек балаларны үз канаты астына сыендырган гаилә алар турында шулкадәр яратып сөйләде. Яшүсмерләрнең иң өлкәненә 15 яшь булса, кечкенәләренә – 11 яшь.

– Искиткеч яхшы балалар, – ди гаилә башлыгы Рөстәм Фидаев дүрт бертуган турында. – Алар булгач, йортыбызга ямь инде, яшәү дәрте артты. Үзебезнекеләр зурлар инде. Үз гаиләләре, балалары бар. Тик ял итәргә чит илләргә йөргәч, җәйләрен бездә сирәк булалар. Хатыным белән уйлаштык та күңел җылысын ятимнәргә бирергә булдык. Аңа кадәр Казанда яшәдек. Янәшәбездә генә балалар йорты урнашкан иде. Шуңа күрә безнең өчен ятимнәрне тәрбиягә алу көтелмәгән, кинәт уйланган карар булмады. Авылга берничә ел элек кенә күченеп кайттык.

Авыл дигәннән, кояш батареялары Фидаевларның авылдашларында да кызыксыну уяткан. Киләләр, сорашалар, дип елмая хуҗа.

Кояш станциясе техник җиһаз буларак ул кадәр игътибар таләп итми. Бары тик нинди ел фасылы булуына карап, аны көньякка каратып, әйләндереп кенә торырга кирәк икән.

Кулланучы өчен белешмә

Микрогенерация объектларын технологик тоташтыру тәртибе



1. Беренчел техник ялгау булырга тиеш (торак йортка техник ялгау акты).
2. Шуннан соң микрогенерациягә техник ялгау акты рәсмиләштерелә (яки берьюлы икесе дә эшләнә).
3. Кулланучы һәм сатучы арасында электр энергиясен сату-алу килешүе төзелә.

Төп шартлар

Закон буенча, микрогенерация объектын электр челтәрләренә физик, юридик затлар һәм эшмәкәрләр тоташтыра ала. Шул ук вакытта аерым бер категория өч елга бер тапкыр гына ташламалы тариф ставкасыннан файдалана ала. Аның күләме – 550 сум. Яңа кагыйдәләр буенча объектны тоташтыру вакыты бер айдан башлана. Микрогенерация объектларын тоташтыруның төп шартлары: энергияне кабул итүче җайланмалар 1000 Вольт көчәнешкә кадәрге электр хуҗалыгы объектларына тоташтырылган булырга тиеш. Электр энергиясен җитештерүче объектның челтәргә энергия бирү күләме бу кулланучының энергия кабул итү җайланмасы егәрлегеннән артып китмичә, 15 кВт тәшкил итә.

Буа электр челтәрләре филиалы директоры Айрат Сәмигуллин әйтүенчә, Фидаевларның станциясе – Буа зонасында беренче микрогенерация объекты.

– Бу – безнең өчен яңалык, – ди филиал директоры. – Кояш батареялары традицион электр энергиясеннән керемне киметә, билгеле. Ләкин безнең компания беренче чиратта клиентларның ихтыяҗларын кайгырта. Кулланучы өчен уңайлы булса, безгә дә яхшы. Электр энергиясенең өстәмә чыганагы булу кулланучының ышанычын арттыра, акчаны янга калдырырга ярдәм итә. Ә гомумән алганда, республика өчен бу – физик һәм юридик затларга өстәмә мөмкинлекләр тудыру дигән сүз. Мәсәлән, электр челтәрләреннән ераграк урыннарда урнашкан төрле төзелеш объектлары (кэмпинг, глэмпинг, шәхси йортлар) өчен яңа мөмкинлекләр ача.

«Яшел энергетика»

Гомумән алганда, «Сетевая компания» экологик кыйммәтләргә, «яшел энергетика»га һәрвакыт өстенлек биреп килә. Аның шул максатларга нигезләнгән берничә юнәлеше бар. Мәсәлән, компания узган елның көзеннән электромобильләр өчен ток бирүче (зарядные) станцияләр урнаштыра башлады. Республиканың төрле районнарында шундый 14 объект барлыкка килде. Алар алмаш токлы – 22 кВт, даими токлы 60 кВт егәрлектәге өч электромобильгә берьюлы заряд бирү мөмкинлегенә ия. Шул ук вакытта моның өчен 90 минутка кадәр вакыт сарыф ителә. Шунысы уңайлы: бу эшне эшләргә аерым хезмәткәр кирәкми, чөнки электромобильләргә заряд бирү процессы смартфоннардагы кушымталар аша башкарыла.

Татарстанда җил генерациясенең дә потенциалы югары. «Сетевая компания» киләчәктә бу өлкәдә дә эшләргә ниятли.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

ЙӘ МИН, ЙӘ АВЫЛ?!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Тормыш аермасы

«Авыл хуҗалыгы продукциясе, яшелчәләр җитештерүдә бу ничек чагылыш табар? Әллә нинди программалар уйлап табарга мөмкин, әмма 4–6 район буш булгач, аларны кем үтәр? Без үзебезне туендыручы җир кешесенә башкача карый башларга тиеш. Әгәр кешенең эше, яшәргә акчасы юк, пенсиясе түбән икән, нәрсә эшләп була?» – диде җан ачысы белән Камияр Байтимеров фермерлар очрашуында. Авылда хәлләр чыннан да шулай мөшкелме? Бу уңайдан «Татарстан муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе Әгъзам Гобәйдуллинның фикерен белештек.

– Урбанизация ул – бүгенге күренеш кенә түгел. 1917 елга кадәр авыл җирендә – 70–75, шәһәрдә 25 процент кеше яшәгән. Хәзер киресенчә. Кеше бит цивилизациягә – кайда яхшы, шунда омтыла. Авылда хәлләр үзгәрми, кешеләр гел шәһәргә китә, дибез. Башка төбәкләр белән чагыштырганда, бездә әлеге процесс әкренрәк бара, – ди ул. – Бүген авылда яшәү шартлары шәһәрнекенә туры килә. 1970 нче елларда авыл белән шәһәр арасында киртәне бетерү дигән шигарь бар иде. Безнең өчен утопия иде ул. Әмма 1990 нчы елларда мөстәкыйльлекне алып, үзебезнең программаларны кабул иткәннән соң, чыннан да, Татарстанда авыл белән шәһәрдә аерма юк, дип әйтә алабыз.

Аның фикеренчә, проблема авылларда эш булмауга бәйле. Бу процессны эре инвесторлар керү, колхозларны бетерү кызулатты. Инвесторлар зур комплексларда эшли башлады. Шуңа күрә терлекләрне карау юкка чыкты. Бүген авыллар бетә дип фаҗига ясарга кирәкми. Перспективалы авылларны карап, күбрәк эш урыннары булдырырга кирәк. Шәһәрләрдәге завод-фабрикаларның авылларда филиаллары булырга тиеш.

– Карагыз, иртә белән Казанга бару юлында никадәр машина. Кайтканда да – бөке. Күбесе эшкә шәһәргә йөри. Монда дәүләт программасы кирәк. Бөтен шартларны үз эченә алган программа әлегә юк. Бүгенге ситуация авылларда эш шартлары булдыруга этәрәчәк. Татарстанда бу процесс бик тиз китәчәк. Әгәр филиаллар, эш урыннары булдырсак, күбесе авылга кайтып эшләр. Минем шигем юк. Күбесенең әти-әнисе нигезе бар, эш булса, анда кайтып өй салачак. Икенче әйбер – яшьләрне калдыру өчен өстәмә кызыксындыру чаралары булдыру. Әйтик, аларга түләүсез җир кишәрлеге, өй төзегәндә ташламалы кредитлар бирү. Бездә бу уңайдан күпмедер эшләнә, әмма әле тагын да яхшыртырга кирәк, – ди Әгъзам Гобәйдуллин.

«Йокламый» торган авыл

Зәй районындагы иң зур авылларның берсе булып саналган Аксарны халык телендә әнә шулай дип йөртәләр. Элек өмә ясап, бер көн эчендә йорт күтәрә торган булган алар. Тырыш, булдыклы халык яши. Ак көнләшү дигән нәрсә каннарына сеңгән. Монда читкә китү турында түгел, йортны яхшыракны салу, капканы матурракны ясау турында уйлыйлар. Аны эшләп бирердәй осталары да бар. Күршеләр дә бер-берсенә якын урнашкан. Зур йортлар салгач, җир буш тормый, шул ягы белән дә аерылып тора Аксар.

– Авылда 800ләп кеше яши, халык саны кимеми. Элек аксарлылар помидор үсентеләре утыртып, күрше Кама Аланы, Әлмәт, Сарман авылларына барып сатканнар. Хәзер мал-туар асрыйлар. Чаллыга, районга барып эшләүчеләр дә бар, – ди Аксар авыл җирлеге башлыгы Юрий Гыйльманов.

Матурлыкны яраталар, шуңа күрә күпләр бакчаларында чәчәкләр үстерә. Үзара салым акчасының да авылны ямьләндерү, төзекләндерүдә файдасы тигән. Акча бирмим, диючеләр юк икән. Ут, су белән барысы да тәртиптә, зират коймалары тотылган. Ике ел рәттән акчаны урамга асфальт җәяргә тоталар, бу эшне киләсе елларда да дәвам иттерәчәкләр. Баганада утлар янып тора, кичен гаиләләре белән урамга ял итәргә чыгалар. Балалар мәйданчыклары бар. 2016 елда спорт ярышларында актив катнашып, спорт комплексы отканнар. Шартлар булгач, авыл кешесе үзен шәһәрнекеннән бер дә ким итеп хис итми. Планнары алга таба да зурдан. Буш җиргә йортлар салып, яшьләрне авылда төпләндерү хакында уйлыйлар. Юрий Гыйльманов әйтүенчә, федераль программага кергән очракта, өйләр саны тагын 20–25кә артачак. Җир сораучылар да шактый икән. Район үзәге дә ерак түгел, 7–8 чакрым ераклыкта гына. Халкына килгәндә, яшьләре дә, 90га җиткән әбиләре дә, 50–60 ел бергә тигез гомер иткән парлылар да бар.

Читкә китәр идеммени?

Зур авыллар кечерәймәсен, бетмәсен өчен нәрсә эшләргә кирәклеген анда яшәүчеләр яхшырак белә. Чирмешән районының Яшәүче авылында бүген 30лап кына йорт бар. Авылында эш булса, зоотехниклыкка укыган Илшат Харисов бер районнан икенчесенә күчеп эшләп йөрмәс иде. Казан ветеринария медицинасы академиясен тәмамлаган егет башта туган авылында ферма мөдире булган. Бүген инде ферма таркалган. Шуңа күрә белгечкә Нурлат районында сөт комбинатын, Чистай районындагы «Чистай» агрофирмасының сөт комплексын җитәкләргә туры килгән. «Бик сирәк җирдә генә 30 яшькә кадәрге сыер савучылар бар иде. Күбесе – пенсия яшендәгеләр», – ди ул. Хәзерге вакытта Казанга фабрикага урнашып йөргән чагы.

– Яшьләр авылда төпләнсен өчен яшьләргә, беренче чиратта, эш кирәк. Икенчесе, мәктәп. Биш авылга бер генә мәктәп калдыру зур хата булды. Гомер буе авыл хуҗалыгында эшләдем. Ирләренә: «Йә мин, йә авыл, әйдә балалар артыннан шәһәргә китәбез», – дип шарт куючы хатыннар да очрый. Әлбәттә, иргә килешергә генә кала. Әти-әниләр балалар рәхәттә яшәсен дип борчыла хәзер. Без авылдан бер пар оекбаш белән чыгып киткән идек. Әзергә бәзер булып яшәмәдек, – ди Илшат Харисов.

Аның әйтүенчә, кайбер хакимият башлыкларына яшьләрнең авылда калуы кирәкми дә. «Килгән җитәкче үз кесәсен калынайта да китеп бара. Шул җирлекнеке булса, андагы халык: «Син үз халкың өчен нәрсә эшләдең?» – дип әйтәчәк. Киткән кешегә сүз әйтеп булмый. Авылыбызда йөрергә мәчет бар әле. Тамырларым авылга береккән, шәһәр – минем өчен бары акча эшләү урыны гына. Авылда әни яши, кайтып хәлен белешеп торабыз. Яшәүчедә рухны сүндермәс өчен бәйрәмнәрне бергәләп уздырабыз», – ди Илшат.

«Кунакка барсак та, кайтасы килә»

Балтач районының Пүскән авылында 63 хуҗалык кына исәпләнсә дә, яшьләренең читкә китмәве белән аерылып тора ул. Бу авылда клуб та, мәктәп тә юк. Шуңа карамастан, шартлар юк дип зарланмыйлар. Быел үзара салым акчасын да 3 мең сумнан җыйганнар. Эшмәкәрләр дә авылны яшәтик дип ярдәм иткән. Яңа урамда гына йортлар саны унга җиткән. Монда барысы да – яшьләр. Һәр гаиләдә – 2–3 бала.

Авылга тугры калган династияләр дә бар. Абыйлы-энеле дүрт бертуган Гарифуллиннар хәзерге вакытта Тимирязев исемендәге хуҗалыкта хезмәт куялар. Иң олысы Фәргать – токарь, Фердинанд – терлекче, Фәнис – шофер, Фәрит күрше авыл клубында сәнгать җитәкчесе булып эшли. Әтиләре Фәхретдин абый гомер буе – комбайнда, Гөлфирә апа терлекче булып эшләгән. Хәзерге вакытта балаларының игелеген күреп яшиләр. Җиргә мәхәббәт әти-әнидән күчкән. Бу нәселдә җырламаган кеше юк, оста биюләр. Фәхретдин ага – авыл имамы.

– Өчебез дә йорт җиткезеп чыктык, энекәшебез төп йортта яши, – ди Фәнис Гарифуллин. – Шәһәргә китү мөмкинлеге дә бар иде, әмма без авылны сайладык. Авылны яратам. Кунакка барсам да, тизрәк өйгә кайтасы килә башлый. Авылның өстенлекләре күп инде аның. Беренчедән, саф һава. Икенчедән, бакчаңда үстергән ризык ашыйсың. Үзең эшләп тапканы тагын да тәмлерәк була. Без тир түгеп яшәргә өйрәнгән. Әтигә ияреп, 12 яшемдә комбайн ярдәмчесе булып эшли башладым. Шуннан бирле колхоздан киткәнем юк. Сәламәтлек кенә булсын. Мөмкинлекләр дә шәһәрчә бит. Шуңа күрә нигә шәһәр тормышына кызыгырга? Эш булсын, ансыз бер көн дә тора алмыйм.

Хатыны Илзия белән алар өч бала үстерәләр. Олы кызлары – шәфкать туташы. Уллары армиядә хезмәт итә. Төпчекләре мәктәптә укый. Алар да җыр-моңга гашыйк. Фәнис «Җырлыйк әле» тапшыруында да җиңеп кайткан. Кызлары Илүзә районда узган «Татар кызы» фестивалендә «Иң сөйкемле кыз» дип табылган. Гаиләләре белән төрле бәйгеләрдә дә катнашалар. «Тик торырга вакыт юк. Әле бу көннәрдә бишенче концертны куеп кайттык», – ди Фәнис.

Үз итү

Соңгы вакытта шәһәрдән авылга кайтып, бакчачылык, терлекчелек белән шөгыльләнүче фермерлар турында ишетеп язып торабыз. Берничә ел элек шәһәрдә яшәүче Җамалетдиновлар Питрәч районының Керәшен Сәрдәсе авылына кайтып төпләнеп, терлекчелек буенча үз эшен булдырган. Гаилә башлыгы Газинур – эретеп ябыштыручы. Бу алар өчен чит авыл булса да, аны инде үз итеп өлгергәннәр. Дүрт бала тәрбиялиләр.

– Күп сөйләшергә яратмыйм, эшләргә яратам. Әле тимер эреткән чагым, – дип, Газинур сүзне кыска тотты. – Кайтканга бер дә үкенмибез, кире китәргә дә җыенмыйбыз. Мал-туар асрыйбыз, сөтен сатабыз. Әкрен генә үз җаебыз белән яшәп ятабыз. Йортны сатып алдык. Авылда күңелсез түгел, Аллага шөкер. Барлык шартлар да бар. Өйгә суы, газы кергән. Балаларга укырга мәктәп бар, – диде Газинур.

Арча районының Ашытбаш авыл җирлеге башлыгы рәисе Фәһим Фәйзуллин үз җирлеге егетләрен мактап телгә алды. Купчелеге мини ферма программасында катнашып, хуҗалыгында 8–10, 12 баш сыер асрый икән. Ел саен 3–4 хуҗалык әлеге программада катнашып, субсидия ала. Сөт тапшырып, кредитын каплый, техникасын сатып ала, йортын төзи. Шәхси хуҗалыкларга сыер башына бирелә торган 3–4 мең сум да авыл халкы өчен зур ярдәм. Атлар, тана, кәҗәләр сатып алырга ярдәм бар.

– Мин яшьләрне тәнкыйтьләмим, алар эшлибез дип тора. Замана акчага корылды. Теләгән кеше шәһәрдә торсын, шул ук вакытта авылда да менә дигән итеп яшәп була. Мәшгульлек үзәге төрле һөнәрләр үзләштерергә чакыра, укыта, акчалата ярдәм күрсәтә. Тик ачуны китергән бер әйбер бар. Интернет, өйдән чыкмыйча, җиңел акча эшләргә өйрәтеп ята, – ди башлык.

Фәһим әфәнде әйткәнчә, элек бөтен авыл халкы күмәк хуҗалыкларда эшләсә, хәзер нибары 10 процентка җитә. Авыл хуҗалыгындагы алдынгы технологияләр, заманча җир эшкәртү агрегатлары эшче көчкә экономия ясый. Монысы – бер. Икенчедән, җиң сызганып эшлим, дигән яшьләргә дә каршылыклар күп. «Инвесторлар килеп керү яңа яшәү форматы булдырды. Аларга авылның социаль сферасы артык чыгым булса, алар бездә эшләми шикеллерәк караш туа. Пай җирләрен алу бик кыен. Чөнки инвесторга азык базасын тоту өчен җир кыйммәт. Әле

Фикер

Айрат ФӘРРАХОВ, Дәүләт Думасы депутаты:

– Авылдан шәһәргә күченү – бик зур проблема. Бөтен ил шундый проблема кичерә. Бу сорау кайбер илләрнең икътисади үсеше белән бәйле. Кытайда авыл җирлегендә эшче куллар бик очсыз, аларга аз түләнә. Шуңа күрә аларның продуктлары юньрәк. Россия, Татарстан өчен дә урбанизация мәсьәләсе искәрмә түгел, зур проблема. Кешеләр уңайлы, бигрәк тә балалар өчен мөмкинлекләр зур булган шартларда яшәргә тырыша. Авыл кешеләренә җитәрлек шартлар тудыра алмаган дәүләтләр бу вазгыятьтә отыра. Авылда милли бергәлек, тел, мәдәният саклана. Татарстанда Президент ярдәме белән авылны үстерү өчен шактый эшләнә, шуңа күрә ил белән чагыштырганда, шәһәргә күченү күрсәткече югары түгел. Шулай да бу безне шатландырмый. Шуңа күрә Дәүләт Думасы «Авылны үстерү» программасын булдырды. Сайлау кампаниясе вакытында авылларга чыкканда, без инде аның нәтиҗәләрен күрдек. Клублар, фельдшерлык-акушерлык пунктлары төзелә. Әмма бу гына җитми, сыйфатлы юллар кирәк. Транспорт челтәре, су программалары, иң мөһиме – яхшы акча түләнә торган эш кирәк. Шул чакта гына яшьләр авылда калачак. Шуның буенча эшлибез.

Таһир ҺАДИЕВ, Татарстан Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе урынбасары:

– Кызганыч, бүген авылның язмышын, аның үткәнен, киләчәген барлау тиешле дәрәҗәдә түгел. Гадәттә, күп сөйләгән әйбер турында аз эшләнә. Россиядә XX гасырда 150 меңнән артык авыл юкка чыккан, Татарстанда – 1200. Бүген дә авылның картаюы дәвам итә. Шуның өчен бу мәсьәлә милләтләр өчен: татар халкы булсынмы, удмурт, чуаш, мордвамы – барысы өчен дә мөһим. Бу очракта милләтнең йөрәк тибеше дә кими дигән сүз. Авыл мәсьәләсен хәл итү өчен ил буенча да стратегик мәсьәләләрне карарга кирәк. Әлбәттә, республикада төрле программалар бар. Әгәр дә аның үтәлеше белән шушы мәсьәләләрне хәл итүнең күләмен чагыштырсак, аерма бик зур. Программа белән хәл ителмәсә, авыл язмышын дәвам иттерү кими. Без бу мәсьәләдә көчебездән килгән кадәр эшләргә тырышабыз. Илнең киләчәге турында уйласак, хөкүмәт авыл турында күбрәк кайгыртырга тиеш. Эш урыннарын, кешенең мәнфәгатьләрен өйрәнү кирәк. Әгәр табиб диагнозны дөрес куймаса, авыруны беркайчан да дәвалый алмый. Яңа хезмәт урыннары булдырганда, югары хезмәт хакы түләгәндә, яшьләргә бала тәрбияләү, ял итү өчен шартлар тудырганда, авылда яшәү нәтиҗәләре бермә-бер артачак.

моңарчы пай җире алганнарның чүп үлән үстергәне юк, – ди ул. – Авылга ярдәм итәрдәй кешеләр булганда, авыл беркайчан да таркалмый. Буш нигезләр дә бетәчәк. Авылдан киткәннәр яхшы фатирларын балаларына, оныкларына калдырып, кире кайтачак. Шәһәрдә туып-үскәннәр дә тартылачак. Тора-бара авылларда үз эшләрен булдыручылар кибет ачкан шикелле (кибеттә пешкән хәләл ризык күп сатыла) кафелар ачып, әби-бабайлар кичке ашны кафеда ашап, ял итеп, аралашып, кайтып китәрләр дип күз алдына китерәм. Авыл җыеннарында миллилекне беренче урында тоту кирәк.

Җир туендыра

Бүгенге вазгыятьтә, кибеттә бәяләр артканда, авыл халкы башкачарак уйлый башлады түгелме? Бәрәңге кишәрлекләрен арттырырга кирәк дигән сүзләр дә ишетелә. Бәлкем, шәһәргә күченеп китүчеләр дә авылдагы буш бакчаларында алабута үстерми башлар. Бу уңайдан халык язучысы Фоат Садриев та, авылда үзгәрешләр булачак, тик шәһәрдән кайтып эшләүчеләре бер процент чамасы гына булыр, дип фаразлый. Яшьләр булган бәхетле авыллар күп түгел, алар шәһәр яны кардәйлар, ди.

– Бакча башында берәүнең буш җире бар. Быел үзем утыртмыйм, теләсәгез, утыртыгыз, ди. Авыл эчендә җирләргә игътибар артачак. Мондый хәлдә, башка әйбер сатып ала алмасаң, яшәргә кирәк бит. Әгәр җире бар икән, аны утырту ягын караячак. Күп кешеләр хәзер бакчасының яртысына печән чәчә. Ул әйберләр дә кимер дип уйлыйм. Берәр бозау алса, аңа чөгендер, бәрәңге утыртачак. Шундый үзгәреш булыр, – ди Фоат ага.

Язучы, авылда кискен борылыш булсын өчен, яхшы хезмәт хакы кирәк дип саный. Аның фикеренчә, һәр авылны саклап булмаячак. Зурракларында җитештерү объектлары ачарга кирәк. «Совет чорында ике теплица тотып, районны кыяр-помидор белән тәэмин иткән егетләр бар иде. Хәзер эссе теплицада тиргә батып, кем эшләргә риза? Эшләтәм дисәң дә, 30–50 мең сум түләргә кирәк. 50 мең сум түләсәләр, кеше Казаннан да җир казырга килергә мөмкин. Миңа – 81 яшь, үз көчемә җитәрдәй эш булса, барыр идем. Акчасын түләгәндә, гөрләтеп эшләрләр, шәһәргә дә акча эзләп китмәсләр. Дәүләт барысын да уйлап эшләсен иде», – ди Фоат Садриев.

Сәрия МИФТАХОВА

Дару җитәчәк

Даруга кытлык булмаячак! Россиягә карата кертелгән чикләүләр даруларга кагылмый. Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Фәридә Яркәева бу хакта журналистлар белән очрашуда сөйләде.

«Дарулар җитештерә торган бер чит ил оешмасы да санкцияләр аркасында Россия базарыннан китмәде. Аларның күпчелеге иң кирәкле саналган препаратлар белән җитәрлек күләмдә тәэмин итәбез дип әйттеләр», – дип тынычландырды министр урынбасары.

Фәридә Яркәева сүзләренә караганда, бүген республиканың дәүләт даруханә складында Татарстанның дәвалау оешмаларын тәэмин итәрлек 3,5 миллиард сумлык дару саклана. «Моннан тыш аларның һәркайсында 1–2 айга җитәрлек дару запасы бар. Ташламалы программаларга килгәндә, әлеге тармакка билгеләнгән дарулар 3–5 айга җитәрлек», – ди ул.

Татарстанга 6,5 миллиард сумга төзелгән 2,5 мең дәүләт контрактының яртысыннан артыгы буенча дарулар кайтарылган инде. Хәзерге вакытта республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгы агымдагы елның икенче яртыеллыгына дару алу белән мәшгуль. «Даруханәдәге препаратларның җиту-җитмәве һәрчак контрольдә. Монополиягә каршы федераль хезмәт һәм Росздравнадзор идарәләре аларга бәяләрне тәүлек әйләнәсе күзәтеп тора», – ди Фәридә Яркәева.

Даруханәдә нинди дә дару табa алмасаң да борчылырга кирәкми. Ул булмаса, аның үзебездә җитештерелгән аналогы бар. Дөрес, бүген күпләр Россиядә җитештерелгән даруларга сагаеп карый. Аларның файдасы юк, булса да, аз дигәнрәк фикер яши. Фәридә Яркәева бу мәсьәләгә дә ачыклык кертте. «Бөтен илләр дару җитештерү өчен кирәкле чималны Кытай белән Һиндстаннан ала. Шуңа күрә даруларны барыбыз да бер үк төрле җитештерә», – диде белгеч.

Инсулинсыз калмаммы дип борчылучыларны да тынычландырырга ашыкты ул. Соңгы арада, шикәр комы кебек, аны да күпләп запаска алып куючылар булды. «Инсулинга кытлык булмаячак. Якын арада Татарстанга тагын 5 айга җитәрлек инсулин кайтыр дип көтелә. Аны күпләп алып куюдан файда юк. Күпләр инсулинны суыткыч ишегендә саклый. Ләкин аны суыткычның үзендә сакларга кирәк. Әмма ничек кенә дөрес сакласаң да, аның да яраклылык вакыты бар», – ди Фәридә Яркәева.

Белгеч сүзләренә караганда, дөрес сакламаган очракта, яраклылык вакыты чыкмаган даруның да шифасы тимәскә мөмкин. «Аш бүлмәсендә температура тотрыклы түгел. Шуңа күрә анда даруларны, гомумән, сакларга ярамый. Аларны тәрәзә төбендә, кояш төшә торган ачык урыннарда да тотмау хәерле. Дөрес сакламаган очракта аларның файдасы калмый. Юкка гына даруханәләрдә һәр дару аерым шартларда сакланмый бит инде», – ди Фәридә Яркәева.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЯРЛАРЫННАН ЧЫКСА ЕЛГА...

РАЙОННАР ТАШУГА ӘЗЕРМЕ?

Быел Татарстанда 200 торак пунктка су басу куркынычы яный. Игътибар бирелергә тиешле корылмалар исемлегендә 20гә якын күпер, социаль һәм икътисад объектлары бар. Алдан чарасын күрү турында Хөкүмәт йортында узган очрашуда сөйләштеләр. Биредә гадәттән тыш хәлләргә каршы тору һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия утырышы узды.

Февраль азагында республикада кар катламы соңгы елларның уртача күрсәткеченнән күпкә биегрәк булган. Шуңа быел хәлләр катлаулырак булырга мөмкин. Премьер-министр урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин районнарга бүгеннән үк әзер торырга киңәш итте.

– Су баса башласа, гадәттән тыш хәл режимына күчү кирәк, – диде ул. – Узган ел республикада 20 районда су басу күзәтелде. 206 йорт яны территориясе, 540 бакча участогы, 9 күпер, 8 автомобиль юлы зыян күрде. Ул чакта без гидротехник корылмаларның торышы канәгатьләнерлек булмавын, ярларны ныгыту, тирәнлекне арттыру, елга үзәннәрен чистарту буенча чаралар күрергә кирәклеген ачыкладык. Быел бу эшләр җиренә җиткереп башкарылырга тиеш.

Татарстан гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары Николай Суржко сүзләренә караганда, күп кенә урыннарда әзерлек тәмамланган инде. Әмма хәл ителмәгән мәсьәләләр дә шактый. Әйтик, Кайбыч, Чирмешән, Биектау районнарында су астында калу куркынычы янаган күперләр бар. Аларны тәзекләндерергә кирәк.

– Узган ел гидротехник корылмалар тәзекләндерелде, елгалар чистартылды, су торбалары яңартылды. Барлыгы 726 миллион сум акча тотылды, – ди Николай Суржко. – Быел Гөбенә, Карлы, Кече Чирмешән елгаларында су биеклеге күпьеллык уртача күрсәткечтән югарырак. Язгы ташу башланганчы карны чыгарып бетерергә кирәк. Кече елгаларда кар тыгылу да ташуга китерә. Боз да тыгыла. Республика сулыкларында боз тыгылу куркынычы булган барлыгы 63 участок бар. Әнә шуңа да бозны кисә башларга вакыт. Күперләр янәшәсендә боз тыгылса, су басуны көт тә тор.

Рөстәм Нигъмәтуллин, су басу аркасында юлсыз калган, шул сәбәпле район үзәгенә бару мөмкинлеге булмаган кешеләргә аеруча игътибар бирергә кушты. Әйтик, табиблар барып җитә алырлык булсын. Юлы өзелгән авылларны коткаручылар да контрольдә тотачак. Районнардагы гадәттән тыш хәлләргә каршы тору буенча комиссия вәкилләренә дә җиһазларын хәзердән үк сызганып күярга кушылды.

Су басу куркынычы булган дүрт район утырышта хисап та тотты. Кайбыч районында 10 авылны су басарга мөмкин икән. Хәтта бер авылда чиркәү, мәдәният йорты, кибеттә су керү ихтималы зур. Әзерлек башланган инде. Кирәк була калса, халыкны күчерү, малларны урнаштырып тору өчен урыннар билгеләнгән. Сарман районында бозлар ватылган, күперләр чистартылган. Сарман җитәкчеләре яхшыга өметләнә. Чирмешәндә 2 буа күтәрелергә мөмкин. Ташу ел саен ике күперне алып китә икән. Алар да алдан хәстәрен күргәне. Ә менә Биектау районындагы ташуга әзерлекне белә алмадык. Җирле гадәттән тыш хәлләр комиссиясе рәисе Дамир Шәйдуллинның микрофоны эшләмәде. Аңа ике тапкыр сүз биреп карадылар, тик тавыш кына ишетелмәде.

– Язгы ташу вакытында шундый хәлгә калмагыз инде, – диде Рөстәм Нигъмәтуллин.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча идарәсе башлыгы Рафис Хәбибуллин әйтүенчә, язгы ташуга әзерлек күздән үк башлана.

– Җибәрелмәгән буалар ташу вакытында күтәрелә. Шуңа да авыллардагы буаларны йә авыл хуҗалыгы өчен, йә янгынга каршы кулланырга кирәк. Тик ята икән, аларны агызу хәерлерәк, – ди ул. – Су басу әлек тә бар иде ул. Кемнендер килеп ярдәм иткәнен көтмәдек. Коткаручылар әзер, әмма халык та үзүзен кайгыртсын иде. Форсаттан файдаланып шуны да әйтәм: бозга керә күрмәгез. Аеруча балыкчылар сак булсын. Алар безгә ышанган, коткарырсыз әле, дип утыралар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

Су баса калса, Татарстанда 42 меңгә якын кешегә 158 вакытлыча тору урыны әзерләнгән. Гадәттән тыш хәлләргә каршы тору өчен 17 мең кеше, 2,5 мең берәмлек техника тупланган.

28 март | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР» 6+
10.00, 23.30 «БЕСЦЕННАЯ ЛЮБОВЬ» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.20 «Каравай». Наследие древнего искусства 6+
00.45 «Соотечественники» 12+
01.05 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
04.15 «Башваткыч» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.25 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 «ЯНЫЧАР» (S) 16+
22.55 «Большая игра» 16+
23.55 Док. расследование Михаила Леонтьева «Большая игра». Фильм 5-й 18+
00.55 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.00 Вести
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.00 Вести
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
20.00 Вести
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «СОФИЯ» 16+
02.00 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
03.30 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.35, 15.10, 17.55 Новости
06.05, 21.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 12.40 Специальный репортаж 12+
09.25 Смешанные единоборства. UFC. Кертис Блейдс против Криса Дакаса. Трансляция из США 16+
10.30 «Ж.К.В.Д.» 16+
13.00 Тайский бокс. Чемпионат России. Трансляция из Улан-Удэ 16+
14.10 «Есть тема!» Прямой эфир
15.15 «Человек, который изменил всё» 16+
18.00 «Громко» Прямой эфир.
19.00 Хоккей. КХЛ. 1/2 финала конференции. Прямая трансляция
22.30 Тотальный футбол 12+
23.00 «МОЛОТ» 16+
01.15 «Есть тема!» 12+
01.40 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – «Нижний Новгород» 0+
03.25 Новости 0+
03.30 «Всё о главном» 12+
03.55 «Наши иностранцы» 12+
04.20 «Виктор Царёв. Капитан великой команды». Док. фильм 12+
05.10 «Громко» 12+

НТВ

04.50 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «АНОНИМНЫЙ ДЕТЕКТИВ» (S) 16+
23.45 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
03.35 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «С ВОЛКАМИ ЖИТЬ…» 16+
06.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Двойник» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.45 «ПИСЬМО НАДЕЖДЫ» 16+
19.00 «МОЖЕШЬ МНЕ ВЕРИТЬ» 16+
23.05 «ДЫШИ СО МНОЙ» 16+
02.05 «Чудеса» 16+
03.00 «ПРОВОДНИЦА» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «ЗЕМЛЯК» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 22.15 Новости дня 16+
09.15 «РАЗНЫЕ СУДЬБЫ» 12+
11.20 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25, 14.05 «КУЛИНАР» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
19.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
20.40 «Война миров» 16+
21.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Наши разведчики в атомном аду». Премьера! 12+
22.30 «Между тем» 12+
22.55 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах № 96». Премьера! 16+
23.45 «ЗАКОН И ПОРЯДОК. ОТДЕЛ ОПЕРАТИВНЫХ РАССЛЕДОВАНИЙ»-3 16+
01.30 «СЛУЧАЙ В ТАЙГЕ» 12+
03.00 «Калашников». Док. фильм 12+
03.30 «КУЛИНАР» 16+

29 март | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР» 6+
10.00, 23.00 «БЕСЦЕННАЯ ЛЮБОВЬ» 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Бехтерев. Координаты души 12+
00.40 «Tatarstan Today. Открытый миру» 12+
01.05 «Реквизиты былой суеты» 12+
01.35 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә»(субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.25 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. «ЯНЫЧАР». Многосерийный фильм (S) 16+
22.55 «Большая игра» 16+
23.55 Документальное расследование Михаила Леонтьева «Большая игра». Фильм 6-й 18+
00.55 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.00 Вести
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.00 Вести
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
20.00 Вести
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
03.30 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 17.55 Новости
06.05, 20.50, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 02.05 Специальный репортаж 12+
09.25 Профессиональный бокс. Лучшие бои Дениса Лебедева 16+
10.25 На лыжи с Еленой Вяльбе 12+
10.45 Лыжные гонки. Чемпионат России. Женщины. 10 км. Прямая трансляция из Сыктывкара.
12.10 Лыжные гонки. Чемпионат России. Мужчины. 15 км. Прямая трансляция из Сыктывкара.
14.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.55 Волейбол. Чемпионат России «Суперлига Paribet». Мужчины. «Локомотив» (Новосибирск) – «Енисей» (Красноярск). Прямая трансляция
16.55, 18.00 «ТРЕТИЙ ПОЕДИНОК» 16+
21.35 Футбол. Чемпионат мира-2022. Отборочный турнир. Финал. Прямая трансляция
00.30 «Есть тема!» 12+
00.55 «Манчестер Юнайтед. Путь к славе». Док. фильм 12+
02.25 Футбол. Чемпионат мира-2022. Отборочный турнир. Чили – Уругвай. Прямая трансляция
04.30 Волейбол. Чемпионат России «Суперлига Paribet». Женщины. «Заречье-Одинцово» (Московская область) – «Уралочка-НТМК» (Свердловская область) 0+

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «АНОНИМНЫЙ ДЕТЕКТИВ» (S) 16+
23.45 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
03.40 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Новый жилец» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «НАСТУПИТ РАССВЕТ» 16+
19.00 «ДВОЕ НАД ПРОПАСТЬЮ» 16+
23.15 «ДЫШИ СО МНОЙ» 16+
02.15 «ПРОВОДНИЦА» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «КУЛИНАР» 16+
07.00 «Сегодня утром». 12+
09.00, 13.00, 18.00, 22.15 Новости дня 16+
09.15, 18.45 «Специальный репортаж» 16+
09.35 «ОПЕКУН» 12+
11.20 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 12+
13.25, 14.05 «КУЛИНАР» 16+
14.00 Военные новости 16+
19.00 «Открытый эфир» 12+
20.40 «Война миров». Док. сериал. «Сталин против Гитлера» 16+
21.25 «Улика из прошлого» 16+
22.30 «Между тем» 12+
22.55 «Легенды армии». Пётр Орехов. Премьера! 12+
23.45 «ЗАКОН И ПОРЯДОК. ОТДЕЛ ОПЕРАТИВНЫХ РАССЛЕДОВАНИЙ»-3 16+
01.30 «ОНА ВАС ЛЮБИТ» 12+
02.50 «Афганский дракон» 12+
03.20 «Оружие Победы» 12+
03.30 «КУЛИНАР» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 28 МАРТ – 3 АПРЕЛЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)

Бу атнада йорт җиһазы яки башка зур әйбер алу киңәш ителми: акчасын түләгәннән соң өйгә китереп бирүләрен озак көтәргә туры килер. Эштә үзгәрешләр булырга мөмкин. Ләкин куркасы юк: аларның сезгә зыяны тимәячәк.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)

Элеккеге эшләрегезгә вакыт-вакыт кире кайткалап алырга туры килер. Иң элек тизлекне түгел, ә сыйфатны кайгыртырга кирәк булыр. Атна уртасында үзегезне күптәннән борчып килгән бер матди мәсьәлә искиткеч дәрәҗәдә уңышлы хәл ителер.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)

Бурычны түләргәме, әллә инде үзегезгә бик кирәкле бер әйбер сатып алыргамы? Бу атнада әнә шул икенең берсен сайларга кирәк булачак. Атна урталарында сөенечле яңалыклар ишетеләчәк.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)

Телефон аша шалтыратып яки язып, зарыгып көтелгән бер хәбәр ирештерерләр. Шәхси тормышта да, эштә дә – бары тик уңышлар. Атна ахырында кечкенә генә бер хата нерв күзәнәкләренә тиеп алыр.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)

Чираттагы ял турында уйлау өчен әйбәт кенә форсат килеп чыгар. Торак мәсьәләсен хәл итүнең дә очы күренә башлар. Тик менә артык күп сөйли башлавыгыз гына... Алдан кычкырган күке турында гыйбарә ишеткәнегез юктыр, ахры?..

КЫЗ (24.08 – 22.09)

Кайнап торган көч-куәт юлыгызда калкып чыккан теләсә кайсы киртә-чикләүләрне эһ иткәнче алып ташлау мөмкинлеге бирер. Аннан килеп, дусларыгыз да ярдәм кулы сузарга гына торыр. Атна ахырында хезмәттәшләрегез арасында абруегызны үстереп җибәрердәй хәлләр килеп чыгар.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)

Эштә күл кушырып утырырга туры килмәячәк. Җитәкчегезнең мактау сүзләреннән үзегезгә гүя канатлар үсеп чыгачак. Тик менә өйдә генә бераз ыгы-зыгы булып алырга мөмкин. Көнчелек аркасында...

ЧАЯН (24.10 – 22.11)

Бу чор, һич көтелмәгәнчә, искиткечле мөмкинлекләр алып килер. Шулай итеп, тормышыгызда ап-ак полоса ачылып китәр. Өйдә – тулы тынычлык, эштә – моңарчы күрелмәгән уңышлар!

УКЧЫ (23.11 – 21.12)

Акыл көченә таянып эшләүчеләр хезмәтләрен җиңеләйтердәй шәп яңалыклар ишетер. Соңгы араларда такыраебрак калган кесәгә әйбәт кенә акча керер. Өстәвенә әле туганыгыз да шәп бер хәбәр белән куандырыр.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)

Максатка омтылышлы, үҗәт булуыгыз күптәннән борчып килгән бик катлаулы эшегезгә, ниһаять, бик әйбәт нокта кую мөмкинлеге бирер. Җитәкчегезгә гозерегез булса, озакка сузмыйча, рәхим итегез. Сезне бер сүздән аңлаячак ул.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)

Хезмәттәшләрегез арасыннан берәү кайбер нәрсәләргә күзләрегезне ачар. Бу хәл нык кына уйланурга этәрер. Нәтиҗәдә үзегез өчен дөрес карарга килеп, эшегез һәм тормышыгызга яңа сулыш өрүгә ирешерсез.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)

Эш-мәшәкатьләрегез артыр. Әмма кулдан килмәгәнгә тотына күрмәгез: авыр хәлдә калуыгыз бар. Намуслы, керсез булуыгызның куелган максатларга ирешүдә искиткеч зур ярдәме тияр.

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Галимзяновым Ф.М., являющимся членом саморегулируемой организации «Ассоциация кадастровых инженеров Поволжья» (уникальный реестровый номер 1413, номер в реестровой записи 30841 от 16.12.2016 г., 420101, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, sinaf@mail.ru, (843) 514-63-63, № квалификационного аттестата 16-14-697 от 20.05.2014 г., СНИЛС 106-073-122 06), в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:16:082602:284, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, некоммерческое садоводческое товарищество «Сирень ГИПО», участок 284 проводятся работы по уточнению местоположения границы и (или) площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Гилязутдинова Былбыл-инас Мухарлямовна (Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 89030618183).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 28 апреля 2022 г. в 10 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.

Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельного участка на местности принимаются с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63 с 28.03.2022 г. по 28.04.2022 г.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ земельных участков, расположенных по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, некоммерческое садоводческое товарищество «Сирень ГИПО», участок 285 и участок 305.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, нотариально заверенную доверенность на предоставление интересов юр. лица, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 года N 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

ТУФРАК ТА – ДОШМАН

Җир шарында яшәүчеләрнең 20 процентка якыны аллергиядән интегә. Шуларның яртысыннан артыгы сезонлы аллергиядән җәфалана, ди Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы белгечләре. Бу мәкерле чирне алдан кисәтеп буламы? Аллергиядән интеккән кеше ниләр белеп торырга тиеш?

КФУ Университет клиникасының табиб-аллергологы Алия КЛЮЧАРОВА белән шул хакта сөйләштек.

:: Алия Рафаиловна, аллергия диган афәттән интегүчеләр саны елдан-ел арта бара. Бу ни сәбәпле шулай икән?

– Аллергия нәселдән килүче авырулар рәтенә керә. Шуңа күрә ата-анасы шуннан интеккән балада аллергия килеп чыгу ихтималы 60 процент тәшкил итә. Шул сәбәпле әлеге чирдән интегүчеләр саны елдан-ел арта бара. Сезонлы аллергия вакытындагы билгеләргә килгәндә, монда күп нәрсә теге яки бу үсемлекнең климаттагы үзгәрешләрне ничек кичерүе, чәчәк ату чорының күпме дәвам итүенә, һавага никадәр серкә бүленеп чыгуга бәйле. Әйтик, яз озын килгәндә агачларның яфрак яру чоры апрель уртасыннан май азагына кадәр дәвам итә. Бу очракта үсемлек серкәсенә аллергиясе булган кешеләр дә озаграк интегәчәк. Яз эшне тиз тотса, ул ике атна эчендә дә тәмамланырга мөмкин.

:: Аллергия нинди билгеләр белән уза?

– Әйткәнемчә, аллергия – нәселдән күчә торган авыру. Әмма һәр гаилә әгъзасы аны төрлечә кичерергә мөмкин. Әйтик, берсе аны җиңелчә үткәрсә, икенчеләрендә ул поллиноз, атопик дерматит рәвешендә уза ала. Бу очракта иң элек кешенең нәкъ менә нәрсәгә аллергиясе барлыгын ачыкларга кирәк. Әгәр кеше теге яки бу әйбергә карата организмда даими рәвештә реакция барлыгын сизсә, ул сезон саен кабатланып торса, кичекмәстән, аллерголог-иммунологка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Уч төбе кычыту да аллергия турында кисәтә аламы?

– Тән тиресе кычытуга тулы бер төркем авырулар сәбәпче була ала. Алар арасында аллергиянең атопик дерматит, контактлы аллергия дерматиты кебек төрләре дә бар. Шикәр чире, гепатит кебек хроник авырулар вакытында да тән тиресе кычыта ала. Шуңа күрә андый билге күзәтелгәндә, үзлегеңнән генә дәваланырга ярамый, белгечкә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Аллергиядән интеккән кеше коронавируска тизрәк бирешә, диюләре дөресме?

– Аллергик ринит һәм атопик бронхиаль астмадан интеккән кешедә коронавирустан соң өзлегүләр сирәк күзәтелә. Әмма коронавирус белән авырганнан соң аллергия баш калкытырга мөмкин. Атопик дерматиттан интеккән кешеләрдә бу аеруча еш күзәтелә. Андый чакта тән тиресе корый, чирдән саклану өчен даими рәвештә антисептик кулланган, кулларны гел юып торган очракта тән тиресе тагын да начарлана.

:: Аллергия вакытында нинди ризыклардан баш тарту хәерле?

– Иң беренче чиратта рационнан аллергия китереп чыгарган продуктларны алырга кирәк. Чәчәк серкәсенә аллергиясе булган кешегә бу чорда үлән чәйләре, бал, чикләвек, алма, цитруслардан һ.б. баш тартырга кирәк. Аларда серкә составындагы аллергеннар бар. Бу чорда составында гистамин, буягыч, стабилизатор, консервантлар булган ризыкларны да (кондитер ризыклары, казылык, консервланган продуктлар, цитруслар, җиләк, помидор, шоколад, какао, кәһвә) чама белән генә кулланырга кирәк.

:: Барлык төр хайваннар да аллергия китереп чыгара ала, дигән фикер дөреслеккә туры киләме? Гөл төбендәге балчык, юыну бүлмәсендәге дымлылык аллергиягә сәбәпче була аламы?

– Әйе, барлык төр хайваннар да аллергия китереп чыгара ала. Кешедә аларның йонына гына түгел, селәгәй, сидек, кавыгына да аллергия башланырга мөмкин. Кайчак безгә, өендә йорт хайваны булмаса да, аллергиядән зарланып мөрәҗәгать итәләр. Аларда ул, гадәттә, йортында эт, мәче асраучылар белән аралашканнан соң башлана. Дымлы бүлмә, ванна, подвалладагы кебек үк гөл туфрагында да күпсанлы гөмбәчекләр бар. Мондый гөмбәчекләргә аллергиясе булган кешеләргә бүлмәләрне һәрчак җыештырып, тузан сөртеп, суыткычны бозылган азык-төлектән вакытында чистартып торырга кирәк. Аллергиянең бу төреннән интегүчеләргә куас, кефир, сыра кебек әче ризыклар, күгәрекле сырдан баш тарту хәерле.

pixabay.com

АЛЛЕРГИЯНЕ КИСӘТҮ ӨЧЕН

- Иң беренче чиратта көз ахыры – кыш башында аллергологка барып, махсус тикшерену узарга кирәк. Кешенең конкрет нинди әйбергә аллергиясе барлыгын ачыклап, махсус дәвалану (АЗИТ терапия) билгеләячәкләр. Моны үсемлекләр чәчәк атарга 3–4 ай кала эшләргә кирәк. Бу очракта кеше аллергия баш калкыткан чорны җиңелрәк уздырачак.
- Мөмкинлек булса, үсемлекләр чәчәк аткан, аллергия котырынган чорда башка илгә, төбәккә күченеп тору хәерле. Иң мөһиме – анда кешедә аллергия китереп чыгаручы үсемлекләр булмасын.
- Үсемлекләр күпләп тупланган җирләрдән (урман, кыр, авыл, бакча) ераграк тору хәерле.
- Урамнан кергәч, душ керергә, күз, борын, авызны яхшылап юып, чиста кием киярга кирәк.
- Урамга чыкканда битлек, кояштан саклаучы күзлек кию дә комачауламас.
- Бүлмәләрне даими рәвештә җилләтеп, тузан сөртеп, җыештырып торырга да онытмагыз.
- Бал, балавыз, исерткеч эчемлекләрдән, үлән чәйләреннән баш тарту хәерле. Үләннәрдән ясалган косметик чаралар да кулланырга киңәш ителми.
- Чәчәкләр серкәләнү чоры башланырга ике атна кала табиб-аллергологка мөрәҗәгать итегез. Ул билгеләгән дәвалау курсы аллергия чорын җиңелрәк уздырырга ярдәм итәчәк.

Белеп тор!

Кәһвә йөрәккә бәрә

Көн саен күп күләмдә кәһвә эчү йөрәк-кан тамырлары системасына бәйле проблемаларга һәм йөрәк мускулары талчыгуына китерергә мөмкин, ди табиб-терапевт Надежда Чернышова. «Кәһвәне чамадан тыш күп эчкән очракта йөрәк мускулы кирәгеннән артык эшли, йөрәк кыскарулары тизләнә. Боларның барысы да йөрәк мускулы талчыгуына һәм йөрәк-кан тамырлары авырулары барлыкка килүгә сәбәпче булырга мөмкин», – дип кисәтә табиб. Моннан тыш даими рәвештә кәһвә эчкән кеше ярсучанга әйләнә, пошаманга төшә, йокы режимы бозыла. Аларның барысы да нерв системасын артык стимуллаштыру нәтиҗәсендә килеп чыга. Чернышова фикеренчә, бу эчемлек организмнан калий һәм башка микро- һәм макроэлементларны чыгара, шуңа күрә аларны тулыландырып торырга кирәк.

Күңелең төшсә әгәр...

➤Депрессиядән коткаручы төнәтмә өчен 500 г сельдерей тамыры, 50 г керән тамыры, 1 лимон, 50 г сарымсак белән 50 г бал кирәк булачак. Сельдерей, керән, сарымсак һәм лимонны иттарткыч аша чыгарып, шушы катнашмага бал өстәгез. Аннары банкага тутырып, бер атна төнәтегез. Аны көнгә бер чәй кашыгы күләмендә ач карынга эчәргә кирәк. Төнәтмәне суыткычта саклыйсы.

➤Күңел төшенкелеге белән йокысызлыктан интегүчеләргә түбәндәге исулның да ярдәме тими калмас. Бер стакан кайнап торган суга 1 аш кашыгы вакланган бөтнек яфрагы салып, ун минут кайнатырга кирәк. Аны көн саен иртә-кич ярты стакан күләмендә эчсәгез, хәлегезнең яхшырганын сизәрсез.

➤Күңел төшенкелегеннән үлән чәйләре дә коткара. Сары мәтрүшкә, песи үләне тамыры, пустырник һәм мелисса салып кайнатылган чәй тынычланырга, йокыны җайга салырга ярдәм итә.

➤Эфир майларының хуш исе дә кәефне күтәрергә сәләтле. Шуңа күрә йортыгызда бөтнек, грейпфрут, розмарин исе аңкып торса, күңел төшенкелегенә бирешмәссез.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ҖЫЙДЫМ ЯРМА, ШИКӘР... НИЧӘ ЕЛГА ҖИТӘР?

Халык он, тоз, токмач, ярма, шикәр ише ризыкны күпләп җыйды һәм җыя. Шкафлар гына түгел, балкон-чоланнарда да урын юк инде, диючеләр дә бар. Запаска җыю – бер хәл, капчык-капчык шикәр, он, ярманы саклыйсы да бар бит. Оны көяли, ярмасы күгәрә, кортлый, тозы яки шикәре катып китә. Аларның һәркайсының саклау шартлары һәм вакыты бар бит. Бүген аларны саклау турында сөйлибез.

Вакытына кара

Иң элек продуктның саклау вакытына тукталып үтик. Ярманы саклау вакыты – 4 айдан 24 айга кадәр. Шул ук вакытта ризыктагы өстәмәләр моны нык киметә. Мәсәлән, йөземле яки башка төрле кипкән җимешле, чикләвекле геркулес 6 айдан ук бозыла башларга мөмкин. Тиз пешә торган ярмаларны да 6–12 ай чамасы гына сакларга була.

Шикәр комы һәм тозның да саклау срогы бар. Әйтик, шикәр жылы складларда гына озак – 8 елга кадәр сакланырга мөмкин. Ә җылытылмаган урыннарда – чоланда яки балконда аны 4 елдан артык тотып булмый. Табиблар кисәтүенчә, капчыгы белән шикәр комы алып кую аны артык күп кулланугa китерүе бар. Кеше көн дәвамында шикәр куллануны 30 граммнан арттырмаска тиеш.

Тозны саклау вакыты исә шикәрнекеннән бик күпкә ким – нибары 12 ай. Гәрчә аны гомер буе сакларга мөмкин кебек тоелса да. Әйе, ул үз чыганагында миллионнарча ел бозылмыйча ятарга мөмкин. Тик тоз сәнәгатьтә эшкәртелә: йодка, макро- һәм микроэлементларга баетыла. Шул сәбәпле билгеле бер вакыттан соң ул яраксызга әйләнә.

Ничек сайларга һәм сакларга?

Ярманың үтә күренмәле каптагысын сайлагыз. Бу сыйфатын шундук чамаларга мөмкинлек бирә. Озаграк саклау өчен аны табада кыздырып алу да яхшы. Әлбәттә, капчыклап алып куйган запасны алай эшкәртү мөмкин түгел. Бу очракта аны караңгы, салкынчарак – һава температурасы +18 градустан да артмаган урында тотарга кирәк.

Идар Мөхәммәтҗанов

Пакетын ачкач, ярманы пыяла, пластик яки керамик савытка салып куярга киңәш ителә. Юкса, һава керу сәбәпле, тәмен югалтачак, бөҗәкләргә дә юл ачылачак. Продуктны тимер савытларда сакламагыз, чөнки тимер ярмага ят тәм сеңдерергә мөмкин. Ярма саклана торган шкаф киштәләрен даими юып, чистартып торырга кирәк. Бөҗәкләр ияләшмәсен өчен, киштәләрне аш серкәсендә чылатылган чүпрәк белән сөртеп алу да әйбәт. Ә инде ярмалар дым тартмасын өчен, тоз салынган шырпы тартмасының кырыйларын энә белән тишкәләп, аны киштәгә куярга мөмкин. Тоз дымны үзенә сеңдерәчәк, шулай ук бөҗәкләр иялэшүдән дә саклаячак. Шунысын истә тотыгыз: ярманы аскы киштәләрдә саклау дөресрәк. Җылы һәм дымлы һава һәрвакыт өскә күтәрелә, шунлыктан шкафның аскы өлешендә ярмалар яхшырак сакланачак.

Ярма, шулай ук шикәр комы, тоз җылылык +18...+25 градустан артмаганда гына әйбәт саклана. Подвал, идән асты, суыткыч саклау урыны була алмый, чөнки анда дымлылык зур. Иң әйбәте – җиллэтелә торган келәттә саклау.

Саклау вакыты

манный ярмасы – 8–9 ай

тары – 9 ай

арпа ярмасы – 14–16 ай

перловка, карабодай – 20 ай

дөге – 18 ай

борчак – 24 ай (ярдырылган борчак – 20 ай)

токмач – 1 ел

шикәр комы – 4 ел (җылытылган урында – 8 ел)

тоз – 12 ай

Халык ысуллары

Күгәрмәсен, кортламасын өчен, халык ысулларын да кулланырга мөмкин. Ярмалар өстенә, әйтик, канәфер, дәфнә яфрагы, әфлисун кабыгы яки чистартылмаган сарымсак тырнагы салып кую әйбәт. Аларны раковинадан читтәрәк саклау яхшы. Бер генә су тамчысы да савыттагы ризыкны бозачак. Ә инде шкафта бөҗәкләр пәйда булса, киштәләргә ала миләүшә (лаванда) һәм каштан ботаклары (йорт һәм бакча товарлары кибетендә сатыла) куярга мөмкин.

Кибеттән яңа гына алып кайтылган он яки ярмаларны да игътибар белән карагыз. Чөнки ихтыяҗ зур булу сәбәпле, сатучылар хәзер әллә кайчаннан бирле ятkaн запасларны да сатуга чыгара. Өйдәге башка продуктларга зыян килмәсен дисәгез, аны җентекләп тикшерегез. Бигрәк тә дөге һәм онга игътибарлы булыгыз: алар бигрәк тә тиз кортлый. Каптагы продуктны зуррак табага бушатып, чәнечке яки пычак белән болгатып карагыз. Бөҗәкләр булса, алар шундук күренәчәк. Әлбәттә, мондый ризыкны ашамавың хәерле.

Бакчачы почмагы

Сорауларга Эльмира ИСХАКОВА җавап бирә

?Помидор үсентеләрен күчереп утырткан идем. Нигәдер күтәрелеп китә алмыйлар, нечкә сабаклы булып үсәләр. Нилектән шулай икән?

Наилә МИНҺАҖЕВА.
Балык Бистәсе

– Үсентеләр артык нечкә булып, озынаеп китсә, «Атлет» ашламасын сибү киңәш ителә. Ләкин, чамасын белеп, помидор үсентесенең 3–4 чын яфрагы чыккач кына. 1 литр суга 1,5 мл ампуладагы сыекчаны өстибез дә, болгатып, һәр төпкә 30–50 мл чамасы (кечкенә бер чәркә) сибәбез. Шуннан соң 2–3 көн су сипмичә торабыз. Тамырлары көчәеп, сабаклары юанаеп китәчәк, яфраклары куе яшел төскә керәчәк. Ләкин эремәне бер генә тапкыр сибү кирәк. Яфракларына гына сиптерергә уйласак, 1,5 литр суга 1,5 мл сыекча кушып, 7 көн аралаш 3 тапкыр сиптерәбез. Борычны да шулай тукландырырга мөмкин. Баклажанның исә төбенә бер генә тапкыр сибәргә киңәш ителә.

Сүз уңаеннан, эремәне бүлмә гөлләренә дә (300 мл суга 1,5 мл препарат салып – ярты елга бер тапкыр), петунияләргә (1 литр суга 1,5 мл) сибәргә мөмкин.

?Петуния нишләптер нәзек кенә булып, бик начар үсә. Бөтен кагыйдәләрен истә тотып чәчтем югыйсә...

Нурлисә ШИҺАПОВА.
Буа

– Чәчәк үсентеләре туфракның тыгыз булуын, суны күп сибүне яратмый. Теш чистарткыч таякчык белән туфрагын йомшартып алыгыз. Калий гуматы да сипсәгез, петунияләр гөрләп үсеп китәчәк.

Тәмле булсын!

Умач ашы

Айгөл Таҗиева рецепты

Кирәк булачак: *шулпа пешерү өчен сөякле ит, бәрәңге, кишер, бер йомырка, бераз тоз, он һәм яшел тәмләткеч.*

Гадәттәгечә шулпа кайнатабыз. Тәлинкәгә бер йомырка сытабыз, бераз тоз сибеп, чәнечке белән болгатабыз. Он салабыз. Он күп булырга тиеш. Аннары аны кул белән уып, валчыклар ясыйбыз. Умачны иләк аша үткәреп, артык онын коеп төшерәбез.

Шулпага бәрәңге, кишер өстибез. Пешеп чыккач, умачны салабыз. Кайнап чыккач, сүндереп куябыз.

Валентина СЕМЕНОВА әзерләде

УРАЗА – БАРЛЫК ИЗГЕЛЕКЛӘРНЕҢ НИГЕЗЕ

Изге рамазан ае башланырга бер атна вакыт калып бара. 1 апрельдә ястү намазыннан соң беренче тәравих намазы укылачак. 2 апрель – уразаның беренче көне. Адәм баласыннан бик зур ихтыяр көче, рух ныклыгы таләп иткән гөнаһлардан чистарыну, яңару аена аяк басабыз.

«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН белән рамазан аеның асылы, ураза тоту тәртибе турында сөйләштек.

:: Рөстәм хәзрәт, рамазан аенда ураза тотуның әһәмияте нидә?

– Ашамыйча, эчмичә тору – рамазан аендагы барлык изгелекләрнең нигезе. Йорт салгандагы кебек үк шушы нигез нык булса, калган бар нәрсә яхшы булыр. Сәхәрдән ифтарга кадәр ашамыйча торып, шушы нигезне ныгытып куябыз. Аннары инде аның өстенә курыкмыйча баганалар да утыртырга мөмкин. Баганалар дигәндә, намаз уку, зәкят бирү, хаҗга бару кебек изге гамәлләрне күздә тотуым. Шул рәвешле ел дәвамында инде бу бинага түбә дә ябабыз.

:: Кемнәргә ураза тоту киңәш ителми?

– Юлда, сәфәрдә булмаган, авырмаган кеше ураза тотарга тиеш. Авыруы көчәйгән чор булса, кеше уразаны соңрак, хәле уңайлангач тота ала. Йөкле, яңа гына бала тапкан яки бала имезүче хатын-кызга ураза тотмаска киңәш ителә. Күрем вакытында да ураза тоту тыела. Җитди сәбәп аркасында ураза тота алмаган кеше тотмаган көннәре өчен фидия сәдакасы биреп, ураза тоткан кешене ашата ала.

:: Фидия сәдакасын тагын кайларга, кемнәргә бирергә була? Аны биргәндә нәрсә диярга кирәк?

– Быел фидия сәдакасының Диния нәзарәте тарафыннан расланган күләме бер көнгә 300 сумны тәшкил итә. Фидия сәдакасын ифтар ашлары уздырган мәчетләргә тапшыру хәерле. Анда ураза тотучыларны сезнең исемнән ашатачаклар. Фидия сәдакасын мохтаҗларга, балалар, картлар йортларына, ятимнәргә дә бирсәң була. Моның өчен Аллаһы Тәгалә һичшиксез әҗер-савабын бирер. Фидия сәдакасын җаваплы кешегә тапшырганда: «Бу – минем фидиям. Йа Раббым, фидиямне кабул кыл, уразаның савабын бир», – дип ниятләп бирергә кирәк. Аны кычкырып әйтү мәҗбүри түгел.

:: Фидия сәдакасын тапшыргач, син ай буе ураза тоткан булып саналасыңмы?

– Юк, фидия сәдакасын бик нык авырган, чиренең дәвасы булмаган яки бик олы яшьтә булу сәбәпле ураза тота алмаган кеше генә бирергә тиеш. Ураза тотарга мөмкинлеге була торып та, моны эшләмәгән кешеләр фидия сәдакасы биреп кенә савапка ия булмый.

:: Фитыр сәдакасын һәркем бирергә тиешме?

– Фитыр сәдакасын һәркем бирергә тиеш. Ләкин әгәр кеше үзе дә мескен хәлдә булса, күпме булдыра ала, шуның кадәр бирергә тиеш. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) аны бер хөрмә рәвешендә генә бирсәң дә була дигән. Әмма Аллаһы Тәгалә барысын да күрә, белә. Шуңа күрә, мөмкинлегең бар икән, фитыр сәдакасын бер хөрмә белән генә бирсәң дә була икән дип, тынычланырга ярамый.

islam.ru

:: Беренче тапкыр ураза тотучыларга нинди киңәш бирер идегез?

– Иң беренче чиратта аларга, шикләнмәгез, диярием. Юкса күпләр уразага керер алдыннан, булдыра алырмынмы-юкмы, дип баш вата. Шикләнсәң, булдыра алмыйсың. Шуңа күрә: «Йа Раббым, көчкуәт бир! Синең ризалыгың өчен ураза тотам», – дигән ният белән уразага керегез һәм, иншә Аллаһ, җиңел генә үтәрсез.

:: Кешедән: «Ураза тотасыңмы?» – дип сорарга ярыймы?

– Һәр сорауның әдәбе бар. Әйтик, сез кешене ифтар ашына кунакка чакырырга телисез, ди. Шунда сез аннан җайлап кына: «Син уразалымы?» – дип сорап куясың. Ник дигәндә, ифтар ашы уздыргандa уразалы кешеләрне ашатсаң, савабы күбрәк була. Андый чакта кешедән: «Ураза тотасыңмы?» – дип сорауның бернинди начарлыгы да юк. Әмма моны әдәп белән, кешенең дәрәҗәсен төшермичә, аны үпкәләтмәслек итеп эшләргә кирәк.

:: Ерак юлга чыкканда ураза тоту дөресме?

– Бу – кешенең үз ихтыярында. Тотмаган очракта да ул шушы юлдагы көннәре өчен уразаны соңрак тотып бетерә ала. Аллаһы Тәгаләдән моңа рөхсәт бар. Әмма Ул, адәм баласы юлда да ураза тотса, хәерлерәк, ди.

:: Ураза вакытында никах укытырга ярамый, диләр.

– Ураза аенда никах укыту, исем кушу кебек йолаларның барысы да рөхсәт ителә. Ләкин табын авыз ачканнан соң гына корылырга тиеш.

:: Уразалы кешегә мунча керергә рөхсәт ителәме?

– Ураза тотканда юыну, мунча керү рөхсәт ителә. Иң мөһиме – ул сиңа зыян китермәскә тиеш. Мунча кереп, чабынып, су эчәсе килеп әлсерәп йөрсә, бу бер дә дөрес булмас. Мунча керүдән аермалы буларак, уразалы килеш бассейнда йөзү тыела. Чөнки без үзебез дә сизмәстән суны йотып җибәрә алабыз.

:: Сәхәр ашамыйча гына уразага керергә ярыймы?

– Кайберәүләр сәхәргә тора алмый, йоклап кала. Андый чакта сәхәр ашамыйча да ураза дөрес булыр. Ләкин уразаны сәхәр ашап, дога кылып тоту иң бәрәкәтлесе санала. Ник дигәндә, ул вакытта бөтен догалар кабул була.

:: Ураза тотканда чәч кисәргә ярыймы?

– Ярый, бу уразаны бозмый. Аллаһы Тәгалә матурлык яклы. Шуңа күрә без дә һәрчак матур булырга тиеш.

:: Күзгә, колакка дару салу, укол ясату, сөлек салу уразаны бозамы?

– Кан бирү, сөлек салу, хиҗама ясау уразаны бозмый. Уразада килеш витаминлы уколлар ясатырга ярамый. Чөнки ул безгә көч бирә, шуңа ашау белән бер дәрәҗәдә санала. Ә гадәти укол ясату рөхсәт ителә. Шулай ук ураза тотканда борынга һәм колакка дару салу да рөхсәт ителми. Чөнки ул тамак аша уза.

:: Тәравих намазын уку бөтен кешегә дә мәҗбүриме?

– Тәравих намазының савабы бик зур. Шуңа күрә аны мәчеткә барып укысаң, хәерлерәк. Җаегыз булмаса, аны өйдә, гаиләгез белән укыгыз.

:: Сәхәр һәм ифтарда нинди ризыкларга өстенлек бирергә кирәк?

– Иң беренче һәм иң төп шарт – ашаган бар ризык хәләл булырга тиеш. Сәхәрдә безгә көне буена җитәрлек ризык ашау, күп су эчү хәерле. Кыздырган, майлы әйберләрне ифтарга калдырсаң яхшырак. Ник дигәндә, алар көне буе су эчәсе китерәчәк.

Апрель аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Җом	03:00	05:14	16:11	18:21	20:10
2	Шим	02:57	05:12	16:13	18:23	20:12
3	Якш	02:53	05:09	16:14	18:25	20:15
4	Дүш	02:50	05:07	16:16	18:27	20:17
5	Сиш	02:46	05:04	16:17	18:29	20:20
6	Чәрш	02:42	05:01	16:19	18:31	20:23
7	Пәнҗ	02:39	04:59	16:20	18:33	20:26
8	Җом	02:35	04:56	16:22	18:35	20:28
9	Шим	02:31	04:54	16:23	18:37	20:31
10	Якш	02:28	04:51	16:24	18:39	20:34
11	Дүш	02:24	04:49	16:26	18:41	20:37
12	Сиш	02:20	04:46	16:27	18:43	20:40
13	Чәрш	02:16	04:44	16:29	18:45	20:43
14	Пәнҗ	02:12	04:41	16:30	18:47	20:46
15	Җом	02:08	04:38	16:31	18:49	20:49
16	Шим	02:03	04:36	16:33	18:51	20:52
17	Якш	01:59	04:34	16:34	18:53	20:55
18	Дүш	01:55	04:31	16:35	18:55	20:58
19	Сиш	01:50	04:29	16:37	18:57	21:02
20	Чәрш	01:46	04:26	16:38	18:59	21:05
21	Пәнҗ	01:41	04:24	16:39	19:01	21:08
22	Җом	01:36	04:21	16:41	19:03	21:12
23	Шим	01:32	04:19	16:42	19:05	21:15
24	Якш	01:26	04:17	16:43	19:07	21:19
25	Дүш	01:21	04:14	16:45	19:09	21:22
26	Сиш	01:16	04:12	16:46	19:11	21:26
27	Чәрш	01:10	04:09	16:47	19:13	21:30
28	Пәнҗ	01:04	04:07	16:48	19:15	21:33
29	Җом	00:58	04:05	16:50	19:17	21:37
30	Шим	00:51	04:03	16:51	19:19	21:41

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Саклап куй!

Сәхәр ашагач, ураза тотарга ният кылганда укыла торган дога

«Нәвәйтүән әсумә саумә шәһри Рамадаанә минәлфәҗри иләл-мәгъриби хаалисән лилләһи тәгалә».

Тәрҗемәсе: Аллаһы Тәгалә өчен чын күңелдән ният кылдым ошбу көннең фарыз уразасын тотарга, таң атканнан алып, кояш баеганчыга тикле.

Авыз ачканда шушы дога укыла

«Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим. Аллаһүммә ләкә сумтү, үә бикә әәмәнтү үә гәләйкә тәүәккәлтү үә гәлә ризкыйкә әфтартү, фәгъфир лии йәә Гаффәәрү мәә каддәмтү үә мәә әххартү. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин. Әмин».

Тәрҗемәсе: Әй, Аллаһым! Ошбу уразамны Синең өчен генә тоттым һәм Сиңа гына иман китердем, вә Сиңа тәвәккәл кылдым; вә Синең ризыгың белән авыз ачамын. Әй, гөнаһларны ярлыкаучы Раббым! Минем моңа кадәр кылган гөнаһларымны да, соңгыларын да ярлыкасаң иде. Әмин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

КАЗАН ЕГЕТЛӘРЕ:

«СӘХНӘДӘ БЕР-БЕРЕБЕЗНЕ «САТАБЫЗ»

«Ни хәл?» сәхифәсенең бүгенге кунаклары – моннан 26 ел элек оешкан «Казан егетләре» төркеме. Ничек кенә үзгәрсәләр дә, сәхнәдән китәргә ашыкмый алар. Әле менә яңа егетләре белән танышып кайттык.

:: Ни хәл?
Айдар Әгъләмов:
– Бар да яхшы. Кәефләр дә шәп – яз җитте бит!

:: Бүгенге «Казан егетләре» – нинди алар?
Айдар:
– Беренчедән, «Казан егетләре»нең бүгенге кебек яшь булганы юк иде әле. Яңа тавышлар, яңа энергия, яңа җырлар, кыскасы, барысы да яңа. Шул ук вакытта тамашачыбызның теләкләрен исәпкә алып, без репертуарыбыздагы танылган җырларны да башкарабыз. Бүгенге «Казан егетләре» һәрвакыттагыча эзләнүдә.

:: Әлеге состав ничегрәк җыелды?
Айдар:
– Составтагы үзгәрешләр бөтен артист халкын сынаган авырлыклар белән бәйле. Барыбызга да билгеле сәбәпләр аркасында, җырчыларга авырга туры килде, чикләүләр чорыннан соң күпләр, гомумән, югалды. Мин моны менә ничек аңлатам: бу авырлыклар синең бу өлкәдә кирәк булу-булмавыңны аңларга ярдәм итте. Гомерен шуңа багышлап, иҗатка тугры булучылар калды. Ә без менә шул мәлдә яңа составта эшли башладык.

Беренчеләрдән булып безгә баянчы егетебез килеп кушылды.

Илназ Инсафов:
– Ягъни мин булам инде ул. Төркемгә чакырулары минем өчен бик көтелмәгән хәл булды. «Казан егетләре»н кечкенәдән беләбез бит инде, бик сөendem, билгеле.

Айдар:
– Бик талантлы егет ул. Бер күрүдә, дөресрәге, бер ишетүдә ошаттык та, җибәрәсе килмәде. Үзегез дә күрәсездер, үзенчәлекләре дә җитәрлек. Шул ук чәч төсен алсак та, нindидер экзотика бар, әйеме? *(көлә)*

Ә Радик белән без шактыйдан таныш. Бергәләп «Дуслар» төркемен булдырган идек. Ләкин безнең аны «Казан егетләре»ндә күрәсе килде.

Радик Шәрәфиев:
– Айдар шалтыратты да: «Радик, ике яңалыгым бар: берсе яхшы, икенчесе начар. Кил, икесен дә сөйләрмен», – диде. Начарыннан башларга куштым. «Дуслар»дан

китәргә туры киләчәк, ди. Әһә, мин әйтәм, бик үк яхшы хәбәр түгел шул. Икенчесе, яхшы яңалыгы, «Казан егетләре»нә чакыруы икән. Мин исә кайда кирәгрәк, шунда эшләргә әзер идем.

Айдар:
– Ә Айсафны табарга миңа дус-ишләрем булышты. Интернеттан табышып, язышып алдык та, очрашырга сүз куештык. Берзаман студиягә май кояшыдай балкып килеп керде...

Айсаф Хаҗиев:
– Башта ышанмадым, аптырап та калдым. Аннан хатынымнан сорадым. «Син бит инде шуның өчен укыган, бәлки алырлар», – дигәч, тынычландым да очрашуга киттем.

:: Яңа составны тамашачы тиз кабул иттеме?
Айдар:
– Бу сорауга да мин җавап бирәм инде, чөнки чагыштырырлыгым бар. Алдагы состав җыелып беткәч тә, тамашачы бик авыр һәм озак иябnde. Бу юлы исә бөтенләй башкача булды. Вазгыять катлаулы икәнен аңлаган хәлдә, тамашачы безнең хәлгә керде, уңай фикерләр дә озак көттермәде.

:: 1996 елда оешкан төркем бит бу...
Айдар:
– Без әле дә төркемне булдырган кеше – Рафаэль Мәҗитов белән эшлибез. Ул – безнең продюсер. Дөресен генә әйткәндә, «Казан егетләре» нәкъ менә аның зур тырышлыгы, теләге һәм ышанычы аркасында яши. Ул һәрьяклап бик ярдәм итә безгә.

Озын гомерле булуыбызның тагын бер сере – контрактларсыз эшләү. Бу яссылыкта караганда, коллективта эшләү – авыр нәрсә. Күңелеңне биреп иҗат итмәсәң, контракттагы имзаң гына сине тотып тора алмый. Кешене җир казырга мәҗбүр итеп буладыр ул, ләкин җырлатып булмый. Татар эстрадасы тарихын гына алыйк, контракт нигезендә эшләүчеләрнең күпчелеге продюсерларыннан сүзгә килми генә китә алмый. Талашып, судлашып бетәләр. Төркемдә эшләгәндә син үзең турында гына да уйлый алмыйсың. Бу – тагын бер ягы. Төркемдәшләреңә чын күңелдән, булышам, дип йөрсәң, бергә атлый аласыз, юк икән – юлларыгыз аерыла.

:: Төркемдә эшләгәндә, менә мине күбрәк күрсеннәр әле, дигән уйлар килмиме?
Айдар:
– Без бит сәхнәгә чыккач та бер-беребезне «сатабыз». Иң яхшы мәгънәдә, әлбәттә. Җырчы үз-үзен мактап торса, аңа шикләнебрәк карыйлар. Ә без бер-беребезне мактыйбыз һәм бу күпкә үтемлерәк. Башка төркемнәрнең төп ялгышы – алар бер-берсеннән көнләләр. Ямьсез итеп.

:: Соңгы проектларыгыз турында да сөйләсәгез иде.
Айдар:
– Соңгы иң зур проектларның берсе – Татарстанның һәр районына багышланган җырлардан альбом туплadык. «Тебе, мой Татарстан» дип атала ул. Сүзләрен дә, көен дә үзебез яздык. Дөрес аңлагыз: ул нинdидер шаблонга корылган җырлар түгел, һәр районныкы үзенчәлекле. Хәзер менә гастрольләрдә йөргән чакта да, нинди район аша узабыз, шул район турындагы җырны куябыз.

Без әлеге проектны Мәдәният министрлыгы белән берлектә эшләдек. Җырлап, күңел ачып, үзеңнең кесәңне генә кайгыртып йөрү – бер хәл инде. Безнең республика тарихында эзебезне калдырасы килә. Төркем оешканда ук аның төп миссиясе шул иде.

ӘҢГӘМӘНЕҢ ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Ә СИН ТАНЫЙСЫҢМЫ?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

*11 нче март санында чыккан уенда дөрес җавапны беренчеләрдән булып Казан шәһәрендә яшәүче **Энҗе Гыймадиева** юллады. Афәрин! Рәсемнәр астына без Салават Фәтхетдинов репертуарыннан «Юкка үпкәләгән булып», Гөлназ Сираеваның «Кайтабыз да китәбез» һәм Хания Фәрхи башкаруындагы «Үпкәләсәң, әйдә, үпкәлә» җырларын яшергән идек.*

Бу җырны башкаручы бер серле кошка таңнарын һәм төннәрен санарга куша.

Әлеге җыр балачакка алып кайта. Әни кулыннан «Әче» дия-дия капкан бер бакча җимеше турында ул.

Бу җырны башкаручы сиңа бер күк җисеме белән килергә куша. Тормышны нәкъ син булганга өзелеп яратым, ди.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

30 март | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР» 6+
10.00, 23.00 «Большой скачок». Док. фильм 12+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00, 00.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия» 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
23.50 «Соотечественники». Лев Толстой. Казань. Становление 12+
00.15 «Каравай». Кладези народного творения 6+
01.35 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
09.40 «Йөрәктән – йөрәккә». Радиф Гаташ турында телеочерк 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Яшьләр тукталышы» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
04.15 «Йөрәктән – йөрәккә». Радиф Гаташ турында телеочерк 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.25 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. «ЯНЫЧАР». Многосерийный фильм (S) 16+
22.55 «Большая игра» 16+
23.55 Документальное расследование Михаила Леонтьева «Большая игра». Фильм 7-й 18+
00.55 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.00 Вести
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.00 Вести
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
20.00 Вести
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков и Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
01.00 Мария Андреева, Евгений Цыганов, Надежда Маркина, Пётр Зайченко. «СОФИЯ» 16+
02.00 Ольга Будина. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
03.30 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.30, 15.10, 18.00 Новости
06.05, 18.05, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.35 Биатлон. Чемпионат России. Спринт. Мужчины. Прямая трансляция из Тюмени
10.30 Лыжные гонки. Чемпионат России. Командный спринт. Прямая трансляция из Сыктывкара
12.25 Биатлон. Чемпионат России. Спринт. Женщины. Прямая трансляция из Тюмени
14.10 «Есть тема!» Прямой эфир
15.15 «ТРЕТИЙ ПОЕДИНОК» 16+
17.10 Футбол. Чемпионат мира-2022. Отборочный турнир. Обзор 0+
18.55 Волейбол. Чемпионат России «Суперлига Paribet». Женщины. «Динамо-Ак Барс» (Казань) – «Локомотив» (Калининградская область). Прямая трансляция
20.55 Смешанные единоборства. UFC. Хабиб Нурмагомедов против Конора МакГрегора. Трансляция из США 16+
22.45 «ЧЕЛОВЕК, КОТОРЫЙ ИЗМЕНИЛ ВСЁ» 16+
01.15 «Есть тема!» 12+
01.40 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Локомотив-Кубань» (Краснодар) – «Астана» (Казахстан) 0+
03.25 Новости 0+
03.30 «Третий тайм» 12+
04.00 «МОЛОТ» 16+

НТВ

04.55 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00 Сегодня
08.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
10.00 Сегодня
10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.00 Сегодня
13.20 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.00 Сегодня
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.00 Сегодня
20.00 Премьера. «АНОНИМНЫЙ ДЕТЕКТИВ» (S) 16+
23.15 Сегодня
23.45 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
02.55 Их нравы 0+
03.25 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Синдром Бога» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «МОЖЕШЬ МНЕ ВЕРИТЬ» 16+
19.00 «КАРТА ПАМЯТИ» 16+
23.15 «ДЫШИ СО МНОЙ» 16+
02.15 «ПРОВОДНИЦА» 16+
06.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «КУЛИНАР» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 22.15 Новости дня 16+
09.25, 01.30 «ШОФЕР ПОНЕВОЛЕ» 12+
11.20 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 12+
13.25, 14.05 «КУЛИНАР» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
19.00 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 12+
20.40 «Война миров». Док. сериал. «Советские офицеры против японских самураев» 16+
21.25 «Секретные материалы». Док. сериал. Премьера! 16+
22.30 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
22.55 «Главный день». «Распад СССР». Премьера! 16+
23.45 «ЗАКОН И ПОРЯДОК. ОТДЕЛ ОПЕРАТИВНЫХ РАССЛЕДОВАНИЙ»-3 16+
03.00 «Вторая мировая война. Город-герой Севастополь». Док. фильм 12+
03.30 «КУЛИНАР» 16+

---

31 март | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР» 6+
10.00, 00.00 «Большой скачок». Док. фильм 12+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп әйрәник» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Казаннан – казанга» 12+
18.00 «Юлчы» 6+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 12+
22.10 «Наша Республика – наше дело» 12+
00.50 «Видеоспорт» 12+
01.15 «Соотечественники». Вселенная династии Дубяго 12+
01.40 «Каравай». Старинные тюрко-татарские инструменты 6+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БИТ Шоу» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Халкым минем» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Калеб» 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.25 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. «ЯНЫЧАР» (S) 16+
22.55 «Большая игра» 16+
23.55 Документальное расследование Михаила Леонтьева «Большая игра». Фильм 8-й 18+
00.55 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.00 Вести
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.00 Вести
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
20.00 Вести
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Мария Андреева, Евгений Цыганов, Надежда Маркина, Пётр Зайченко, Борис Невзоров. «СОФИЯ» 16+
02.00 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
03.30 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.30, 12.55, 15.10, 18.00 Новости
06.05, 18.05, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.35 Биатлон. Чемпионат России. Одиночная смешанная эстафета. Прямая трансляция из Тюмени
10.00 Профессиональный бокс. Александр Поветкин против Жоана Дюопа. Трансляция из Екатеринбурга 16+
11.05 Биатлон. Чемпионат России. Смешанная эстафета. Прямая трансляция из Тюмени
13.00 Специальный репортаж 12+
13.20 Футбол. Чемпионат мира-2022. Отборочный турнир. Обзор 0+
14.10 «Есть тема!» Прямой эфир.
15.15 «ТРЕТИЙ ПОЕДИНОК» 16+
17.10 Смешанные единоборства. UFC. Кертис Блейдс против Криса Дакаса. Трансляция из США 16+
18.55 Профессиональный бокс. Александр Девятов против Хесуса Куадро. Руслан Файфер против Шигабудина Алиева. Прямая трансляция из Краснодара.
22.45 «БЕЛЫЙ ШКВАЛ» 12+
01.15 «Есть тема!» 12+
01.40 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Нижний Новгород» – «Зенит» (Санкт-Петербург) 0+
03.25 Новости 0+
03.30 Биатлон. Чемпионат России. Одиночная смешанная эстафета. Трансляция из Тюмени 0+
04.30 Биатлон. Чемпионат России. Смешанная эстафета. Трансляция из Тюмени 0+

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00 Сегодня
08.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.00 Сегодня
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.00 Сегодня
20.00 Премьера. «АНОНИМНЫЙ ДЕТЕКТИВ» (S) 16+
23.15 Сегодня
23.45 «ЧП. Расследование» (S) 16+
00.20 «Поздняков» (S) 16+
00.35 «Мы и наука. Наука и мы» (S) 12+
01.30 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
03.20 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Разыскивается девочка» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.45 «ДВОЕ НАД ПРОПАСТЬЮ» 16+
19.00 «ЛЕТНИЙ СНЕГ» 16+
23.35 «ДЫШИ СО МНОЙ» 16+
02.35 «ПРОВОДНИЦА» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «КУЛИНАР» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 22.15 Новости дня 16+
09.20, 18.45 «Специальный репортаж» 16+
09.40 «ВОЖДЬ БЕЛОЕ ПЕРО» 12+
11.20 «Открытый эфир» 12+
13.25, 14.05 «КУЛИНАР» 16+
14.00 Военные новости 16+
19.00 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 12+
20.40 «Война миров». Док. сериал 16+
21.25 «Код доступа». Премьера! 12+
22.30 «Между тем» 12+
22.55 «Легенды науки» 12+
23.45 «ЗАКОН И ПОРЯДОК. ОТДЕЛ ОПЕРАТИВНЫХ РАССЛЕДОВАНИЙ»-3 16+
01.30 «В НЕБЕ «НОЧНЫЕ ВЕДЬМЫ» 12+
02.50 «Из всех орудий» 16+
03.35 «КУЛИНАР» 16+

---

1 апрель | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Рыцари вечности» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Мин» 12+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «КВН РТ-2022» 12+
00.00 «1612» 16+
02.20 «Соотечественники». Сердечная команда Рената Акчурина 12+
02.45 «Каравай». Народная песня – зеркало души 6+
03.10 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Ком сәгате» 12+
09.40 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Нәсыйхәт» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10 «Туган җир» 12+
20.00 «ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ» 6+
21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Ком сәгате» 12+
01.05 «КАПКА» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
04.15 «Ком сәгате» 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.25 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 «Голос. Дети». Новый сезон (S) 0+
23.35 Премьера. История Жак-Ива Кусто. Ламбер Вильсон. «ОДИССЕЯ» (S) 16+
01.50 «Информационный канал» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.00 Вести
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.00 Вести
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
20.00 Вести
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
00.00 Таисия Вилкова, Антон Хабаров, Юлия Майборода, Светлана Антонова, Владимир Стержаков. «СЕРЬЁЗНЫЕ ОТНОШЕНИЯ» 12+
03.10 «АЛЕКСАНДРА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 15.10 Новости
06.05, 18.30, 21.00, 23.50 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 Специальный репортаж 12+
09.25 Профессиональный бокс. Лучшие бои Эдуарда Трояновского 16+
10.35 Лыжные гонки. Чемпионат России. Эстафета. Женщины. Прямая трансляция из Сыктывкара
12.10 Лыжные гонки. Чемпионат России. Эстафета. Мужчины. Прямая трансляция из Сыктывкара
14.15, 15.15 «ПЕЛЕ: РОЖДЕНИЕ ЛЕГЕНДЫ» 12+
16.30 «Есть тема! Жеребьёвка Чемпионата мира по футболу» Прямой эфир
18.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Рубин» (Казань) – «Химки» (Московская область). Прямая трансляция
21.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Унион» – «Кёльн». Прямая трансляция
23.30 «Точная ставка» 16+
00.30 Смешанные единоборства. AMC Fight Nights. Лучшее 16+
01.40 «Реал» Мадрид. Кубок №12». Док. фильм 12+
03.25 Новости 0+
03.30 «БЕЛЫЙ ШКВАЛ» 12+

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00 Сегодня
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) 6+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» 16+
10.00 Сегодня
11.00 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.00 Сегодня
13.20 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.00 Сегодня
16.45 «ДНК» (S) 16+
19.00 Сегодня
20.00 «Жди меня» (S) 12+
21.00 «Страна талантов» (S) 12+
23.20 «Своя правда» с Романом Бабаяном (S) 16+
01.00 «Захар Прилепин. Уроки русского» (S) 12+
01.25 Квартирный вопрос (S) 0+
02.20 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40 «Давай разведёмся!» 16+
09.40 «Тест на отцовство» 16+
11.55 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Невыплаканные слёзы» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.40 «КАРТА ПАМЯТИ» 16+
19.00 «ВТОРАЯ ЖЕНА» 16+
23.20 «Про здоровье» 16+
23.40 «ДОМ, КОТОРЫЙ» 16+
03.15 «ПРОВОДНИЦА» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «КУЛИНАР» 16+
07.10, 09.20 «ИГРА БЕЗ ПРАВИЛ» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 22.15 Новости дня 16+
09.55 «БЕРЕГ» 12+
13.25, 14.05 «КУЛИНАР». 16+
14.00 Военные новости 16+
18.40, 22.30 «ЗАБЫТЫЙ» 16+
23.10 «Десять фотографий». Премьера! 12+
00.05 «ТЕГЕРАН-43» 12+
02.45 «КЛАССНЫЕ ИГРЫ» 16+
04.35 «Инженер Шухов. Универсальный гений». Документальный фильм 6+

2 апрель | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота
21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Рамил Юнысов 12+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Мин» 12+
11.30 «Казаннан – казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 «Созвездие – Йолдызлык-2022» 6+
14.30 «Әсхәт Хисмәтовның 70 яшьлек юбилей кичәсе». 1 нче булек 6+
16.00 «Әйдә, шаяРТ!» 12+
17.00 «СТЕНДАПхана» 16+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
21.30 Новости в субботу 12+
22.00 «КунакБиТ шоу». Илсөя Бәдретдинова 12+
23.30 «ВЕРСАЛЬСКИЙ РОМАН» 16+
01.20 «Каравай». Юбилейный концерт Дениса Денисова 6+
01.45 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Ләис Зәлкарнәй турында телеочерк 6+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит» 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Башваткыч» 12+
12.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.05 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Ишеттем мин кичә бәрәү җырлый» 6+
14.05 «Кояшларың белән кил син мина». Концерт 6+
17.10 «Казаннан – казанга» 12+
17.40 «Халкым минем» 12+
18.10 «Башваткыч» 12+
19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 Марат Мухин хитлары 6+
22.40 Г.Зәйнашева. «Гайфи бабай, өйлән давай!» К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 12+
01.00 «Гомер язы». Татарстанның халык артисты Резеда Шәрәфиевaның юбилей концерты 12+
03.00 «Башваткыч» 12+
03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.05 «Халкым минем» 12+
05.30 «Нәсыйхәт» 6+

1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «АнтиФейк» 16+
11.05 Премьера. Светлана Смирнова-Марцинкевич, Павел Майков. «О ЧЕМ ОНА МОЛЧИТ» (S) 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «О чем она молчит» (S) 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 «О чем она молчит» (S) 16+
15.40 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
17.00 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 «Шифр» (S) 16+
21.00 «Время»
22.00 «Шифр» (S) 16+
23.25 К 90-летию Андрея Тарковского. Фильм «СОЛЯРИС» 16+
02.25 «Наедине со всеми» 16+
03.55 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 14.00, 17.00 Вести
11.50, 14.50 «НЕВЕСТА КОМДИВА» 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
20.00 Вести
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЧУЖАЯ СЕСТРА» 12+
01.25 «ПРОТИВОСТОЯНИЕ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Лучшее 16+
07.00, 08.30 Новости
07.05, 13.35, 16.00, 19.15, 21.30, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
08.35 Биатлон. Чемпионат России. Эстафета. Женщины. Прямая трансляция из Тюмени
10.20 Лыжные гонки. Чемпионат России. Женщины. 30 км. Прямая трансляция из Сыктывкара
12.10 Биатлон. Чемпионат России. Масс-старт. Мужчины. Прямая трансляция из Тюмени
13.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Крылья Советов» (Самара) – «Уфа». Прямая трансляция
16.30 Хоккей. КХЛ. Финал конференции «Запад». Прямая трансляция
19.25 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Локомотив» (Москва) – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. Прямая трансляция
00.30 Футбол. Чемпионат Германии. «Боруссия» (Дортмунд) – «Лейпциг» 0+
02.20 Волейбол. Чемпионат России «Суперлига Paribet». Женщины. «Тулица» (Тульская область) – «Динамо» (Москва) 0+
03.25 Новости 0+
03.30 Биатлон. Чемпионат России. Эстафета. Женщины. Трансляция из Тюмени 0+
05.00 Лыжные гонки. Чемпионат России. Женщины. 30 км. Трансляция из Сыктывкара 0+

НТВ

05.20 «ЧП. Расследование» (S) 16+
05.40 «Я СЧИТАЮ: РАЗ, ДВА, ТРИ, ЧЕТЫРЕ, ПЯТЬ...» 16+
07.25 Смотр (S) 0+
08.00, 10.00, 16.00 Сегодня
08.20 «Готовим» (S) 0+
08.45 «Поедем, поедим!» (S) 0+
09.25 Едим дома (S) 0+
10.20 Главная дорога (S) 16+
11.00 «Живая еда» (S) 12+
12.00 Квартирный вопрос (S) 0+
13.05 «Однажды...» (S) 16+
14.00 Своя игра (S) 0+
15.00, 16.20 Следствие вели... 16+
18.00 «По следу монстра» (S) 16+
19.00 «Центральное телевидение»
20.15 Ты не поверишь! (S) 16+
21.10 «Секрет на миллион» (S) 16+
23.15 «Международная пилорама» с Тиграном Кеосаяном (S) 16+
00.00 «Квартирник НТВ у Маргулиса». ST (S) 16+
01.05 «Дачный ответ» (S) 0+
02.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
04.20 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА. ПОСЛЕСЛОВИЕ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Предсказания: 2022» 16+
07.25 «ГОРНАЯ БОЛЕЗНЬ» 16+
11.00 «КЛАДОВАЯ ЖИЗНИ» 16+
18.45 «Скажи, подруга» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК» 16+
23.35 «Скажи, подруга» 16+
23.50 «ДОЛГАЯ ДОРОГА К СЧАСТЬЮ» 16+
03.20 «КЛАДОВАЯ ЖИЗНИ» 16+
06.20 «ОПЕКУН» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «ЗОЛОТАЯ БАБА» 12+
06.55, 08.15 «ФИНИСТ – ЯСНЫЙ СОКОЛ» 6+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.40 «Морской бой». Премьера! 6+
09.45 «Круиз-контроль». «Эльбрус». Премьера! 12+
10.15 «Легенды музыки». «Музыка в фильме Иван Васильевич меняет профессию» 12+
10.45 «Улика из прошлого» 16+
11.40 «Война миров». Док. сериал. «Битва военных фармакологов» 16+
12.30 «Не факт!» 12+
13.15 «СССР. Знак качества» 12+
14.00 Премия Министерства обороны Российской Федерации в области культуры и искусства 0+
15.35 «КОДОВОЕ НАЗВАНИЕ «ЮЖНЫЙ ГРОМ» 12+
18.15 «Задело!» с Николаем Петровым. Информационно-аналитическая программа 16+
18.30 «...И БЫЛА ВОЙНА» 16+
21.15 «Легендарные матчи». «Чемпионат мира 1982 г. Баскетбол. Мужчины. Финал. СССР – США» 12+
00.15 «СИЦИЛИАНСКАЯ ЗАЩИТА» 12+
01.55 «БЕРЕГ» 12+
04.15 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+
05.40 «Оружие Победы» 12+

3 апрель | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Гомер китабы» 6+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
08.00 «Адымнар» 12+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Полосатая зебра» 0+
09.00 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы- шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык» 12+
11.00 «Әйләнә дөнья». Ришат Фазлыйәхмәтов концерты 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 12+
13.00 «Адымнар» 12+
13.30 «Созвездие – Йолдызлык-2022» 6+
14.30.00 «Әсхәт Хисмәтовның 70 яшьлек юбилей кичәсе». 2 нче булек 6+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней» 12+
20.00 «Соотечественники» 12+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Рамил Юнысов 12 +
23.00 «БОБЁР» 16+
00.35 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Татарлар» 12+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00, 16.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
08.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
09.00 «Галиҗәнап шагыйрь» 6+
10.00 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Татарлар» 12+
13.35 «Нәсыйхәт» 6+
14.05 «Казанның кадерле кичләре». Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхабиева концерты 6+
15.35 «Шаян хәлләр» 12+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней» 12+
21.10 «СТЭНДАПхана» 16+
21.40 «Бер сулышта» 6+
23.20 «Халкым минем» 12+
23.45 «Ком сәгате» 12+
00.40 «Татарлар» 12+
01.05 «Манзара» 6+
02.50 «Казанның кадерле кичләре». Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхабиева концерты 6+
04.30 «Җырлап яшик, туганнарым!» Татарстанның халык артисты Георгий Ибушев концерты 6+

1 КАНАЛ

05.35, 06.10 «ХИРОМАНТ». Многосерийный фильм 16+
06.00 Новости
08.25 «Часовой» (S) 12+
08.55 «Здоровье» 16+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Чемпионат России по лыжным гонкам 2022 с участием лучших лыжников мира. Мужчины. 50 км. Прямой эфир (S)
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 15.15, 18.20 «МОСГАЗ». Новое дело майора Черкасова (S) 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
21.00 «Время»
22.35 «Что? Где? Когда?» (S) 16+
23.45 К 90-летию Андрея Тарковского. Фильм «ЗЕРКАЛО» 12+
01.45 «Наедине со всеми» 16+
03.15 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.20 Эмилия Спивак, Алексей Зубков. «ЖИЛА-БЫЛА ЛЮБОВЬ» 12+
07.15 «Устами младенца»
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.50, 14.50 «НЕВЕСТА КОМДИВА» 12+
14.00 Вести
17.00 Вести
18.00 Премьера. «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 «ТЕЧЁТ РЕКА ВОЛГА» 12+
03.15 «ЖИЛА-БЫЛА ЛЮБОВЬ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Фигурное катание. Фестиваль «Влюблённые в фигурное катание». Трансляция из Москвы 0+
07.00, 07.30, 09.00, 10.00, 12.50 Новости
07.05, 09.05, 18.30, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
07.35 Биатлон. Чемпионат России. Масс-старт. Женщины. Прямая трансляция из Тюмени
10.05 «СПОРТ ТОША». Мультсериал 0+
10.15 «НА ВОДЕ». Мультфильм 0+
10.25 «БРЭК!». Мультфильм 0+
10.35 Биатлон. Чемпионат России. Эстафета. Мужчины. Прямая трансляция из Тюмени
12.55 Мини-футбол. Чемпионат России. Суперлига. КПРФ (Москва) – «Ухта». Прямая трансляция
14.55 Хоккей. КХЛ. Финал конференции «Восток». Прямая трансляция
17.15 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. ЦСКА – «Урал» (Екатеринбург). Прямая трансляция
18.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Сочи» – «Зенит». (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
21.00 После футбола с Георгием Черданцевым
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. Прямая трансляция
00.30 Автоспорт. NASCAR. Ричмонд. Прямая трансляция из США
02.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС (Казань) – «ПАРМА-ПАРИБЕТ» (Пермский край) 0+
03.25 Новости 0+
03.30 Биатлон. Чемпионат России. Эстафета. Мужчины. Трансляция из Тюмени 0+
05.00 Лыжные гонки. Чемпионат России. Мужчины. 50 км. Трансляция из Сыктывкара 0+

НТВ

05.00 Максим Виторган, Тимофей Трибунцев, Николай Добрынин. «ПОГОНЯ ЗА ШЕДЕВРОМ» (S) 16+
06.40 «Центральное телевидение» (S) 16+
08.00 Сегодня
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу (S) 12+
10.00 Сегодня
10.20 «Первая передача» (S) 16+
11.00 «Чудо техники» (S) 12+
12.00 «Дачный ответ» (S) 0+
13.00 «НашПотребНадзор» (S) 16+
14.00 Своя игра (S) 0+
15.00 Следствие вели... 16+
16.00 Сегодня
16.20 Следствие вели... 16+
18.00 «Новые русские сенсации» (S) 16+
19.00 «Итоги недели» с Ирадой Зейналовой
20.40 «Маска». Новый сезон (S) 12+
23.25 «Звезды сошлись» (S) 16+
01.00 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
03.30 «Я СЧИТАЮ: РАЗ, ДВА, ТРИ, ЧЕТЫРЕ, ПЯТЬ...» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «ОПЕКУН» 16+
10.00 «ЛЕТНИЙ СНЕГ» 16+
14.30 «ВТОРАЯ ЖЕНА» 16+
18.45 «Пять ужинов» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК» 16+
23.45 «Про здоровье» 16+
00.05 «ВРЕМЯ УХОДИТЬ, ВРЕМЯ ВОЗВРАЩАТЬСЯ» 16+
03.35 «КЛАДОВАЯ ЖИЗНИ» 16+

ЗВЕЗДА

06.05 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
06.20 «КОДОВОЕ НАЗВАНИЕ «Южный гром» 12+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №89» 16+
11.30 «Секретные материалы». Документальный сериал. «Великолепная пятёрка. Британская элита советской разведки» 16+
12.20 «Код доступа» 12+
13.15 «Специальный репортаж» 16+
13.35 «ЗАБЫТЫЙ» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.20 «Легенды советского сыска». Док. сериал 16+
22.45 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
23.00 «Фетисов» 12+
23.45 «АЛЛЕГРО С ОГНЕМ» 12+
01.30 «ИГРА БЕЗ ПРАВИЛ» 12+
03.00 «Звездный отряд». Док. фильм 12+
03.35 «КУЛИНАР» 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 28 март

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр».
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 «Данлы көннәр ельязмасы». Мөхәммәт Мәһдиев. «Без – кырык беренче ел балалары». Моноспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердашхана»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 29 март

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Лирик музыка концерты

Чәршәмбе, 30 март

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Шамил Әхмәтҗанов җырлый

Пәнҗешәмбе, 31 март

6.00-8.00 «Новый день»
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 Популяр музыка концерты

Җомга, 1 апрель

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на башкирском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Мөнир Мазунов турында

Шимбә, 2 апрель

8.10 «Җыр җиргә язлар китерә». Әдәби-музыкаль композиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Язучылар – балаларга»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Татар халык җырлары
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Шигърият». Разил Вәлиев

Якшәмбе, 3 апрель

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом»
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10, 15.10 «Татарстан дулкынында». Язучы Марат Кабировның иҗат кичәсеннән репортаж
16.10 «Әдәбиятыбыз сәхифәләре». Мөдәррис Әгъләм

ЕРЫК АВЫЗ

Юләрләр йортына тикшерү белән килгән инспекторга аңлаталар: «Кешенең юләрме, акыллымы икәнен белү өчен без болай эшлибез: ваннага су тутырабыз, анда авыруны кертеп утыртабыз, аның кулына кашык белән кружка тоттырабыз һәм ваннаның суын түгәргә кушабыз». «Ә-ә, аңладым! – ди инспектор. – Акыллы булса, суны кружка белән түгә, юләр булса...» «Юк, – дип бүлдерә аны табиб. – Акыллы булса, ванна төбендәге бөкене тартып чыгара...»

***

– Бик яхшы кер юу машинасы сатып алдым. Үзе юа, үзе сыга. Ә иң мөһиме – беренди тавышы юк!

– Ә минеке үзе суын, порошогын сала, юа, сыга, әмма тавышына чыдарлык түгел.

– Чит илнекедер әле?

– Нинди чит илнеке булсын, күрше авыл кызы!

***

Әби йокларга җыена, ә бабай һаман юыну бүлмәсеннән чыга алмый.

Әби:

– Син анда нишлисең соң?

– Тешне чистартам, – ди бабай.

– Алайса, берәттән минекеләрне дә чистарт әле!

ИРТӘДӘН ТӨНГӘ КАДӘР

ХӘМЕР САТУ ВАКЫТЫН ОЗАЙТУ НӘРСӘГӘ КИТЕРЕР?

Татарстанда исерткеч эчемлекләр сату вакытын өч сәгатькә озайттылар. Бу көннәрдә республикада әнә шундый яңа закон гамәлгә керде. Билгеле булганча, моңарчы бездә хәмерне кичке сәгать уннан иртәнге унга кадәр сату тыелган иде. Хәзер исә аны иртәнге сигездән төнге унбергә кадәр сатачаклар. Шул рәвешле Татарстанда хәмер сату вакыты ил күләмендәгесе белән тигезләште.

Бездә булмаса, күршегә чаба

Россиядә хәмер сатуны чикләү 2006 елдан бирле гамәлдә. Хәзерге вакытта ил күләмендә төнге сәгать унбердән иртәнге сигезгә кадәр исерткеч эчемлекләр сату тыела. Федераль закон нигезендә төбәкләр бу чикләү вакытын озайта ала. Әлеге мөмкинлектән Россиянең 37 төбәге файдаланган. Алар арасында Татарстан да бар иде. Хәтерләсәгез, 2017 елдан республикада кичке сәгать уннан иртәнге унга кадәр исерткеч эчемлекләр сату тыелды.

Әлеге чикләүгә үзгәрешләр кертү тәкъдиме белән чыккан Татарстан Дәүләт Советы депутаты Лотфулла Шәфигуллин сүзләренә караганда, бездә исерткеч эчемлекләрнең өч сәгатькә кимрәк сатылуы республика бюджетына шактый бәргән. Ул китергән саннар буенча, чикләүнең һәр сәгате эчендә бюджетка тиешле акчаның 9 проценты керми калган. Шул рәвешле хәмер сату вакыты чикләнгән өч ел вакыт эчендә республика бюджеты 1,5 миллиард сум чамасы акча югалткан. Бу – казнага елына 560 миллион сум акча кермәгән дигән сүз. Чикләү республика чигендәге сәүдә нокталары эшенә биграк тә аяк чалган. Ник дигәндә, хәмер белән дус булганнар аның артыннан исерткеч эчемлекләрне иртәнге сигездән төнге унбергә кадәр сатучы күрше төбәкләргә чапкан.

– Безнең белән чиктәш Башкортстан, Чувашия, Киров, Самара һәм Ульяновск өлкәләрендә хәмер сатуга федераль дәрәҗәдәге чикләүләр күптән гамәлдә. Шул рәвешле безне исерткеч эчемлекләрне иртәнге сәгать сигездән үк сатучы төбәкләр чолгап алган, – ди Лотфулла Шәфигуллин.

Эчәргә уйлаган кеше барыбер җаен таба анысы. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да шул фикердә. «Хәмер эчәргә уйлаган кеше барыбер җаен табачак. Исерткеч эчемлекне хәтта көндезге унбердән, уникедән генә сата башласаң да файдасы булмаячак. Аны алдан – запаска булса да алып куячаклар. Шуңа күрә монда халык белән эшне көчәйтергә кирәк. Чикләүләр белән хәлне катлауландырабыз гына», – диде ул парламентның утызынчы утырышында.

Депутатлар республикада хәмер сату вакытын озайтырга этәргән тагын бер сәбәпне атый. Ул да булса – ялган аракы сату һәм аннан агуланып үлүчеләр саны арту. Хәтерләсәгез, узган елның ноябрендә бер төркем студент метанол эчеп агуланган иде. 13 студентның берсе хастаханәгә барып җиткәч тә вафат булды.

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы урынбасары Марина Трофимова сүзләренә караганда, узган ел республикада ялган аракы белән агуланучылар саны, аннан алдагы ел белән чагыштырганда, 1,5 тапкыр арткан. Чагыштыру өчен: 2019 елда Татарстанда 100 мең кешегә аракы белән агуланучың 14,5 очрагы туры килгән булса, 2020 елда бу сан – 14,5. 2021 елда республикада 100 мең кешегә 17,8 ялган аракыдан агулану очрагы туры килгән. Тәгәлрәк әйтсәк, узган ел барлыгы 695 кеше ялган аракы эчеп агуланган. Шуларның 238е үлгән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Әйтергә кирәк, республикада хәмер сату мәсьәләсе тирәсендә үзгәреш җилләре күптән исәргә маташа иде инде. Хәтерләсәгез, әле февраль башында гына Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе Җәүдәт Әхмәтханов авылларда аракы сатуны арттырырга тәкъдим итте. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы исә бу карарга каршы төште. «Имамнарның эшчәнлеге авылларда исерткеч эчемлекләр сату урыннары кимүгә юнәлдерелгән. Моның өчен хәзрәтләр җирле хакимият, халык, эшмәкәрләр, авыл советлары белән сөйләшүләр алып бара. Имамнарның тырышлыгы белән Татарстандагы 16 районга караган 30дан артык авылда кибетләрдә исерткеч эчемлекләр бөтенләй сатылмый яисә изге Рамазан ае вакытында туктатыла», – диелгән иде мөрәҗәгатьтә. Дәүләт инспекциясеннән алынган мәгълүматларга караганда, узган ел иң күп исерткеч эчемлек Питрәч һәм Лаеш районнарында сатылган. Бу яктан иң түбән күрсәткечләр – Сарман һәм Яңа Чишмә районнарында, ди белгечләр.

Һәр нәрсәнең – үз урыны

Бер яхшының бер начары булган кебек бу мәсьәләнең икенче ягы да бар. Республикада хәмер сату вакытын 3 сәгатькә озайту тагын нинди нәтиҗәләргә китерер? Бүген күпләр әнә шул хакта уйлана. Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хөсәенов хәмер сату вакытын чикләү аркасында республика казнасына ел саен керми калган 560 миллион сумны әллә ни күп акча дип санамый. Ләкин килеп туган вазгыятьтә, кризис шартларында һәр тиен исәптә, дигән фикердә ул.

– Исерткеч эчемлекләр куллану – безнең җәмгыятьнең авырткан урыннарының берсе. Хәмер сату вакытын озайту белән аны кулланучылар саны да артырга мөмкин. Бу исә – эчкечелеккә бәйле җинаятьчелек, имгәнү, үлем-китем, гаиләләр таркалу, балалар ятим калу кебек тискәре күренешләр дә артачак дигән сүз. Аларны шулай ук республика бюджеты хисабына хәл итәргә туры киләчәк бит. Шушы тискәре күренешләрне хәл итүгә киткән чыгымнарның исерткеч эчемлек озаграк сатыла башлау аркасында алган табыштан күбрәк тә булуы ихтимал. Ягъни бу яңалыкның нәтиҗәләре безгә күпкә кыйммәткәрәк төшәргә мөмкин, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Эчкечелек юлына баскан кешеләр белән кырык елга якын эшләүче тәҗрибәле табиб-нарколог Рөстәм Вәлиуллин фикеренчә дә яңа закон эчкечеләр санын арттырачак. Белгеч бу урында кызык кына сан да китерде. 80 яшькә җитү өчен, кеше 29200 көн яшәргә тиеш. Эчкечеләр саны арту белән әнә шушы 30 мең көнгә дә тулмаган санаулы гомерне хәмер тозагында бушка уздыручылар саны да артачак дигән сүз.

– Исерткеч эчемлекләр сату вакытын 3 сәгатькә арттыруның бер генә уңай ягын да күрмим. Исерек ир белән интеккән теләсә кайсы хатыннан сорап карагыз: аракы сату хисабына ныгыган мондый икътисад кирәкме икән аңа? Эчкечелектән күпме гаилә, бөтен җәмгыять тилмерә. Ялган аракыга каршы көрәшәбез, диләр. Хәзер бит дәүләт кибетендә сатылган исерткеч эчемлекләргә дә ышаныч юк. Хәмерне тәүлек әйләнәсе сатсаң да, ялган аракы сатып, кесә калынайтып ятучылар саны кимемәячәк, – ди белгеч.

Илдә эчкечелек дәрәҗәсен киметү өчен, шушы кыек юлга баскан кешеләрнең узаныа тәэсир итеп дәвалауны күздә тоткан махсус кумәк сеанслар оештырырга, мәктәпләрдә, эш урынарында хәмернең организмга салган зыяны турында күбрәк лекцияләр укырга кирәк дип саный ул. Рөстәм Вәлиуллин азыктөлек кибетендә исерткеч эчемлекләр сатылуга да каршы.

– Һәр нәрсәнең – үз урыны. Хәмер дә аерым кибеттә генә сатылырга тиеш. Ипигә кергән җирдән күзгә бәрелеп котыртып торган хәмерне алучысы бик тиз табылыр. Бар нәрсәне татып карарга тырышкан үсмерләр өчен аеруча куркыныч бу. Хатын-кыз организмында исерткеч эчемлекләргә бәйлелек ир-ат белән чагыштырганда 5–6 тапкыр тизрәк пәйда була. Ир-ат уртача ун елда сәрхушкә әйләнсә, хатын-кызга ике ел да җитәргә мөмкин. Яшүсмерләрдә исә хәмергә бәйлелек 2–3 ай вакыт эчендә барлыкка килә, – ди нарколог.

Бу яңалыкны дин вәкилләре дә хупламый, әлбәттә. «Кеше күңеле төшкән вакытта проблемадан чыгу юлын эзли. Ни кызганыч, Россия халкы андый чакта хәмер белән юанырга тырыша. Шуңа күрә хәзерге болай да киеренке шартларда хәмер сату вакытын озайту аркасында, илдә эчкечеләр саны артырга мөмкин, – ди «Туган авылым» мәчете имамхатыйбы Нурулла хәзрәт Зиннәтуллин. – Шуңа бәйле рәвештә җинаятьләр саны да артачак. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хәмерне ясаган, эчкән кеше дә, саткан кеше дә, бер урыннан икенчесенә күчергән, йә булмаса, хәмергә нииндидер катнашы булган кеше – барысы да мәлгунь, ягъни ләгънәт кылынган кешеләр», – дигән. Халкыбызга өстәмә ләгънәт файдалы әйбер түгел. Шуңа күрә бу законның нәтиҗәләре бик аяныч булырга мөмкин».

Тагын да артачак

Исерткеч эчемлекләрне кичке уннан иртәнге унга кадәр сатмаганга карап кына илдә эчкечелек кимемәде. Хәмер сату вакыты озайтылгач та вазгыять әллә ни үзгәрмәс. Психотерапевт, «Яшәү территориясе» социаль инициативалар үзәге башлыгы Антон Миронов шул фикердә.

– Нииндидер чикләүләр белән генә вазгыятьнең яхшы якка үзгәргәне юк әле. Совет чорындагы кебек үк эчкечеләрне мәҗбүри дәвалау эше яңадан гамәлгә кертелсә, яхшы булыр иде, диләр. Әмма ул чорда да эчкечелекне җиңеп булмады бит. Бу афәттән котылу өчен, халыкның яшәү дәрәҗәсен күтәрергә кирәк. Кешенең лаеклы эше, тормыш алып барырлык хезмәт хакы булырлык шартлар тудырылсын, – ди белгеч.

Антон Миронов, килеп туган катлаулы вазгыятьтә, билгесезлек, иртәгәге көнгә ышаныч булмау аркасында, илдә эчкечеләр дә, наркоманнар саны да артачак, дип фаразлый.

– Пандемия башланган 2019 елда безгә мөрәҗәгать итүчеләр саны ике мәртәбә артты. Коронавирустан курыккан кеше бик зур стресс кичерде. Эшкә җитешә алмаган чаклар да күп булды. Минем тәҗрибәмдә мондый хәлнең булганы юк иде әле. Шушы шартларда яшәргә күнегеп кенә килә идек, үзегез күреп торасыз, вазгыять тагын да катлауланып куйды. Санкцияләр, инфляция, котырып үскән бәяләр, халыкның айлык керемнәре кимү... Хәзер бер хезмәт хакыннан икенчесенә кадәр очын очка ялгап яшәгән халыкның хәле тагын да катлауланачак. Яшәү дәрәҗәсе төшәчәк. Бу авырлыкка чыдый алмыйча, күпләр шешәгә үреләчәк. Шул рәвешле илдә эчкечеләр саны да артачак. Наркотик ярдәмендә онытылырга теләүчеләр дә күбәячәк, – дип фаразлый белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТЫЕЛГАНЫ ТАТЛЫРАК

Үсеп килүче буынның әхлакый ягына ныграк игътибар итә башладылар әле соңгы арада. Белер-белмәс әллә нинди юнәлешләр белән мавыгып, үзләренә дә, ил киләчәгенә дә зыян салмасын өчен дип инде. Бу юлы үзгәреш җиле якыннан – Башкортстан ягыннан исте. Күрше республика Корылтае депутатлары балалар арасында «чайлдфри» идеологиясен таратуны закон тарафыннан тыярга тәкъдим итә.

pixabay.com

Сан

Татарстанстат мәгълүматлары буенча, 2021 елда республикада 40936 бала туган. Бу 2020 елгы күрсәткечтән 662гә азрак. Узган ел башкалада 20501 бала дөньяга килгән. 2020 елда 724 сабыйга азрак иде.

Сәбәп нәрсәдә?

Белмәгәннәр өчен искәртик: чайлдфри дип баласыз тормыш рәвешен сайлаган кешеләргә әйтәләр. Бу – аңлы рәвештә нәсел калдырырга теләмәүчеләр. Әлеге идеология тарафдарлары арткан саен, киләчәк өчен борчылучылар да ишәя, билгеле. Мондый яшәү рәвеше күпләрнең уй-фикерләренә байтактан тынгы бирми инде.

Күптән түгел Федерация Советы әгъзасы Маргарита Павлова чайлдфри турындагы мәгълүматны тыю тәкъдиме белән чыгыш ясады. «Интернетта террорчылар, җинаятьчеләр, маньяклар, үтерүчеләр романтик рухка төреп тасвирлана. Хатын-кыз хокукларын яклау дигән булып, традицион гаилә абруе һәм хатын-кызның гаиләдәге роленә тап төшә. Бу – радикаль феминизм. Сайлау иреге дигән булып, гаилә корудан һәм бәби табудан баш тартуны пропагандалау бара, бу – чайлдфри. Ирек һәм толерантлык дигән булып, сәламәт булмаган җенси мөнәсәбәтләр һәм бергә яшәүнең бозык юллары пропагандалана», – дигән Маргарита Павлова. Бу күренешләрнең аңы җитлекмәгән яшьләргә аеруча тәэсир итүе дә шүрләтә түрәне. Тискәре яктан, билгеле.

Күршеләр дә борчыла. Башкортстан Корылтае депутатлары «Балалар сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян сала торган мәгълүматтан яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертүне кирәк дип саный. Сәбәбен Корылтайның Рәисе Константин Толкачев болай аңлата: «Көнбатыштан килгән чайлдфри идеологиясе Россия яшьләре арасында шактый киң таралды. Аның нигезендә, кеше үз яшәешен бәйрәм итүгә һәм шәхси ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә багышларга тиеш, дигән гедонизм фәлсәфәсе ята. Бу фикерләр балаларның җитлекмәгән аңына кереп оялаcа, бик хәтәр. Тәнкыйди карашсыз аларның киләчәккә карата бик үк дөрес булмаган максатлары барлыкка килүе ихтимал. Чайлдфри идеологиясен тарату безнең илнең дәүләт сәясәтенә каршы килә. Балаларны мондый мәгълүматтан яклау гаилә кыйммәтләрен ныгытуга ярдәм итәчәк».

Закон проектын әзерләп, Дәүләт Думасына тапшырырга телиләр. Чайлдфри идеологиясен алга сөргән өчен нинди җәза тәкъдим ителә соң? Иң элек – матди штраф. Әйтик, физик затларны – 3 мең, вазыйфаи затларны 10 мең сумга кадәр штрафка тартырга мөмкиннәр. Юридик затларга катгыйрак: 50 мең сум күләмдә штраф һәм 3 айга эшчәнлекне туктатып тору. Бу хакта мәгълүмат тараткан сайтларны да юк итү күздә тотыла.

Фикерләр каршылыклы

Баласыз бер елаган, балалы мең елаган, диләрме? Бер карасаң, һәр кеше үз язмышын үзе билгели инде. Нинди яшәү рәвеше алып баруда кемнең кемдә эше бар?! Ә шулай да, төрләр борчылыр дәрәҗәгә җиткән икән, бу күренешне тыю нинди проблемаларны хәл итәргә тиеш соң? Чикләгәнче, мәсьәләне чишү өчен бүтән юллары юкмы?

Казанның бер югары уку йортында укучы 23 яшьлек әңгәмәдәшебез, чикләүтыю белән генә проблемадан качып булмый, дигән фикердә. Ул да – чайлдфри.

– Гаилә институтын үстерү, тормышкөнкүрешне тагын да җиңеләйтү урынына иң гади ысулны – тыюны сайлыйлар. Минемчә, бу нәтиҗә бирмәячәк, моның файдасы булмаячак. Мәктәп яшендәге балаларда бунтарьлек хисе көчле. Әгәр дә нәрсәнедер тыясың, болай ярамый дип өйрәтәсең икән, алар шуның киресен эшләячәк бит. Бу әле чайлдфри күренешенең үсешенә ныграк тәэсир итмәгәе, – дип уйлый ул. – Балага чын мәгънәсендә барысын да бирә алмыйсың икән, аны дөньяга тудыру да кирәкми, минемчә. Барысы дигәндә матди, вакыт, рухи якларны күздә тотам. Шәхсән мин моңа әзер түгел. Чайлдфри тарафдары булуымның икенче сәбәбе: әлегә илемдә булачак балам өчен перспектива күрмим. Бу шартларда минем яшәвем дә җиткән. Балама да моны теләмәс идем, алар өчен яхшырак булсын дисәң бит инде.

Сәясәтчеләрнең борчылуына Россиядә чайлдфри хәрәкәтен оештыручы Эдвард Лисовский да җавап бирде. Пропаганда дип, төрләрнең бу күренеш белән көрәшә башлаулары көтелгән иде, ди ул. Эдвард инде 10 еллап чайлдфри. Баштарак якыннарына да егетнең карашын кабул итәргә авыр булган. Эдвард әле дә өйләнмәгән, балалары юк, хыялланмый да. «Мин бит башкаларга «гаилә кормагыз, бала тапмагыз» димим. Һәр кешенең сайлау иреге булырга тиеш. Мин бары тик кешеләргә бу юнәлештә мәгълүмат бирәм, баланы бөтенләй тапмаска, йә соңрак та табарга мөмкин, дип аңлатам. Ягъни мин сыр ашарга яратам, әмма барысын да сыр ашагыз дип кыстамыйм», – ди Эдвард.

Казаннан Алия Сәлахова – биш бала анасы. Моннан тыш ул гипнотерапевт, психолог, булачак аналарны авыртуларсыз гына табигый рәвештә бәби табарга әзерләүче белгеч тә. Әңгәмәдәшебез фикеренчә, чайлдфри күренеше турында төрләр борчылырлык дәрәҗәдә пропаганда алып барылмый. Һәрхәлдә, Татарстанда. Аның хакта мәгълүматны тыю да юньлегә илтмәс дигән шиге бар күпбалалы ханымның.

– Мин бер генә юнәлешне дә тәнкыйтьләмим. Һәркем үзенең күңеленә хуш килгән юлдан атлый. Сайлау иреге яклымын. Әмма бу – бер яктан, кешелеклелек ягыннан караганда. Төрле тайпылышлары булган кешеләр белән эшләүче белгеч буларак исә мондый хәрәкәтнең, кешенең бу юнәлештә уйлавының норма түгеллеген аңлыйм. Аның нигезе, күбесенчә, психологик җәрәхәтләргә бәйле, – дигән фикердә әңгәмәдәшебез.

Нәсел калдыру мөмкинлеге булган кешеләрнең кисәк кенә чайлдфри дулкынына кушылуы эчке күрсәтмәләренә (внутренние установки. – **Ч.Г.**) барып тоташа. Тәрбия, үсеш вакытындагы тайпылышлар да үз эзен калдыра. Ата-ана, ана-бала мөнәсәбәтләре дә тәэсир итә.

– Чайлдфри хәрәкәтен тыю, теләсә кайсы башка юнәлешне тыю кебек үк, мәгънәсез. Мәсьәләгә башкача якын килү кирәк, менә мәгънә нәрсәдә, – дип саный Алия Сәлахова. – Бәби табу, йөклелек чорына, бала көткән хатын-кызларга карата мөнәсәбәтне үзгәртү әһәмиятлерәк. Хәзер гаилә кору, йөклелеккә дәва таләп ителгән диагноз буларак карыйлар. Мин гел әйтәм: тыеп кына эш чыкмый, сәбәпләр белән эшләргә кирәк. Чикләү ул өскә калкып чыккан проблемага мазь сөртеп кую белән бер, билгеле бер вакытка авырткан ны басып кына тора.

Гүзәл затларның чайлдфри хәрәкәтенә кушылуына бала табу процессыннан курку хисе этәргеч бирә дип әйтү дә дөрес түгел.

– Бу курку хисе безгә тышкы факторлардан – дини тәгълиматлар, фильм, китаплар, әти-әниләребез тәҗрибәсеннән чыгып тагыла. Асылда, үз тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам, ләззәт хисе кичереп тә бәби табарга мөмкин. Һәм бу – табигый да, – дип саный Алия Сәлахова. – Бәби табудан курку хисе белән эшләмиләр бездә. Хатын-кыз йөклелек буенча учетка баскач та, бу кичерешләрен кемгә сөйли ала дип саныйсың? Иренә, гаиләсенә әйтми ул, бу хакта сөйләшергә өйрәнмәгәннәр чөнки. Хатын-кызлар консультацияләрендә дә бу турыда сөйләшмиләр, анда күбрәк анализларга игътибар бирелә.

Сүз уңаеннан

Традицион гаилә абруен сакларга һәм якларга, үстерергә телибез икән, тыюлар, күпчелек фикерен көчләп тагудан азат булырга кирәктер. Чөнки тыелган күбрәк кызыктырачак. Моны әңгәмәдәшләрнең фикерләре дә раслый.

Гаилә коруның матурлыгын күркәм гаиләләр күрсәтә. Аннан, гаилә корсам, булышучылар бар, дигән уй ышаныч өсти. Социаль шартларны яхшырту, түләү, пособие кебек матди ярдәм чараларын арттыру, шул ук ана капиталының кулланышын да киңәйтү ярап куяр, әнә шул ышанычны куәтләп җибәрер иде. Сер түгел бит: бала багу – саваплы да, нык чыгымлы да. Моннан берничә ел элек Татарстанның хәзерге бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Ирина Волынец та бу җәһәттән комплекслы эшләргә кирәклеген белдергән иде. «Дәүләттән иң яхшы ярдәм – матди ярдәм, социаль гарантияләр һәм тотрыклы икътисад. Хәзер өлкәнәю соңрак башлана, шуңа күрә соңрак бала туу нормага әверелә. Тик биологик сәгатьләрне бернинди идеология генә үзгәртә алмый шул», – дигән иде ул.

Хатын-кызларның куркуларын басу, сөйләшү өчен даирәне арттыру, махсус үзәкләр эшен көйләү дә зыян итмәс. Боларның бушлай һәм белгечләрнең компетентлы булуы мөһим инде бу очракта.

«Элек болары булмаган, тапканнар, үстергәннәр» дигән фикерләр ярсу гына уята, киресен эшләргә этәрә. Узган гасырлар белән хәзергесен чагыштыру урынсыз. Үткәнгә кайтып, кыргый шартларда яшәр өчен цивилизация юлыннан атлыйбызмыни? Аң бирелгән, башкаларны хөрмәт итәргә өйрәнгән кавем бит инде без югыйсә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Белгеч сүзе

Павел УСТИН, Казан федераль университетының Психология һәм мәгариф институты гомуми психология кафедрасы доценты:

– Җәмгыятьтә барлыкка килгән күренешләрнең алшартлары була. Чайлдфри очрагында бу – интернет барлыкка килү, гаиләдәге мөнәсәбәтләр үзгәрү, рольләр алмашыну, хатын-кызлар эмансипациясе (ике җенеснең дә тигез хокуклы булырга омтылышы. – **Ред.**). Чайлдфри ул традицион кыйммәтләрнең үзгәргәнен күрсәтүче кечкенә маяк кебек. Әмма бу юнәлеш тарафдарларын санау мөмкин түгел, чөнки кемнәрдер башка сәбәпләр аркасында бәби алып кайтырга теләми. Үзләрен чайлдфри дип санаган кешеләр бала үстерергә теләмәвен төрлечә аңлата. Әйтик, кемдер чыгымлы ди, кемгәдер – мәшәкать, кемгәдер ул карьера баскычыннан үрмәләргә комачау итә. Чайлдфри-хатын-кызларга нәсел калдыру инстинкты булмау, мәхәббәт-ярату хисләренең бәһасе кимү, ял, матди иминлек кебек кыйммәтләрнең өстен чыгуы кебек сыйфатлар хас. Лидер булырга омтылган, тәнкыйди карашлы, эгоцентризм баш калкыткан, мөстәкыйль гүзәл затлар да чайлдфри дулкынына кушыла. Баласыз тормыш рәвешен сайлаганнарның карашларын гаепләргә кирәкми. Еш кына бу – үз фикереңне белдерү ысулы һәм модага иярү генә.

ЭЛЕККЕГЕ КЕБЕК БУЛА АЛМАМ ИНДЕ...

Әле кайчан гына үз аякларында йөгереп йөргән Әлфия Хисамиева бүген чит кешеләр ярдәменә мохтаҗ. Хәер, якыннары, туганнары, әти-әнисе, каенанасы, балалары, ире ташламый аны. Әнә шул ярату яшәтә инде үзен.

Әлфия Хисамиеваның шәхси архивыннан

– Хатыным үзе йөри алмый. 2015 елда аксаклый башлаган иде ул. Ул чакта кая гына барсак та, диагноз куя алмадылар. Күренмәгән табиб калмады. Аннары бөтенләй аяксыз калды. Хәзер инде куллары да тотмый, – ди ире.

2019 елда Әлфиягә Мәскәү табиблары «хәрәкәтләндерүче нейрон чире» дигән диагноз куя.

– Авырый башлагач, Казанда зур табибларга күрендем. Алар минем чирем хакында берни әйтә алмады. Көннән-көн начарайганымны аңлап, хәтта кайчак үзләренә күренгән өчен дә акча алмыйлар иде. Мин шуннан чыгып, аңладым: хәлем яхшыдан түгел икән. Өметне өзмәскә тырышсам да булмады, – ди Әлфия. – Бик борчылып яши башладым. Ничек тә авыруны җиңәсем, аны бөтенләйгә онытасым килә иде. Тик булмады. Ашаудан калдым, 15 килога ябыктым. Күңел төшенкелегенә бирелдем. Табиблар да моны сизде. Алар, вакытында күреп алып, тиешле дарулар язды. Шулай итеп мин депрессиядән котылдым, үземне кулга алдым. Башка чара булмаганын аңладым. «Ничек бар шулай яшәргә» дигән уйга килдем. Элеккеге кебек була алмам инде. Әмма ничек тә яшисе иде. Бик тә гаиләм янында буласым килә.

Әлфиянең узган ел ахырында әтисе белән әнисе авырып китә. Аларда коронавирус табалар.

– Кышкы айларны бездә яши алар. Минем дә ис һәм тәм сизүем бетте. Мөгаен, авырганмындыр. Хастаханәгә җибәрмичә, әти белән әнине үзем карадым. Шуышып йөрсәм дә, икесенә дә система куя идем. Әллә шул чирнеке булды, әллә башка сәбәп, авырудан соң кулларым да тотмый башлады. Шуышып та йөри алмый башладым, – ди Әлфия.

Аяклар йөрмәсә дә, баштарак Әлфия, коляскага утырып, өйдәге бар эшне башкара торган була. 6 яшьлек нәни кызы бөтен эштә булыша. Әнисе өйрәтеп тора, бала ашарга әзерли. Хәзер Әлфия боларны да эшли алмый. Үзе киенә дә, хәтта чәчләрен дә тарый алмаска әйләнә.

Менә шуннан соң алар чит ил клиникасын эзли башлый. Әлфиянең чирен тулысынча дәвалап булмасын да беләләр. Әмма ничек тә аны туктатып торырга дип тырышалар. Нерв күзәнәкләренә башка зыян килмәсен өчен, дәвалану кирәклеге ачыклана. Ике клиникадан җавап килә. Хисамиевлар Төркияне сайлый.

Шөкер, мәрхәмәтле кешеләр ярдәме белән җыелган акчага алар чит илгә юл тота. Тик илдәге вазгыять аларга да кагыла. Доллар бәясе үзгәрү сәбәпле, дәвалануга күбрәк акча түләргә туры килә. Әлегә алар кунакханәдә торып дәваланалар. Болай иткәндә, яшәү өчен түләү арзанга чыга икән. Озакламый Әлфиягә ярдәм итәрлек дару клиникага килеп җитәчәк. Аны 14 көн аласы һәм 14 көн ял итәсе. Клиникада ике атна яшәү 1 миллион 700 мең сумга төшә икән. Дару өчен 400 мең сум түләячәкләр. Дәвалану алты айга сузылачак.

– Бик зур суммалар сорыйлар шул. Төрле юлларын эзлибез. Даруны алып кайтып, үзебездә ясаучы булмасмы, дибез. Өметне өзмибез, – ди Фидаил.

Әлфиянең ире – бик ипле кеше. Аның сабырлыгы сөйләшүендә үк сизелә.

– Әтидән кешелеклелек, әнидән түземлек алдык. Безне шулай үстерделәр. Мин хатыныма хәзер бик тә кирәк. Шуңа да кулдан килгәннең барысын да эшлим. Ул гына моңаймасын. Әле безнең матур көннәр алда, – ди ул.

Кызлары Азалия белән Сылуны үстереп кияүгә бирәселәре, Азаматны өйләндерәселәре бар әле аларның. Балалар әниләрен көтә инде. Савыгып кайтасына ышаналар. Алар өчен туганнары да борчыла. Барысында да бер теләк: Әлфия апалары савыксын гына.

Хисамиевлар гаиләсенә ярдәм итәргә теләүчеләр өчен исәп-хисап реквизитлары:
▸ **89083 439068** телефон номерына беркетелгән Хисамиев Фидаил Фәһиметдин улы исемендәге Саклык банкы картасы: **4279 3806 3738 1106.**
▸ **8908 349 04 10** телефон номерына беркетелгән Әлфия Рифкать кызы исемендәге «Ак Барс» банкы картасы: **2200 5301 8402 2309.**

ЕЛАП УТЫРЫП ЭШ ЧЫКМЫЙ

Мөслим районының Метрәй авылында гомер итүче Гөлзада Харисова әнә шулай ди. Бүген ул коляскада гына хәрәкәтләнә. Әмма шуңа карамастан, бар эшне үзе башкарырга тырыша. Ризыгын да пешерә, өен дә җыештыра.

Бәхетсезлек аны 23 яшендә эзләп таба. Туган авылына кайтканда, юл фаҗигасенә очрый ул. Кызның умыртка баганасы сына. Гөлзада урынга калгач, янәшәсендә гел әнисе була. Авырлыкларны бергәләп күтәрәләр. Култык таягы белән йөри башлаганчы, 4 ел урын өстендә ята ул.

– Розалия исемле апам бик булышты. Хастаханәдә мине табиблар бөтенләй карамаган булган. Тәннәрем бозылып беткән иде. Үләм дигәндә, шул апам Казахстанга алып чыгып китте. Андагы табиблар тәнемне чистартты, үлемнән алып калды, – дип искә ала Гөлзада апа.

Сызланулар, әрнүләргә түзәргә туры килә кызга. Гөлзада яңача яшәргә өйрәнә. Башка авыруларны күргәч, үз хәленә шөкер итә. Таякка таянган килеш тегүчелеккә укырга керә. Белем алып кайткач, бөтен авылга тегү тегә. Насыйбы булгач, кияүгә дә чыга. Авылдашы Рәис белән гаилә коралар.

Дөрес, Гөлзада башта каршы килә. Сәламәтлеге булмагач, кияүгә чыгу турында уйламый да. Нинди хуҗабикә чыксын аннан? Ярдәм итә алмаячак бит ул иренә. Рәисе исә аптырап тормый: «Өйдә йөри алсаң, миңа шул җитә», – дип җавап бирә.

Табиблар бала табарга ярамаганын кат-кат кисәтсә дә, Гөлзада бәбигә узып куя. Авыру кешенең, җитмәсә таякка гына таянып йөрүче хатын-кызның бала таба аласына ышанмаучылар табыла. Бер табиб Гөлзадага баласын алдырырга куша. Ризалаша ул. Үзен дә йөртергә кирәк бит! Ә озакламый тагын авырга уза! Менә шул чакта Розалия апасы киңәш бирә.

– Вакыт үтәр, әни дә булмас, туганнар да калмас. Ялгызыңа читен булыр. Тормышта ярдәмче кирәк, – ди ул.

muslumirc.ru

Бала күтәрү җиңел булмый. Гөлзада 43 яшендә әни булу бәхетен татый.

– Башка әниләр кебек баламны кулымда йөртеп үстерә алмадым. Кулларымда йоклатмадым. Улым тыныч булды. Елап интектермәде. Әле ярый тапканмын, дим. Мин гел кем өчендер дип яшәдем. Баштарак улымны үстерсәм иде, дип теләдем. Хәзер оныкларны сөеп туя алмыйм. Шул балалар өчен яшәсәм иде, дим. Рәис абыегыз да ныклы терәк булды. Тормышта төрле хәлләр килеп чыкса да, сабырлык барысын да җиңде, – ди ул.

Гөлзада апа 40 еллап таяк белән йөри. Аякларының бөтенләй көче калмагач, коляскага утыра.

– Мин авыру дип елап утырып булмый. Янәшәдә ярдәм итәрлек кешеләр булганга, мин гел яшәргә омтылдым. Башыма әллә нинди уйлар килмәде. Үземә карата кимсетү сүзләре дә ишеттем. Таяк белән йөргәнемнән дә көлделәр. Әмма шөкер, кеше сүзенә карамадым, – ди ул. – Минем – үз тормышым. Аллаһы Тәгалә сынау бирсә дә, бәхетен дә кызганмады. Улым, киленем, оныкларым бар. Рәисем ярдәм итеп тора. Миңа тагын ни кирәк соң?! Сәламәтлек булсын иде. Калганын коляскада килеш тә булдырып була икән!

Игълан тактасы

КЕМГӘ КИРӘК?

13–14 яшьлек кыз бала өчен җәйге киемнәр бар. Кирәк кеше редакциягә шалтыратсын иде.

Лилия. Казан

* * *

Яхшы хәлдәге, берничә тапкыр гына киелгән 48 үлчәмдәге тун, 39 үлчәмдәге кышкы аяк киеме бирәм.

Гөлназ. Чаллы

* * *

42–44 үлчәмдәге хатын-кыз киемнәре бирәм. Бер дә киелмәгән җәйге күлмәк, кофта-чалбарлар бар.

Регина. Казан

КЕМДӘ БАР?

Авыл җирендә яшибез. Кызымның ике баласы бар. 5 яшьлек кыз балага, 10 яшьлек малайга киемнәр бирүче булмасмы?

Фәридә. Алексеевск

* * *

Берәр кешедә 44–46 үлчәмдәге – хатын-кыз, 10 яшьлек кыз балага яраклы киемнәр булмасмы икән? Алдан ук рәхмәтемне җиткерәм.

Алинә Сафина. Казан

* * *

12 яшьлек малай өчен киемнәр кирәк иде. Бирүче булса, редакциягә хәбәр итүен сорыйм. Үзем килеп алыр идем.

Гөлнара. Казан

* * *

Авылыбызда авыр хәлдә яшәүче гаилә бар. Әниләре дә үлеп китте. Ике ир-ат ялгыз калдылар. Шуларга киемнәр кирәк иде. Аларның үлчәмнәрен дә сораштым. 48–50 нче үлчәмдәге киемнәр кияләр икән. Бу гаилә бер генә ярдәмнән дә баш тартмый. Бергәләп булышсак иде.

Фәүзия

Белдерүләр буенча редакциягә шалтыратсагыз иде. Элемтәгә керер өчен телефон: 222-09-67.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

МАРАТ КӘБИРОВ:

«ҮЗ ӘНКӘҢНЕҢ РӘХМӘТЕ КЕБЕК УЛ»

ТУКАЙ ПРЕМИЯСЕ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

Хәзерге заманда иҗатыңны да, шәхесеңне дә пропагандаларга кирәктер. Шуңа күрә, фотоны булса да чыгар, дип артыңнан калмый тагылып йөрүче иҗатчыларга да күнектек бугай инде. Активлык хуплана торган замана... Ә Марат КӘБИРОВ шуларның нәкъ киресе. Китаплары 5, 7 мең тираж белән чыккан язучы Тукай премиясенә бәйле ярышларда да катнашмый. Аның әлеге бүләккә, шуңа бәйле вазгыятькә – үз карашы. Әнә шул хакта сөйләштек тә инде.


«Татар-информ»

:: Марат абый, Тукай премиясенә быелгы кандидатлар арасында синең исем дә бар. Әлеге исемлек билгеле булгач, үзенә күрә ярыш башлана. Кандидатлар халык белән очрашулар оештыра, матбугатта исемнәре ешрак күренә башлый. Син үзең бу җәһәттән активмы, пассивмы? Кандидат булу язучыга нәрсә бирә?

– Язучыга нәрсә бирүен төгәл әйтә алмыйм инде мин. Ләкин бер кызык ягына игътибар иттем әле. Гадәттә, әйтәләр бит инде: «Ник синең бер премияң дә, мактаулы исемең дә юк?» – диләр. Моны журналистлар да, язучылар да, әдәбият белгечләре дә, башкалар да сорый. Кайберәүләр хөкүмәтне, җаваплы кешеләрне гаепләргә тотына: «Вәт, менә шундый язучыны да күрмиләр, тиешенчә бәяләмиләр!» – дип сөрәнлиләр. Ләкин теге язучыны берсе дә бернинди премиягә дә тәкъдим итми. Мине быел «Ватаным Татарстан» газетасы тәкъдим итте. Рәхмәт! Хәзер шундый тәкъдим булгач, теге кешеләр, адым саен: «Ник сиңа бер премия дә бирмиләр? Шундый язучыга!..» – дип шаулашкан журналистлар, әдәбият белгечләре һәм башкалар шатланышып пыр тузарга тиеш бит инде. Әлеге автор турында язарга, әсәрләренә күзәтү ясарга, рецензияләр, тәнкыйть мәкаләләре чыгарырга тиешләр. Хаклык тантана итүенә шанс бар хәзер. Аларның теләге чынга ашарга мөмкин. Мантыйк буенча шулай бит инде. Ләкин беркем берни дәшми. Тынлык.

Үзем турында гына әйтмим, барлык язучыга да кагыла бу. Шуңа күрә кайбер авторлар үзләре нәрсәдер оештырырга мәҗбүр була, очрашулар, матбугаттагы чыгышлар, каләмдәшләренең фикерләре. Гаепләп әйтмим, гаепли торган нәрсә түгелдер инде бу. Тик үзем андый нәрсәләргә бармадым. Нинди каләм әһеленә: «Минем хакта яз әле», – дип ялынып йөрү минем өчен түгел.

> Әгәр бүләк икән, ул язучының шәхси катнашыннан башка бирелергә тиеш. Ялынып йөреп алынган теләсә кайсы премия бүләк булудан туктый, ул хәергә әйләнә. Хәер эстәгән язучыда өмет юк.

:: Кемдер аны үзенә реклама, ди. Исеме ешрак телгә алына бит.

– Кем өчендер, бәлки, шулайдыр. Тик моның икенче ягы да бар бит әле. Әгәр исемеңне телгә алулар премия белән бәйле рәвештә генә ешая икән, бу бүләккә синең хакың бармы? Шундый сорау да туарга мөмкин.

:: Кемдер премияне дәүләт минем алдагы бурычын кайтара дип кабул итә.

– Юк, мин алай дип уйламыйм. Әлбәттә, фантастика, фэнтези кебек жанрларда да эшләгәнем бар. Ләкин: «Дәүләт бурычын кайтара», – дип уйлау өчен бик зур фантазия кирәк. Мин ул дәрәҗәдә үк фантаст түгел.

:: Ә чынлыкта Тукай премиясенең дәрәҗәсе нинди?

– Тиешле дәрәҗәдә түгел бугай. Белмим, моңа нәрсә сәбәпчедер. Менә берәр язучы чит илдә, әйтик, Англиядә берәр әсәр бастырып, нииндидер кәҗә медале тагып кайта икән, и, шуны күккә чөйгән булалар. Гади халык та, зыялылар дип аталган катлау да шулай итә. «О-о, ул бит Англиядә премия алган!» – диләр. Тегене бөтен дөнья беләдер кебек кыланалар. Эт тә белми инде югыйсә. Ә Тукай премиясе нииндидер гадәти, гади бүләк шикелле кабул ителә. Чөнки без үз хәзинәләребезне кадерли белмибез. Без аларга «татарныкы гына бит бу» диебрәк карыйбыз. Үзебезне икенчел дип кабул итүгә күнегеп киләбез. Татарның үз-үзенә карашы үзгәрсә генә ул үз байлыкларын кадерләргә өйрәнәчәк. Үзеңнеке үзәктә булырга тиеш.

:: Ә нинди булырга тиеш?

– Миңа аның исеме ошый. Тукай исемендәге дәүләт премиясе... Халыкның Тукае да, дәүләте дә булуга ишарәле.

> Бу премия татар дөньясының иң югары бүләге бит инде. Нобель премиясе шикеллерәк. Аңа караш та шул дәрәҗәдәрәк булырга тиештер. Үз халкыңның иң югары бүләге бүтән халыкларның иң югары бүләгеннән кадерлерәк булырга тиеш. Үз әнкәңнең рәхмәте кебек бит инде ул.

:: Алты язучы, дүрт театр, өч рәссам, ике музыкант, тарихчы, галимә, хореограф, фотограф. Шундый мөмкинлек бирелсә, болар арасыннан кемгә Тукай премиясен бирер идең?

– Белмим. Бу хакта уйлап та караганым юк. Тумаган тайның билен сындырып утырыр яшьтән узганмын бит инде.

:: «Китап» романы, синеңчә, киң катлау укучыга барамы? Ул нинди аудиториягә күз уңында тотып язылган?

– «Киң катлау укучы» ул бик шартлы төшенчә инде. Мавыктыргыч сюжетка корылса да, «Китап» бик гади әсәр түгел, әллә ничә катламнан тора. Белеме һәм тормыш тәҗрибәсе чамалырак кешеләр аның өске катламын гына күрә ала. Төпкәрәк төшү өчен әдәби барыш, фәлсәфә, дин, психология, яңа чор технологияләре белән таныш булу кирәк. Заманнан артта калган ачы наданнар бернәрсә дә аңламаячак. Бу очракта укучының яше, җенесе, нинди милләттән булуы да мөһим түгел бугай.

:: «Китап» һәм хәзерге яшәеш арасында аерма бармы әле?

– Әсәр язылган вакытта фантастик элементлар бик күп шикелле иде. Хәзер инде аларның күбесе чынбарлыкка әйләнеп бетте. Акыллы йорт, мәсәлән, голограммага нигезләнгән күренешләр... Хәтта туктаусыз реклама тәэсирендә гамәл кылучы кешеләр дә... Күп инде... Мин, әлбәттә, автор буларак, моңа сөенәм. Димәк, бик күп нәрсәләрне алдан күрә белгәнмен. Шул ук вакытта борчылам да. Әсәрдәге күренешләрнең чынбарлыкка әйләнүе ул – куркыныч нәрсә, хәтта фаҗига дип әйтерлек. Мин бит инде шушы фаҗига турында кисәтергә теләгән идем. Ишетүче генә табылмады. Кызганыч инде бераз.

:: Фэнтези, хоррор татар әдәбиятында үз урынын тапты дип әйтә алабызмы?

– Бүген бездә ул бар дип әйтә алабыз. Сыйфатлы хоррор. Миңа кадәр юк иде. Кайбер әсәрләрдә кулланылган аерым элементларны исәпкә алмаганда, әлбәттә. Бүген ул тулы канлы жанр буларак бар. Романнар, повестьлар, хикәяләр рәвешендә. Мин эшләдем. Мактануга охшый инде болай дисәм, тик бу чынлап та шулай. Һәм иң мөһиме аның укучылары бар.

:: Алай дисәң, фантастика дигәне дә туктап калды түгелме?..

– Шулай булырга тиеш ул. Хәзерге чор фантастика өчен җиңел түгел, чөнки технологияләр күз иярмәс тизлек белән үзгәреп тора. Бүген фантастика дип язган әсәрең берничә елдан соң көнкүреш романы булып тоелырга мөмкин. Иң яхшы дигәндә шулай. Мин менә Станислав Лем фантастикасын яратам. Тик аның киләчәктә, алга киткән җәмгыятьтә, полароид белән фотога төшереп йөргән персонажлары елмаерга мәҗбүр итә. Саф фантастика жанрында эшләү өчен тарихны өйрәнгән шикелле итеп киләчәкне өйрәнергә кирәк. Анда да әле хатадан азат булмаячаксың. Фантастика язу бүген тарихи романнар язудан да авыррак. Һәм бу жанрны укучылар күп түгел, ә гадел бәяли алучылар тагын да азрак. Юмор белән фантастикадан да тизрәк искерә торган жанр юк бүген. Ә Клиффорд Саймакның «Шәһәр»е кебек әсәрләр дөнья әдәбиятында да бик сирәк туа. Киләчәк заман турында язылган бу роман бүгенге чорны сагынырга мәҗбүр итә. Бездә әлегә андый дәрәҗәдәге фантастлар юк. Моны хәтта мин дә булдыралмыйм.

:: Җәмгыятьтә барган хәлләрне җәһәт эләктереп алып, әсәр язучылар аз. Син шундыйлардан. 175 нче гимназия фаҗигасенә багышланган повестең да бар. Син актив, ә укучың активмы? Артыңнан өлгерәме?

– Кайчагында миңа язучы үз чорының иң актуаль мәсьәләләрен чагылдырырга тиештер кебек тоела. Шул тойгы язарга этәргеч бирә бугай. Менә әле пандемиягә кагылышлы повесть тәмамланып килә. Тагын берничә идея бар. Хәзер мин төп көчемне әдәбиятка багышларга тырышам. Осталык та, тормыш тәҗрибәсе дә әйбәт әсәрләр язарга мөмкинлек бирер дәрәҗәдә. Азмы-күпме калган гомерне юк-барга әрәм итәсе килми. Шуңа тиз дә, күп тә язган кебек тоеламдыр. Ә укучылар... Барысы да өлгерә дип әйтеп булмый инде. «Күп яза, укып өлгереп булмый», – дип ачыктан-ачык әйтүчеләре дә хәтсез аның. Ләкин төп өлеше бар, мин аларны «Даими Укучым» дип йөртәм. Алар һәр әсәремне бер атна эчендә сатып алып бара. Укыйлар, фикерләрен белдерәләр. Рәхәт. Мин аларга бик рәхмәтле.

:: Тукай премиясен алдың ди. Аны нинди эшкә тотар идең?

– Ай-һай, бирерләр микән... Мин моңа тамчы да ышанмыйм. Бирмиләр аны миңа. Ә кандидатлыкка ризалашу тәкъдим итүчеләрнең күңелен төшермәс өчен генә иде. Редакциям сиңа игелек эшли, хөрмәт күрсәтә, ә син баш тартасың – яхшы түгел бит инде. Моннан мин бернәрсә дә югалтмадым. Бераз тәҗрибә арттырдым бугай. Ул тәҗрибә дә ниндидер эшкә китәчәктер инде.

:: Синең юраганың еш чынга ашамы?

– Әйе.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ГҮРБҮЗ АЗАК

МӘРЬЯМНЕҢ АТЛАРЫ

(РОМАННАН ӨЗЕК)

Дүрт ел чамасы элек Истанбулдагы бер китап кибете хуҗасы, нәшриятчы танышыбыз Гүрбүз Азакның «Мәрьямнең атлары» китабын укырга тәкъдим итте. Без китапны тизрәк сатып алырга ашыктык. Минем әле Төркиягә яңа килгән вакытым, төрекчәм дә чамалы. Китапны шактый озак укыдым, аннары анда язылганнарны, авторны өйрәнә башладым... Автор бу әсәрен заманында редакциягә килгән татар мөһаҗире хатирәләренә таянып язган.

Төркиядә 1938 елда туган журналист, язучы Гүрбүз Азакка 2021 елда Төркия Президенты Рәҗәп Таип Әрдоган тарафыннан дәүләт бүләге тапшырылды, бу вакыйга аның мәртәбәле шәхес булуын искәртте. Шәхсән үземне кабат китапка әйләнеп кайтырга этәрде. Икенче кат укыдым һәм тәрҗемә итәргә утырдым. Төркиягә чыгып киткән мөһаҗирләрнең юлын тасвирлаган әсәр уйланырга, тарихта калган сәхифәләрне яңартырга ярдәм итә...

Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА. Төркия

1

Ант итәм!

Ай, кояш, Кырым һәм Казан белән ант итәм ки, ни дисәм – исемем кадәр чынбарлык... Мин – Гомәр, алтмыш яшемдә. Бик теләдем, һәм дә безне яралткан Аллаһка ялвардым. Ул инанылмас, кан тулы, тетрәндергеч, хәтта искә төшерү куркыныч юлчылык турында ишетелгәнче, беленгәнче юкка чыгарга теләмәдем.

Үзәнлекләр, очсыз-кырыйсыз карлы тау юллары мондый, төннәре төнгә, көннәре көнгә охшамаган, атналарга сузылган елаулардан, үлемнәрдән торган бер күчеш күрмәгәннәрдер.

Әмма без бар идек. Госманлы җиренә, шөкер, барып җитә алдык.

Мин – Гомәр!

Бертуганымның ятим һәм үксез кызы бер икенде вакытында, яңгырда абына-егыла өйгә йөгереп килде, «Абзыкай!» дип, ачыргаланып кычкырды. Аның аһ оруын ни акылы, ни бәдәне лагач, «Бетте», – диделәр. «Юк, бу эш бары тик әлегә бетте. Төрекләр бетмичә туктау юк», – диделәр. Ике йөз большевик алдан карар биргән икән. Абзый, бүген нинди көн?

– Чәршәмбе, кызым.

– Якшәмбе иртәсе бу тирәләрне һәм башка төрек мәхәлләләрен салдырачаклар. Мылтык-кылычлары хәзерләнгән. Кичә бер җиргә җыелып, шундый карар кабул иткәннәр. Көлә-көлә шул хакта сөйләштеләр. Артык канун да, дәүләт тә алар, имеш. Хәлебез бик начар, абзый. Качыйк, көтеп тормыйк... Җиңгәм, ераклага китик. Үлем безне тотканчы, бер минут тормыйча качыйк!

2

Мин – Мәрьямнең абзые, Гомәр.

Шул ук төнне якын-тирәдәге кайгыдан йөрәкләре янган берничә гаилә өчен начар хәбәр язылган хатлар әзерләдем. Мәрьям иртәдән аларның өйләренә барачак, берни сөйләшеп тормыйча, әлеге язуларны тапшырачак иде. Дусларыма шулай яздым:

«Туганнар!

Кичә икенде вакытында мәктәптәге балалар һәм укытучы Муса әфәнде кылычтан кичерелде. Бу якшәмбе безгә каршы бер һөҗүм булачак, ышаныгыз. Артык тик тору һәм сорау бирү вакыты түгел. Хәзерләнегез. Мөһим әйберләрегезне, юрганнарыгызны, кышлыкларыгызны арбаларга төягез. Он, шикәр, тоз һәм чәйләрегезне, коры итләрегезне, булса, сәнәкләрегезне онытмагыз. Мылтыкларыгызны да.

Озын, читен бер сәфәргә чыгабыз. Башка чара юк. Сәфәргә бу җомга сәхәрендә, таң атканда юлга кузгалабыз.

Хәзер үк вазгыятьне белмәгәннәргә җиткерегез. Киткәннәр котылыр, калганнар үләр.

Тилермәгез, кычкырышмагыз, ятлар белән сөйләшмәгез. Көньяк тарафында, шәһәр чыгышыннан биш километр ераклыкта очрашырбыз!

Аллаһ безнең белән!

Язган: Гомәр».

Санлыйлар, хөрмәт итәләр һәм яраталар мине.

Мәрьям иртәдән кәгазь төргәген алып чыгып китте.

Без, хатыным белән, арбаны тутыра башладык. Акрын-акрын, авыр әйберләрне өйдә калдырып, иң кирәкләрен өй артына, өсте һәм кырыйлары тыгыз капланган арбага ташыдык. Әтинең ядкәре – самавырны, ике сәнәкне, ни булыр, ни булмас, урнаштырдык.

Хатыным акрын гына елый иде.

Бу хәсрәт йөге тулы сәфәрдә ничә кеше Госманлы туфрагына барып җитәр, никадәр кеше исән калыр – әйтү авыр. Асыл күчену: йөз еллар эшкәрткән туфракларны, җылы таш өйләребезне, сулыш алган һавабызны ташлап китү. Үз-үземә, Гомәр, таяныч бул, дидем. Бу сәфәр һич кулай булмаячак. Кеше үтерүчеләр, дәүләтнең коралы, бомбалы гаскәре, мәрхәмәтсез качак гаскәриләре, юлбасарлар һәм суык кыш көннәре безгә рәхәт күрсәтмәс. Ноябрь аенда бер белмәгән юлларга чыгу, күп тоткарланып тормыйча, Чечня, Дагыстан, Кавказдан, аннары Госман иленә бару – язмышыбыз.

Мин эчемнән кайгырам, үзем күзләремне качырып, хатыныма пышылдадым: «Елама, үтәр. Иңрәмә (шыңшыма), әйбәтләнер...»

Каршыбызга зур бәла килде, без дә көчле булырга тиеш идек. Аллаһ һәр кешегә үзе күтәрә алырлык йөк бирә. Без, мөгаен, тагын да авырракларын ташырбыз. Хәзергебез кебек, киләчәк тә безнең өчен юк дип уйладым. Әмма бер күренеп юк булган ул нәзберек һәм ерак тоелган өметкә ышану – бердәнбер дәвабыз, бердәнбер адресыбыз.

Мәрьям акрын гына килде, эчкә керде.

Утарга барып, арба тартачак атларны һәм Мәрьямнең үз кардәше санаган яшь, зур гәүдәле ак атны карап, юлга хәзерләдем.

Безгә хәзер куркыныч никадәр якын?

Таң никадәр ерак?

күтәрмәдә, аңын югалтып егылды балакай. Хатыным белән аны өйгә алып кереп сәкегә салдык, аңына китерергә тырыштык. «Мәрьям, Мәрьям!» – дип ялвардык, ялындык. Бераздан кан сарган яшь тулы күзләрен ачты. Бер миңа, бер җиңгәсенә аучылардан качкан кош кебек карады, калтыранып тагын бер кат «Абзый!» диде һәм тагын һушын югалтты.

Мәрьям – әле яңа ундүртен тутырган яшь, кыю кыз. Юк-барга өзелмәс, җиңел генә еламас, мәхәлләдәге һәркем яраткан фидакарь бер бала. Бу кадәр өзелгәнгә күрә, күтәрә алмаслык бик авыр хәлгә очраган яки бик начар хәбәр ишеткәндер дип юрадым.

Вакыт ястүгә якынлашканда гына аңына килде. Хәлсез килеш урыныннан торды. Җиңгәсенә, миңа озак кына карап торгач, берәр кеше ишетмәсен дигәндәй, пышылдап гына:

– Барыбызны үтерәчәкләр... – диде.

– Кемнәр?

– Шәһәрдәге бөтен татарларны (төрекләрне) кылычтан уздырачаклар, атарга тезәчәкләр.

– Кемнәр?

– Өч көннән соң, нәкъ өч көннән соң монда беркем калмаячак. Мөселман калмаячак, абзый.

Мәрьям артык еламый иде. Ул, ниһаять, элеккеге Мәрьям халәтенә кайтты. Булган хәлләрне берәм-берәм аңлатты. Дәһшәт эчендә калган кыз аягына басып тора алмыйча чүкте, дога кыла башлады. Калтырана-калтырана кабатлады: «Я Раббым, Синә сыендык, безне мәрхәмәтеңнән ташлама, колларыңны кызган...» Алдашмыйм: мин дә янына чүктем, учымны догага ачтым, тирән сулыш алып «Амин» дип әйтә алдым.

Мәрьям вазгыятьне болай аңлатты:

– Сыйныфта соңгы дәрес бетүгә иң беренче булып мин урынымнан тордым. Һәрвакыттагы кебек, тәрәзәгә үрелеп, тышка, агачларга, болытларга карый идем, 8–10 кылыч тоткан адәмнең безнең тарафка таба бакыра-кычкыра килгәннәрен күрдем: «Мәктәпләре шушы! Әнә шул бүлмә! Тамырларын корытыйк! Бүген кызгану юк! Берсе дә исән калмасын! Берсе дә!» Бөтен көчемә сыйныфтагы укытучыма, дусларыма кычкырдым: «Качыгыз! Качыгыз! Безне үтерергә киләләр!» Сыйныфта чуалыш башланды. Әмма качар урын юк иде. Мин ул чуалышта ишектән чыга алган бердәнбер кеше булдым. Ара-тирә чыккан кебек, тиз генә иске, караңгы, бик кулланылмаган баскычтан сыйныфның чатырына качтым. Тавыш-тынымны чыгармадым. Исерек большевиклар укытучының үлем куркуы белән келәләгән ишекне шатырдатып җимерделәр. Иелеп, түшәм такталары арасыннан астагы хәлләрне күзәтә башладым. Укучылар болан балалары кебек качар урын эзләде. Бер почмакка елый-елый өелештеләр. Сәрхуш адәмнәр башта алар алдына чыккан Муса мөгаллимгә әллә ничә тапкыр кылыч кададылар. Соңрак балаларга таба киттеләр.

Кыз туктап калды. Бераз тын алгач, кабат шул хәлне яшәгәндәй дәвам итте:

– Соңрак балаларны кылычтан уздырдылар. Тугызы да кычкыра-кычкыра үлде. Гомәр абый, миңа үлгәннән дә начаррак... Гомер буе оныта алмам... Елау, кычкырышлар ишетелми баш-

Дәвамы бар >

Укучыларыбыз иҗаты

Фирдәүсә БИКМӘТОВА

БҮГЕН ЯШӘ ИКӘН!

Гомер диган биек тауга карап,
Менгән чакта йөрәк тала икән.
Дәрт булса да, дәрман саекканда,
Тау башында хыял яна икән.

Таулар түбәсендә кылдай хыял,
Чыңлап өзелгәндә, упкын икән.
Киләчәкне уйлап, юл үткәндә,
Яшәү ямен таты бүген икән!

Хатирәләр күлен кичкән чакта,
Узган гомер артка дәшә икән.
Томан сарган күлгә керми генә,
Бүген яшә, бүген яшә икән!!

ХОЛЫК

Була инде, була төрле чаклар,
Сабырсыз да булам, ярсыйм да.
Кимчелексез фигыль кемдә диген?
Фәрештәдәй холык кайсында?

Сүз әйтергә кыймый телне тешләп,
Ничә көйдем кеше сүзеннән.
Көчсезлектән елаган да булды,
Качып кына кеше күзеннән.

Яшәргә көч таптым ничә сынып,
Яшь аралаш көлдем үземнән.
Шикләнмичә атлап, ничә үттем,
Үтә үткен кылыч йөзеннән.

Кимчелексез кем бар, диген, әйдә
Фәрештәдәй холык кайсында?
Йөз төрлегә сырлансам да, исәп
Сынатмаска тормыш каршында.

ИСӘН УЛ...

Менә хәзер ишек ачылыр да,
Әни керер кебек җил атлап.
Түтәлләрен бераз уташтырып,
Тавыкларга гына җим ташлап.

Табагачын мичкә терәп куйган,
Чиләгенә салган тамгасын.
Чәйнегендә чәе җылы әллә?
Мич алдында тора табасы.

Дисбеләрен, җәйләп, чөйгә элгән,
Намазлыгын төргән хәстәрләп.
Күзлеген дә иплән кенә куйган,
Ята гәҗитләре өстендә.

Бөтен нәрсә – әни исәнлеге,
Бар нәрсә дә монда урынлы.
Исән әни... Ник соң бертуктаусыз
Хәсрәт тора тырнап карынны?

Күлмәкләре әнә ничә дистә,
Яулыклары күпме сандыкта!
Бәяләр дә әзелмәгән икән, –
Бәйләмәгән, ахры, алып та.

Ул бәйләгән җылы оекбашлар,
Көткән капчыгында хуҗасын.
Алыйм әле берсен исәлеккә,
Саклап тотыйм, кимим, тузмасын.

Тәрәз төбе саен – чәчәкле гөл.
Боекканнар... Кылыйм ни чара?
Тамчылы гөл әни төсе иде...
Башын игән, сулып, бичара.

Тик шулай да күңел һич ышанмый,
Юк, үлмәгән әни, исән ул...
Ишек алдын урап керер өчен,
Тышка гына чыгып киткән ул.

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Оештыручылар – «Ватаным Татарстан» газетасы, Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте

Үзегез яшәгән җирлектәге имамнар, аларның күркәм хезмәтләре турында «Ватаным Татарстан» газетасы «бәйге» дигән тамга белән язмалар юллый аласыз.

Бәйгедә өч урын билгеләнәчәк. Аларны бүләкләү түбәндәгечә:
I урын – 10 мең сум;
II урын – 7 мең сум;
III урын – 5әр мең сум күләмендә ике премия.
Бер җиңүчегә Татарстан Диния нәзарәтеннән 10 мең сум күләмендә махсус премия тапшырылачак.

Бәйгенең төп иганәчесе – Яшел Үзән районының Бакырчы авылыннан Бәхтияровлар гаиләсе.

БӘЙГЕНЕҢ ШАРТЛАРЫ:

«Безнең авыл имамы» бәйгесенә язмалар 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 10 июленә кадәр кабул ителә. Нигезләмә белән **www.vatantat.ru** сайтында танышырга мөмкин. Бәйгегә башка матбугат чараларында басылган язмалар кабул ителми. Язма күләме басма форматта 3 биттән (юл арасы – 1,5 интервал) артмаска тиеш.

Материаллар 420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт адресы буенча яки **konkurs_vt@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә һәм кире кайтарылмый. Хатта авторның исем-фамилиясе, яше, торган урыны күрсәтелергә тиеш. **Белешмә өчен телефон: (843) 222-09-70, 8 917-927-00-40.** Бәйгедә катнашучының 2022 елның икенче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына язылган булуы шарт, квитанция күчермәсе редакциягә язма белән бергә җибәрелә. (Исегезгә төшерәбез: һәр айның 15 нче числосына кадәр язылган очракта газета киләсе айдан килә башлый.)

Бәйгенең нигезләмәсе, тулырак мәгълүмат www.vatantat.ru сайтында.
2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 1 августына кадәр дәвам итә.
Оештыручысы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Реклама. 16+

КОМБИКОРМА, ЗЕРНО
Комбикорм для *БРОЙЛЕРА ФИНИШ* (от 26дней)
25 кг – 1070 р/мешок
Комбикорм для *БРОЙЛЕРА СТАРТ* (0-25 дней)
25 кг – 1350 р/мешок
Полный ассортимент: agroline1.ru
Казань, Техническая, 15.
тел.: +792-704-99-706
Реклама

КАРПИКА һәм КАРПАТКА
токымлы бал кортлары семьясын сатам.
4 рамкалы, 2-3 кәрәзе – личинкалы,
1 кәрәзе – бал икмәге белән.
+7 96 55 99 88 67,
+7 96 25 61 60 93
Пчелопакет Карника и Карпатка комплектация по 4 рамки
2-3 расплодом +1 медаперговая
Реклама

БРИГАДА
СТРОИТЕЛЕЙ ВЫПОЛНИТ ВСЕ ВИДЫ РАБОТ *Телефон:* 89600509692

Реклама



Рәис Габдулла

18 март санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: маймыч, шаувәл, Чирмешән, ләүкә, доли, Митхун, Әсәй, ачалак, әдәп, Ус, рәшәткә, урман, Верона, әрәм, солы. **Вертикаль буенча:** элмә, Афәт, дер, чүмәлә, Маврикий, Пра, рәт, Әнвәр, чүл, чыш, ре, медуза, әдрәс, Шон, Лут, Омо, җәл, Аскын, ничек, Ары.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч вариантлан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Кол Шәриф мәчетенең ничә манарасы бар?
А) 7;
Б) 8;
В) 10.

2 «Кара үлем» — Европада чума эпидемиясе ничәнче елларга карый?
А) 1237–1240;
Б) 1378– 1417;
В) 1347–1350.

3 Михраб ул – ...
А) мәчет стенасында Мәккә юнәлешен күрсәтүче уем;
Б) сарай шагыйре һәм җырчысы;
В) матур язу сәнгате.

4 Бородино сугышы кайчан булган?
А) 1912;
Б) 1812;
В) 1814.

Җаваплар: 1) Б; 2) В; 3) А; 4) Б.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 17132 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 241

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәширият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.)**.

16+